# ШУРА

№ 31
2021

2021

1442
1443

Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы

2000999959349

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11

Аллаһы Тәгалә барлыкка китергәннәрнең хикмәте . . . . . . . . . . 12

Коръәннең исемнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17

Һәр мизгел изгелектә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22

Ислам – мәрхәмәтлелек дине . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27

Раҗәб аеның фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32

Рәгаиб кичәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37

Пәйгамбәребезнең ир-атларга киңәшләре . . . . . . . . . . . . . . . 40

Шәгъбан аеның фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45

Мигъраҗ кичәсе нәрсәгә өйрәтә? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50

Балаларыбызны милли рухта тәрбиялик . . . . . . . . . . . . . . . . . 56

Рамазан аеның фазыйләте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60

Бәраәт – мөселманнарның мәртәбәле кичәсе . . . . . . . . . . . . . . 67

Рамазанның иң зур бүләге – ураза . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72

ӘҢГӘМӘ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76

«Коръән – рухи азык» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86

Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһе . . . . . . . . . . . . . . 87

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94

ТАРИХ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102

Татарларның Таллиндагы янгын сүндерү депосын мәчет итүләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103

Беренче бөтендөнья сугышы: татар солдатлары күргән авырлыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106

Император гаиләсенең шәхси кучеры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109

Рус императорларын Ислам белән таныштырган беренче кеше 113

МИРАС . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Борындык мәчете. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117

ТӘФСИР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Ибраһим галәйһиссәлам кыйссасы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Коръән сүрәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151

ФӘН . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
«Хәдис» гыйлеменең аңлатмасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170

МӨСЛИМӘ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Ислам тарихында эз калдырган мөслимәләр . . . . . . . . . . . . . 178
Ана – бөек исем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183

НӘСЫЙХӘТ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Олы гөнаһлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188

ӘДӘБИ СӘХИФӘ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196
Кайнар диңгез юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197

**«ШУРА» дини альманах, №31**

*гыйнвар – март 2021*
*җөмәдәл-әүвәл – шәгъбан 1442*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 29.12.2020
Чыгу көне: 18.01.2021

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ! ۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ:

۞ ________________________________

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

۞ ______________________________

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللّٰهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләз̣ии һәдәәнә лиһәәз̣әә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләз̣ии каалә фии китәәбиһил- кәриими әстәгыйз̣ү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин газ̣әбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гус̣мәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләз̣иинәт-тәкау, вәл-ләз̣иинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйз̣ү билләһи: ______________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ______________________

______________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалəллаһу тәбәәракә вә тәгаалә филкәләәми. Вә иӟәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйӟу билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гаалəмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәлләӟиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраанимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлийййи вәш-шәрафил галийййи сәйййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галийййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәйййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәйййидинәл Хәсәни вә сәйййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мүъминиинә вәл мүъминәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йәъмүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

# Вәгазьләр

*8 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 24нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Аллаһы Тәгалә барлыкка китергәннәрнең хикмәте

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллэллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бер мизгелгә уйланып алыгыз әле: нинди гүзәл бу дөнья! Күпме матурлык анда! Карагыз әле, безнең Җир шарында нинди мәһабәт таулар, иксез-чиксез далалар яки урманнар, джунглилар, тирән һәм әле дә өйрәнелеп бетмәгән диңгез-океаннар бар.

Әлбәттә, иманлы адәм баласы боларның барлыкка китерүчесе Аллаһы Тәгалә икәнен таный. Танымаслык түгел бит: Җир шары, Кояш йолдызы, ерактагы калган йолдызлар, без белмәгән планеталар, гомумән, җиһан, көн-төн, акылга ия кеше, су, һава, ут – болар барысы да Аллаһы Тәгаләнең зур аятьләре булып тормыйлармы соң?

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اعْبُدُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ وَالَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ
﴿٢١﴾ الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ الْأَرْضَ فِرَاشًا وَالسَّمَاءَ بِنَاءً وَأَنزَلَ مِنَ السَّمَاءِ مَاءً
فَأَخْرَجَ بِهِ مِنَ الثَّمَرَاتِ رِزْقًا لَّكُمْ ۖ فَلَا تَجْعَلُوا لِلَّهِ أَندَادًا وَأَنتُمْ تَعْلَمُونَ
﴿٢٢﴾

**«Ий кешеләр! Сезне дә, сездән әүвәлгеләрне дә Яратучы Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз, бәлки, [Аллаһының газабыннан үзегезне коткарып] саклана алырсыз. Ул [Раббыгыз] җирне – сезнең [җайлап урнаша алуыгыз] өчен түшәк, күкне [биек түбә һәм гөмбәз кебек] бина итте, күктән су иңдерде һәм, аның белән сезгә ризык булсын өчен, [туфрактан] төрле җимешләр чыгарды. Сез, белгән хәлдә, Аллаһыга һичнәрсәне тиң итеп куймагыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:21-22

ٱللَّهُ ٱلَّذِي خَلَقَ سَبۡعَ سَمَٰوَٰتٖ وَمِنَ ٱلۡأَرۡضِ مِثۡلَهُنَّ يَتَنَزَّلُ ٱلۡأَمۡرُ بَيۡنَهُنَّ لِتَعۡلَمُوٓاْ أَنَّ ٱللَّهَ عَلَىٰ كُلِّ شَيۡءٖ قَدِيرٞ وَأَنَّ ٱللَّهَ قَدۡ أَحَاطَ بِكُلِّ شَيۡءٍ عِلۡمَۢا ﴿١٢﴾

**«Аллаһы – җиде [кат] күкне Яратучы һәм шуның кадәр үк җирне дә [бар итүче]. Аллаһының – һәрнәрсәгә [көче җиткән] кодрәтле икәнен һәм Аллаһның гыйлеме белән һәрнәрсәне уратып алганын белүегез өчен, әмер [каза һәм кадәрдән гыйбарәт булган бар итү һәм идарә итү эше] алар [җиде кат күк белән җиде кат җир катлары] арасында иңеп тора».**

«Әт-Талак», 65:12

Яхшырак аңлар өчен, бер-ике мисал карыйк:

Аллаһы Тәгалә безнең өчен ризык яраткан. Аллаһы Тәгалә нинди генә агач, шул агачларда нинди генә җимешләр барлыкка китермәгән. Җир шары буенча нинди генә үсемлекләр, хайваннар юк. Хак Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

ٱللَّهُ ٱلَّذِي جَعَلَ لَكُمُ ٱلۡأَنۡعَٰمَ لِتَرۡكَبُواْ مِنۡهَا وَمِنۡهَا تَأۡكُلُونَ ﴿٧٩﴾

**«Ул – кайсына атланып йөрүегез, кайсын [итен] ашавыгыз өчен сезгә терлек-туарны Яратучы».**

«Гафир / Гафу итүче», 40:79

Шулай ук үләннәр һәм үсемлекләр турында Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَالنَّجْمُ وَالشَّجَرُ يَسْجُدَانِ ﴿٦﴾

**«Үләннәр һәм агачлар [яратылган максатка хезмәт итү өчен Яратучыларына] сәҗдә кылалар».**

«Әр-Рахмән / Мәрхәмәтле», 55:6

Чыннан да, үләннәр һәм үсемлекләрнең вазифаларын санап бетергесез. Алар безгә, хайваннарга ризык, сулар өчен кислород чыгаручы да, кош-кортлар өчен оя да. Һәм әле без белми торган күпме сыйфатлары бардыр.

Бу аятьтән күренгәнчә, Аллаһы Тәгаләнең барлыкка китергән нәрсәләре Аңа гел гыйбадәттә, сәҗдәдә икән. Кадерле җәмәгать, без дә Аллаһы Тәгаләнең мәхлүкълары, без дә бит гел гыйбадәттә булырга тиешбездер: күп итеп зикер кылырга, намазлар укырга, садакалар бирергә һ.б.

Шулай ук Аллаһы Тәгалә бу дөньяны бер системага салып яраткан.

«Йәсин» сүрәсен исегезгә төшерсәгез, Аллаһы Тәгалә ай, кояшның үз юллары буенча йөрүләре, аларның үз вазифалары барлыгы турында әйтә. Аларның шулай йөрүеннән, Җир шарының үз тирәли һәм Кояш тирәли әйләнүеннән көн һәм төн, ел фасыллары барлыкка килә дә.

Көн һәм төннең дә үз вазифасы бар.

اللَّهُ الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ اللَّيْلَ لِتَسْكُنُوا فِيهِ وَالنَّهَارَ مُبْصِرًا ۚ إِنَّ اللَّهَ لَذُو فَضْلٍ عَلَى النَّاسِ وَلَٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَشْكُرُونَ ﴿٦١﴾

**«Аллаһы – сезгә [ял итеп] тынычлык табуыгыз өчен төнне [караңгылык итеп] Яратучы, көнне исә – [эшләп кәсеп итү, ихтыяҗларыгызны күрүегез өчен] яктылык итеп [бар итүче]. Һичшиксез, Аллаһы кешеләргә карата [ирешелмәслек дәрәҗәдә зур] рәхмәт [һәм чиксез игелек] иясе. Ләкин кешеләрнең күбесе шөкер итмиләр».**

«Гафир / Гафу итүче», 40:61

«Ән-Нәбә» сүрәсендә дә Раббыбыз моның турында безгә искә төшерә. Чыннан да, бер төн эчендә күпме сихәт бар бит, арып-талып эштән кайткач, инде бер дә хәл калмаган кебек тоела. Әмма иртән инде Аллаһы Тәгалә шушы төн эчендә безгә күпме ял биргән була.

Кадерле җәмәгать, Аллаһы Тәгаләнең барлыкка китергән әйберләреннән күпме гыйбрәт, хикмәт табып була. Ә иң мөһиме, барлык мәхлүкат Аллаһыга мохтаҗ икәнен онытмасак иде. Аллаһы Тәгалә Үзенең мәхлүкъларына мохтаҗ түгел, киресенчә, Ул –»Әс-Самәде», ягъни бөтен барлык Аңа мотаҗ. Бер генә мизгелгә дә Аның рәхмәтеннән башка яши алмый. Каты таш та, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булмаса, тузан кебек коелып бетәр иде.

اللَّهُ خَالِقُ كُلِّ شَيْءٍ ۖ وَهُوَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ وَكِيلٌ ﴿٦٢﴾

**«Аллаһы – һәрнәрсәнең Яратучысы. Ул – һәрнәрсәгә Яклаучы. [Шуңа күрә бөтен барлыклар бар булуларында Аңа мохтаҗ булганнары кебек, яшәүләрен дәвам итүләре өчен дә Аңа мохтаҗлар]».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:62

Инде вәгазебезнең ахырында шуны әйтәсе килә: Раббыбыз безне бу дөньяда да камил итеп яратты, әмма онытмыйк, безнең әле Ахирәт дөньябыз бар. Раббыбыз болай дип әйтә:

أَوَلَيْسَ الَّذِي خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ بِقَادِرٍ عَلَىٰ أَن يَخْلُقَ مِثْلَهُم ۚ بَلَىٰ وَهُوَ الْخَلَّاقُ الْعَلِيمُ ﴿٨١﴾

**«Күкләр белән җирне Яратучы алар шикеллеләрне [яңадан] яратырга кодрәтле түгелме әллә? Әйе! [Әлбәттә, Аның һәрнәрсәгә көче җитә!] Ул бит [мәхлүкълары бик күп булган һәм кабат-кабат] Яратучы, [һәрнәрсәне] Белүче».**

«Йәсин», 36:81

Көн саен Раббыбызның барлыкка китергәннәренә карап, фикерләп, Аңа якынаерга насыйп булса иде. Әәмин!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*
*Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*15 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Коръәннең исемнәре

Әгүүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи кәрим вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Галимнәр фикеренчә, Коръәннең бик күп исемнәре бар, якынча 90 исем дип әйтелә. Әмма кайбер галимнәрнең сүзләренә караганда, Коръәннең исемнәре түгел, ә аның сыйфатлары дип әйтү дөресрәк, чөнки Коръәннең исеме бер генә – «Коръән» дип әйтелә, ә калганнары Коръәннең сыйфатлары. Ә без кайберләрен генә атап китәрбез.

Коръәннең иң мәшһүр вә мәгълүм беренче исеме – ул **«Әл-Коръән»**, кайбер галимнәр аның мәгънәсен иң күп укыла торган китап дип аңлата. Шулай ук «җыелган» дигән мәгънәсе дә бар. Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

لَا تُحَرِّكْ بِهِ لِسَانَكَ لِتَعْجَلَ بِهِ ﴿١٦﴾ إِنَّ عَلَيْنَا جَمْعَهُ وَقُرْآنَهُ ﴿١٧﴾ فَإِذَا قَرَأْنَاهُ فَاتَّبِعْ قُرْآنَهُ ﴿١٨﴾ ثُمَّ إِنَّ عَلَيْنَا بَيَانَهُ ﴿١٩﴾

**«[Ий Җәбраил китергән вәхине тыңлаганда ул бетергәнче укый башлаган Расүлем!] Аны тизрәк отып алыр өчен [тәмамлануын көтмичә] телеңне дә кузгатма! Һичшиксез, аны [синең хәтереңдә] җыю да һәм укыту да – Безнең өстебездә. Һәм Без аны [Җәбраилнең теле белән] укыган чакта, син аның укуына ияр генә! Шуннан соң аны [мәгънәләре белән] аңлату – Безнең өстебездә».**

«Әл-Кыямә / Кыямәт», 75:16-19

Әмма шәригать күзлегеннән Корьән – ул **«Аллаһы Сүзе»**, Пәйгамбәребезгә иңгән, тиләвәте илә гыйбадәт, аятьләре исә могҗиза булып, вә барча кешеләргә вә җеннәргә бердәмлеккә вә һидаятькә өнди торган Китап булып санала.

Корьәннең икенче исеме дә нәкъ менә **«Әл Китап»** дип атала.

Китап дигән сүз – ул хәрефлерне бер урынга җыюны белдерә, ә шәригатьтә бөтен кыйссаларны, хөкемнәрне, аятьләрне, хәбәрләрне үз эченә туплаган, дип аңлатыла. Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда болай дип әйтә:

ذَٰلِكَ الْكِتَابُ لَا رَيْبَ ۛ فِيهِ ۛ هُدًى لِّلْمُتَّقِينَ ﴿٢﴾

**«Ул – [пәйгамбәрләр (галәйһимуссәлам) хәбәр иткән] үзендә бер шик тә булмаган, мөттәкыйләр [Аллаһы рәхмәтен югалтудан куркучы тәкъвалар] өчен юл күрсәтә торган Китап».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:2

Корънннең өченче исеме – **«Әл-Фуркан»**, чөнки «Фуркан» дигән сүз ул «хакны батылдан, акны карадан аеру» дигән мәгънәне белдерә. Аллаһы Тәгалә Корънни Кәримдә болай дип әйткән:

تَبَارَكَ الَّذِي نَزَّلَ الْفُرْقَانَ عَلَىٰ عَبْدِهِ لِيَكُونَ لِلْعَالَمِينَ نَذِيرًا ﴿١﴾

**«[Кеше һәм җен җәмгыятен исәпкә алып] Бөтен галәмнәр өчен бер үгетләүче булсын дип, Фурканны [Корънне] колына [Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдергән Зат – [һәрнәрсәдән хәерле] Бөек».**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:1

Корънннең дүртенче исеме – **«Әт-Тәнзил»**, ягъни «иңдерелгән» дигән сүз. Корън Аллаһы тарафыннан иңгәнгә күрә, Аллаһы аны Әт-Тәнзил дип атады. Аллаһы бу турыда болай дип әйтә:

وَإِنَّهُ لَتَنزِيلُ رَبِّ الْعَالَمِينَ ﴿١٩٢﴾

**«Һичшиксез, ул [Корън] – бөтен галәмнәрнең Раббысының иңдерүе».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:192

Корънннең бишенче исеме – **«Әз-Зикер»**, ягъни «искә төшерү». Галимнәр Корънгә шундый исем бирелү өч төрле сәбәп аркасында диләр:

1. Вагазь вә кисәтүче буларак искә төшерә торган (зикер).

2. Кешеләрнең дөнья вә Ахирәттә булган ихтыяҗларын үз эченә алган.

3. Зикер, ягъни шәрәф мәгънәсендә, гомумән халыкларга ул Аллаһыны зикер итеп укыла торган Китап.

Аллаһы Тәгалә Корънндә болай дип әйтә:

وَإِنَّهُ لَذِكْرٌ لَّكَ وَلِقَوْمِكَ ۖ وَسَوْفَ تُسْأَلُونَ ﴿٤٤﴾

**«Ул – [сиңа вәхи ителгән Коръән гарәп телендә иңдерелгән булуы белән] синең өчен дә, кавемең өчен дә бер үгет. Әмма тиздән [Кыямәт көнендә] соралачаксыз».**

«Әз-Зүхруф / Зиннәтләнү», 43:44

Коръәннең алтынчы исеме – **«Әл-Мәүгыйзә»** дип атала, ягъни «Вәгазьче-Нәсыйхәтче».

يَا أَيُّهَا النَّاسُ قَدْ جَاءَتْكُم مَّوْعِظَةٌ مِّن رَّبِّكُمْ وَشِفَاءٌ لِّمَا فِي الصُّدُورِ وَهُدًى وَرَحْمَةٌ لِّلْمُؤْمِنِينَ ﴿٥٧﴾

**«Ий кешеләр! Сезгә Раббыгыздан бер үгет, күкрәкләрдәге [шик-шөбһәләр кебек начар] нәрсәләргә бер шифа, һидаять, мөэминнәр өчен бер рәхмәт [булган Коръәни Кәрим] килде».**

«Юныс», 10:57

Коръәннең җиденче исеме – **«Шифа» вә «Рәхмәт»**, ягъни «Аллаһының рәхмәт вә шифа бирә торган Китабы».

وَنُنَزِّلُ مِنَ الْقُرْآنِ مَا هُوَ شِفَاءٌ وَرَحْمَةٌ لِّلْمُؤْمِنِينَ ۙ وَلَا يَزِيدُ الظَّالِمِينَ إِلَّا خَسَارًا ﴿٨٢﴾

**«Без мөэминнәр өчен шифа һәм рәхмәт булган Коръәнне иңдерәбез. Әмма ул [Коръәни Кәримне инкяр итүдә үҗәтлек күрсәткән] залимнәргә зарардан башка берни дә арттырмый».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:82

Коръәннең сигезенче исеме – **«Ән-Нур»**, ягъни «Якты Китап».

فَالَّذِينَ آمَنُوا بِهِ وَعَزَّرُوهُ وَنَصَرُوهُ وَاتَّبَعُوا النُّورَ الَّذِي أُنزِلَ مَعَهُ ۙ

**«Аңа иман китергән кешеләр аны олыларлар, [дәгъватын ирештерү юлында] аңа ярдәм итәрләр һәм аның белән бергә иңдерелгән нурга иярерләр».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:157

Коръәннең тугызынчы исеме **«Әл-Хакк»**, ягъни «хакыйкатьне сөйли торган Китап».

وَإِنَّهُ لَحَقُّ الْيَقِينِ ﴿٥١﴾

**«Һичшиксез, ул [Коръән] – шиге булмаган хак».**

«Әл-Хәкка / Котылгысыз», 69:51

«Коръәннең унынчы исеме – **«Әл-Газыйм»**, ягъни **«Бөек Китап».**

وَلَقَدْ آتَيْنَاكَ سَبْعًا مِّنَ الْمَثَانِي وَالْقُرْآنَ الْعَظِيمَ ﴿٨٧﴾

**«Без сиңа кабатлана торган җиде мактау чарасын [җиде аятьле «Фатиха» сүрәсен] һәм олуг Коръәнне бирдек».**

«Әл-Хиҗр», 15:87

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*22 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Һәр мизгел изгелектә

Бөтен дөньяларны юктан бар кылып, безгә җан иңдереп һәм күп төрле нигъмәтләрен бирүче Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр һәм данмактаулар булса иде. Пәйгамбәрләребезнең соңгысы булган Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

قُلْ يَا عِبَادِ الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا رَبَّكُمْ ۚ لِلَّذِينَ أَحْسَنُوا فِي هَٰذِهِ الدُّنْيَا حَسَنَةٌ ۗ

**«[Расүлем! Минем исемнән] Әйт: «Ий Минем иман китергән колларым! Раббыгыздан куркыгыз! Бу дөньяда изге гамәл кылган кешеләр өчен әҗер бар».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:10

Изгелек... Шушы сүздә күпме мәгънә һәм күңелгә нур булып үтеп керә торган җылылык. Мөгаен, изгелекне бу дөньяда бөтен зат та аңлыйдыр. Иман китерүче һәркем изгелек кыларга тиеш. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем үзен изгелектән (башкаларга яхшылык теләүдән, йомшаклыктан) мәхрүм кылса, шул үзен күп изгелекләрдән мәхрүм кылыр», – дип әйткән.

Намаз, ураза безнең үзебез өчен кылына торган изгелекләр. Ә башка кешеләргә карата кылынган изгелек икеләтә сөенечле, чөнки үзебезгә эшләнгән изгелек белән савап алсак, башкаларга изгелек кылуыбыз белән без аларны сөендереп, аларга да изгелеккә юлны күрсәтәбез. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

لَّيْسَ الْبِرَّ أَن تُوَلُّوا وُجُوهَكُمْ قِبَلَ الْمَشْرِقِ وَالْمَغْرِبِ وَلَٰكِنَّ الْبِرَّ مَنْ آمَنَ
بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ وَالْمَلَائِكَةِ وَالْكِتَابِ وَالنَّبِيِّينَ وَآتَى الْمَالَ عَلَىٰ حُبِّهِ
ذَوِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينَ وَابْنَ السَّبِيلِ وَالسَّائِلِينَ وَفِي الرِّقَابِ
وَأَقَامَ الصَّلَاةَ وَآتَى الزَّكَاةَ وَالْمُوفُونَ بِعَهْدِهِمْ إِذَا عَاهَدُوا ۖ وَالصَّابِرِينَ فِي
الْبَأْسَاءِ وَالضَّرَّاءِ وَحِينَ الْبَأْسِ ۗ أُولَٰئِكَ الَّذِينَ صَدَقُوا ۖ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُتَّقُونَ
﴿١٧٧﴾

**«Игелек [тәкъвалык] – йөзләрегезне [гыйбадәт вакытында Кодеснең] көнчыгыш яки көнбатыш тарафына юнәлдерүегез [генә] түгел[1]. Ләкин чын игелек – Аллаһыга, Ахирәт көненә, фәрештәләргә, Китапка һәм пәйгамбәрләргә иман китергән; кадерле булганыннан [мал-мөлкәтне] туганнарына, ятимнәргә, мескеннәргә, юлда калганнарга, теләнчеләргә һәм коллар азат итүгә мал сарыф иткән; [фарыз] намазны укыган, зәкят биргән, вәгъдәләшкән чакта сүзләрендә торган, [фәкыйрьлек кебек] кыенлыкта, [хасталык кебек] авырлыкта һәм [сугышның иң кызган чагындагы кебек] афәтләр вакытында сабыр иткәннәр ул. Әнә шулар – [иманнарына] тугрылыклы кешеләр һәм әнә шулар [яман эшләрдән һәм көферлектән үзләрен саклаган] тәкъвалык ияләре».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:177

Җир йөзенә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән булган бер вакыйганы искә алыйк.

---

1 Насаралар Кодес шәһәренең көнчыгышына таба йөзләрен юнәлдерүне игелек дип санаганнар, ә яһүдиләр, киресенчә, көнбатышына юнәлдерүне игелек дип санаганнар.

Ул Пәйгамбәребезнең киң күңелле, олы йөрәкле кеше икәненә тагын бер дәлил.

Расүлебез Исламга чакыру нияте белән Таиф шәһәренә килгәч, аны ташлар атып куып җибәрәләр. Шулвакытта Җәбраил галәйһиссәлам аның янына таулар фәрештәсе белән килә һәм ул: «Ий Аллаһының Расүле! Әгәр син теләсәң, мин бу җирлекне юк итәрмен», – дип әйтә. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу сүзләргә: «Юк, алай эшләргә кирәкми. Мин бу җир йөзенә рәхмәт буларак җибәрелдем. Мин алар нәселеннән изге кешеләр чыгар дип өметләнәм», – дип җавап кайтара.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм изгелек кылу хакында болай дип әйткән: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәдә дә (барлык очракларда да) изгелекне (башкаларга яхшылык теләүне, йомшаклыкны) сөя».

Изгелектә Аллаһының рәхмәте, бәрәкәте бар. Аны кылгач, ишеткән рәхмәт сүзләребез безгә дога булып бара. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Раббыларына иң рәхмәтле булучылар – кешеләргә (кайсы милләт һәм дин вәкиле булуларына карамастан) иң рәхмәтле булучылар».

Изгелек – ул каткан йөрәкләргә назлы, язгы Ләйсән яңгыры сыман, күңелләрне җебетә. Әгәр тормышыбызның якты булуын теләсәк, изгелек кылыйк. Изгелек тормышыбызга нур һәм бәрәкәт алып килер, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте артуына сәбәпче булыр. Раббыбыз Коръәндә болай дип әйткән:

لِّلَّذِينَ أَحْسَنُوا فِي هَٰذِهِ الدُّنْيَا حَسَنَةٌ ۚ وَلَدَارُ الْآخِرَةِ خَيْرٌ ۚ وَلَنِعْمَ دَارُ الْمُتَّقِينَ ﴿٣٠﴾

**«Игелек кылган кешеләргә бу дөньяда әҗер бар. Ахирәт йорты исә [дөньяда кулга төшерелгәннәрдән] яхшырак. Тәкъвалык ияләренең йорты [булган җәннәт] нинди яхшы [бер урын]»!**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:30

Шунысы да мөһим: ихлас күңелдән, риясыз кылынган изгелек кенә Аллаһы тарафыннан зур дәрәҗәгә ия. Әйтик, берәү зур суммадагы акчалар белән изгелекләр кыла ди, әмма аның күңелендә рия бөртеге була һәм шул сәбәпле бөтен әҗере юкка чыга. Ә икенче берәү кечкенә генә гамәлне дә ихлас күңелдән башкара. Һәм шул кечкенә гамәл берничә зур гамәлне алыштыра. Коръәндә Раббыбыз болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا ارْكَعُوا وَاسْجُدُوا وَاعْبُدُوا رَبَّكُمْ وَافْعَلُوا الْخَيْرَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ۩ ﴿٧٧﴾[1]

**«Ий иман китерүчеләр! Рөкүгъ кылыгыз, сәҗдә кылыгыз, [бөтен фарызларны үтәп] Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз һәм [нәфел гыйбадәтләр, туганлык җепләрен саклау, күркәм әхлаклы булу кебек] игелек эшләгез. Бәлки, сез уңышка ирешерсез»;**

«Әл-Хаҗ», 22:77

فَآتَاهُمُ اللَّهُ ثَوَابَ الدُّنْيَا وَحُسْنَ ثَوَابِ الْآخِرَةِ ۗ وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ ﴿١٤٨﴾

**«Аллаһы аларга һәм [ярдәм, җиңү һәм ганимәт кебек] дөнья савабын, һәм күркәм Ахирәт савабын [мәгъфирәт һәм җәннәтне дә] бирде. Аллаһы игелек кылучыларны сөя».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:148

Безнең тормышыбызда ялгыш юлда йөреп, кылган изгелеге сәбәпле һидаятькә күнгән кешеләр дә бар. Шуңа да изгелек кылучы кешеләргә «Аллаһының рәхмәте булсын» дип әйтергә кирәк. Безнең ихлас күңелдән

---

1 Игътибарлы булыгыз: сәҗдә аяте.

әйткән шушы сүзләребез сәбәпле, Аллаһының рәхмәте белән, бу кешеләр дингә килерләр. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җирдәгеләргә (кешеләргә, хайваннарга) мәрхәмәтле бул һәм күктәгеләр сиңа карата мәрхәмәтле булырлар», – дип әйткән.

Изгелекләребезнең азмы яки күпме икәнен белер өчен көн азагында үз-үзебезгә хисап бирергә өйрәник. Әгәр кеше көн дәвамында кылган изгелекләренең күплеген күрде икән, димәк, бу көнен юкка уздырмаган. Әгәр инде начар гамәлләренең күплеген аңласа, димәк, алдагы көннәрен күбрәк изгелекләр кылып уздырырга кирәк.

Раббыбыз тормышыбызны изгелек белән бизәп, безгә ике дөньяда да изгеләр сафында булырга насыйп кылсын. Әәмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*
*Саба районы имам-мөхтәсибенең*
*яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*
*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*29 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Ислам - мәрхәмәтлелек дине

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Ислам диненә бернинди катышы булмаган кайберәүләр, Ислам дине артына яшеренеп, төрле әшәкелекләр кылалар. Төрле юллар аша, гаепсез кешеләрнең гомерләрен куркыныч астына куялар, бик күп халыкның вафат булуына сәбәпче булалар. Бу коточкыч гамәлләрнең безнең динебезгә бернинди дә катнашы юк, чөнки Ислам диненең нигезендә мәрхәмәтлелек ята. Ислам сүзенең тамыры «сәлам» сүзеннән чыга, ягъни «тынычлык», «иминлек», «сәламәтлек», дигән мәгънәләрне бирә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

مِنْ أَجْلِ ذَٰلِكَ كَتَبْنَا عَلَىٰ بَنِي إِسْرَائِيلَ أَنَّهُ مَن قَتَلَ نَفْسًا بِغَيْرِ نَفْسٍ أَوْ فَسَادٍ فِي الْأَرْضِ فَكَأَنَّمَا قَتَلَ النَّاسَ جَمِيعًا وَمَنْ أَحْيَاهَا فَكَأَنَّمَا أَحْيَا النَّاسَ جَمِيعًا ۚ وَلَقَدْ جَاءَتْهُمْ رُسُلُنَا بِالْبَيِّنَاتِ ثُمَّ إِنَّ كَثِيرًا مِّنْهُم بَعْدَ ذَٰلِكَ فِي الْأَرْضِ لَمُسْرِفُونَ ﴿٣٢﴾

**«Шул [рәвешчә, Кабил Һабилне үтерүе] сәбәпле, Без [бу гөнаһны күп итеп кылган] Исраил улларына [бер хөкем буларак] әмер иттек: кем дә кем бер җан өчен [кыйсас ителү кебек хокуклы**

**очрак булмыйча] яки җирдә бозыклык [һәм юлбасарлык кебек үтерелүне кирәк кылган сәбәп] булмыйча, [нахакка] бер җанны үтерсә, гүя бөтен кешене дә үтергән кебек булыр. [Берәүнең үтерелүенә комачау итеп һәм аны куркынычлардан коткарып, аның гомерен саклап калуга сәбәп булу белән] Кем дә кем аны терелтсә, гүя бөтен кешеләрне терелткән кебек булыр. [Исраил уллары хакында бу хөкемне язганыбыздан соң] Расүлләребез аларга [бу җинаятьләрдән ерак торсыннар өчен] ап-ачык дәлилләр китергән иде, ләкин [шулкадәр дәлилләр килүгә карамастан] моннан соң араларыннан бик күбесе җирдә [бозыклык чыгару һәм кеше үтерү гөнаһларында] чиктән чыкты».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:32

Имам Бохари хәдисләр җыентыгында түбәндәге хәдис китерелә: Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бер кеше мөселманнар белән килешү төзегән мөселман булмаган кешенең гомерен өзсә, 40 еллык аралыкка таралган җәннәтнең хуш исен дә татымас», – дип әйткән.

Димәк, моннан шундый нәтиҗә чыгарырга була: кеше үтерү – ул олы гөнаһлардан санала. Хайбәр сугышында пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм, байракны үзенең кияве Гали радыяллаһу ганһегә тоттырганда, шундый сүзләрне әйтә: «Аллаһы белән ант итәм, әгәр синең аша бер кеше һидаять юлына басса, ул синең өчен кызыл малларга караганда да яхшырак булыр». Гарәпләрдә исә дөя бик бәяләнә, чөнки ул чүлдә күп төрле хезмәтне башкара һәм файда китерә ала. Кызыл мал, зурлыгы һәм чыдамлылыгы ягыннан башка маллар белән чагыштырганда, иң кыйммәтлеләрдән санала. Монда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм нәрсәне әйтергә теләде соң? Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм һич кенә дә кешеләрне үтерергә һәм аларның байлыгына ия булырга теләмәде. Кешеләрнең һидаятькә ирешүләре, иманга килүләре, бәхетле булулары һәм җәннәткә керүләре – аның чын максаты иде.

Дөрестән дә, һәрбер кешенең күңеле яктылыкка, дөреслеккә, гаделлеккә, пакьлеккә омтыла. Шулай ук, бөтенебез дә диярлек Ислам диненен тиз арада таралуын телибез. Ләкин һәрнәрсәнең тәртибе бар: спорт белән шөгыльләнергә теләгән кешегә остазы элек 5 кг күтәрергә куша, аннары акрын гына авырлыкны күбәйтә. Мәктәпне дә бер ел эчендә тәмамламадык бит. Аллаһы Тәгалә җирләрне, күкләрне һәм алар арасында булган барча мәхлүкатларны 6 көн эчендә бар итте. Коръәни Кәрим китабы 23 ел дәвамында иңгән. Раббыбызның дөньяны бар итәргә һәм Коръән китабын бер секунд эчендә иңдерергә кодрәте җитмәс идеме? Һичшиксез, җитәр иде. Ә ни өчен шулай? Чөнки бу Аллаһының теләге. Аллаһы Тәгалә шулай акрын-акрын кешеләрнең йөрәкләре пакь булуын һәм дин тотарга әзер булуын теләде.

Безнең өчен Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм үрнәк булып тора. Мәккәдә 10 ел буена халыкны дингә өндәгәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһә һәм аны һәрвакыт яклаучы, әтисенең абыйсы Әбү Талиб вафат булалар. Бу елны «кайгы елы» дип атыйлар. Шуннан соң Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдән Таиф шәһәренә барырга уйлый. Мәккә белән Таиф арасы 90 чакрым була һәм һава торышы эссе булуына карамастан, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм җәяү бара. Ниһаять, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул шәһәргә барып җитә. Иң элек Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм кабиләнең олуглары белән күрешә һәм ни өчен алар янына килгәнен аңлатып, Ислам динен кабул итәргә тәкъдим ясый. Кабилә башлыклары Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне инкяр итәләр, мыскыллап көләләр һәм аны куып чыгаралар. Гарәпләрдә кунакчыллык сыйфаты иң югары дәрәҗәдә булса да, алар Пәйгамбәрне кабул итмиләр, ял иттермиләр, су эчертмиләр, ашатмыйлар, киресенчә, аны куып чыгаралар. Моның белән чикләнмичә, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне

таш белән «озаталар», шуның аркасында аның хәтта аяк киемнәре кан белән тула. Шуннан соң Пәйгамбәребез хәлсезләнеп, агачка таянып, дога кыла. Бу вакытта Җәбраил белән тау фәрештәсе галәйһимуссәлам килеп Пәйгамбәребезгә: «Аллаһы синең догаңны ишетте, сиңа сәлам тапшырды, безне синең яныңа җибәрде, әгәр теләсәң Таиф шәһәрен җир белән тигезлибез», – дип әйтәләр. Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм шундый авыр хәлдә булса да, йөрәгендә бернинди дә ачу, үч алу хисе булмый. Киресенчә, фәрештәләргә: «Аллаһы мине кешеләрне газаплар өчен түгел, ә барлык дөньяга рәхмәт буларак җибәрде», – дип әйтә. Расүли Әкрам саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең йөрәгендә Раббыбызга карата Таиф кешеләре барыбер Ислам динен кабул итәрләр дигән ышану һәм Аның рәхмәтенә өмете була. Менә шушы вакыйгага карап, татарларда шундый мәкаль чыккан: «Таш атканга, аш белән кайтар».

Ни өчен кешеләр хәзер төрле агымнарга, фиркаларга яки ялгыш юлга керәләр? Чөнки алар Ислам динен белмәгән төрле-төрле кешеләрдән яки интернеттагы тикшерелмәгән сайтлардан гына алып өйрәнәләр. Әмма иң дөресе – башта мәчеткә барырга, имам белән танышып, аның белән сөйләшергә һәм киңәшләшергә кирәк, чөнки имам – бөтен яхшы эшләрдә алда, башкаларга үрнәк, адашканнарны туры юлдан алып баручы, караңгыда – яктыртучы, яхшылыкның таралуына сәбәпче, киңәшче, авыр хәлгә калганнарга чыгу юлын күрсәтүче, йөрәгендә хаста булганнарга «рухи табиб», халыкны берләштерүче, хикмәт иясе. Татарстан буенча «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге», «Мөхәммәдия» мәдрәсәләре, Рәсәй Ислам Университеты, Болгар Ислам Академиясе һәм тагын күп мәдрәсәләр бар. Динне дөрес чыганаклардан, дөрес укытучылардан өйрәнергә теләгән кешегә шушы санап чыккан уку йортларына кереп укырга була.

Шулай ук безнең әби-бабайларыбыздан калган гореф-гадәтләрне дә, татар-мөселман дөньясындагы күп кенә галимнәребезне дә өйрәнергә

кирәк. Шулар арасында Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Галимҗан Баруди, Сөнгатулла Бикбулат, Габдрәхим Утыз Имәни Әл-Болгари бар. Алардан калган китаплардан без гыйлем, хикмәт, гыйбрәт, тәҗрибә алып, Аллаһы боерган булса, дөрес юл буенча барачакбыз.

Иң элек үзебездән, аннары гаиләдән, балаларыбыздан, туганнарыбыздан башларга кирәк.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ибраһим хәзрәт Шаһимәрдәнов,*
*Питрәч районы, Көек авылы мәчете имам-хатыйбы,*
*«ТҖ МДНнең Дәгъват бүлеге белгече*

*5 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Раҗәб аеның фазыйләтләре

Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы исеме белән башлыйм.

Аллаһы Тәгалә вакытны бер дә туктап тормый, һәрвакыт хәрәкәттә булган берәмлек итеп яраткан. Көн артыннан көн килеп, айлар елларга әйләнеп, вакыт уза, дәверләр кичелә, заманнар үзгәрә. Менә тагын бер фазыйләтләргә бай ай – раҗәб ае ишек шакый. Шул айның өстенлекләрен искә төшереп узыйк.

Һәрвакыт белем алып тору, белгәнне искә төшерү – мөселманның асыл сыйфатыдыр. Раббыбыз Аллаһы Үзенең Изге Китабында болай дигән:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ ۗ إِنَّمَا يَتَذَكَّرُ أُولُو الْأَلْبَابِ ﴿٩﴾

**«Әйт: «[Исламны] Белгән [һәм белгәне белән яшәгән] кешеләр белән [хакны] белмәгән [шул сәбәпле, наданнарча эш йөрткән һәм адашу эчендә югалып калган] кешеләр тиң була аламы? Аек акылларга ия кешеләр генә үгетләнә».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:9

Әйдәгез, Ислам динебезне яхшы белүче һәм белгәннәребез белән гамәл кылучылар рәтеннән булыйк, җәмәгать!

Билгеле ки, раҗәб, шәгъбан һәм Рамазан айлары изге айлардан санала. Алдагы икесе Рамазан аена әзерлек – үз-үзеңне рухи һәм физик яктан чыныгуга, чистарынуга, үзгәрүгә әзерлек вакыты булып тора. Раҗәб ае җиттеме, димәк, изге Рамазан аена бер адым тагын да якынлаштык дигән сүз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Раҗәб ае башка айлардан, Коръән кеше сүзеннән

өстен булган кебек, аерылып тора. Шәгъбан аеның өстенлеге исә минем башка илчеләрдән өстенрәк торуыма тиң. Ә Рамазан аеның өстенлеге – Аллаһының үз мәхлүкъларыннан өстен булуы кебек үк».

Раҗәб ае – ярлыкау һәм мәрхәмәткә ирешү ае ул. Раҗәб «Әр-Руҗүб» сүзеннән барлыкка килгән. «Әр-Руҗүб» – «бөекләү, олылау» мәгънәсенә ия. Сүзнең тамыры «тәраҗиб» сүзенә барып тоташа, мәгънәсе – «ихтирам-хөрмәт».

Раҗәб ае һиҗри буенча мөселман ай календаренең җиденче ае, ул харам айлар рәтенә керә. Әбү Бәкрат радыяллаһу ганһедән риваять кылына: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Бер ел унике айдан гыйбарәт, шуларның дүртесе харам айлары, ә аларның өчесе рәттән килә – зөлкагъдә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррам, ә «раҗәб мүзарә» җөмәдәл-ахыр һәм шәгъбан арасында» (Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Ни өчен хәдистә раҗәб ае «раҗәб мүзарә» дип аталган? Бу исә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселендәге бер Мүзарә исемле кешенең исеме белән бәйле. Шушы кешенең кавеме раҗәб аеның вакытын күчерми торган була, башка гарәп кавемнәре, сугышны туктатып тормас өчен, раҗәб аен кичектереп тора торган булалар.

Раҗәб аеның харам айлар рәтенә керүе хакында Изге Коръәндә ачык дәлил бар:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге [катгый карарын белдергән] язуында [Ләүхүл-Мәхфүздә] – унике. Шуларның дүртесе – харам [айлар]. Бу – [рәвешле елның унике ай булып, шуларның дүртесенең харам кылынуы турындагы хөкем**

**Ибраһим һәм Исмәгыйльдән [галәйһимуссәлам] калган] хак дин. [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] Боларда [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] үз-үзегезгә золым итмәгез».**

«Әт-Тәүбә», 9:36

Харам айлар дип аталган вакыт аралыгында, дошман явызлык күрсәтмәсә, сугыш алып бару тыела. Үз-үзеңне якларга гына рөхсәт ителә. Югарыда китерелгән аятьтә исә бу айларда гөнаһлардан тыелуга аерым басым ясала, чөнки гөнаһның авырлыгы арта төшә, ягъни кешенең үз-үзенә салган золымының куәте-зурлыгы арта. Шулай ук изге гамәлләрнең савабы да бермә-бер зурая.

Ислам тарихы сәхифәләрен барласак, раҗәб ае нинди вакыйгаларга бай икән соң?

Беренчедән, иң зур вакыйгаларның берсе – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе хәзрәти Габдулла һәм әнисе хәзрәти Әминә бу айда никахлашып кавыша. Раҗәб аеның беренче җомгасы төнен зурлап «Рәгаиб кичәсе» дип йөртәләр. Бу төндә кылынган догалар кабул ителә, гөнаһлар кичерелә.

Икенчедән, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдәге Әл-Харам мәчетеннән Кодес (Иерусалим) җирендәге Әл-Әкъса мәчетенә күчеш ясый һәм Аллаһы янына күтәрелә. Бу вакыйга «Әл-Исра вәл Мигъраҗ» дип атала. Ул раҗәб аеның 27 нче төне дип исәпләнә. Мигъраҗ вакыйгасы – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһы тарафыннан бүләк ителгән могҗизаларның берсе булып тора. Нәкъ менә Мигъраҗ вакытында Галәмнәрнең Раббысы Үзенең колларына биш вакыт намазны фарыз итеп йөкли. Бу хакта бер риваятьтә Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе болай дигән: «Мигъраҗ төнендә Аллаһының Расүленә илле тапкыр намаз укырга йөкләнелде. Соңыннан аңа: «Әй Мөхәммәд! Шиксез, безнең сүзебез үзгәрмәс. Синең өммәтеңә йөкләнгән биш тапкыр кылына-

чак намаз савабы буенча илле тапкыр укылган намазга тиң булыр», – дип әйтелде (Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан). Икенче бер хәдистә шулай ук әлеге вакыйганың фазыйләтләре ассызыклана: «Мигъраҗ вакытында Аллаһының рәхмәте буларак өч нәрсә бүләк ителде: биш вакыт намаз, «Әл-Бәкара» сүрәсенең соңгы аятьләре һәм күп илаһларга табынучы булмаганнарга гафу кылыну мөмкинлегенең барлыгы» (Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Аллаһының Расүле үзенә кадәр җиргә хакыйкатьне җиткерүчеләр булып җибәрелгән Ибраһим, Муса, Гайсә, Идрис, Йосыф галәйһимуссәлам кебек пәйгамбәрләр белән күрешә. Мигъраҗ вакыйгасы Коръәндә болай дип сүрәтләнә:

لَقَدْ رَأَىٰ مِنْ آيَاتِ رَبِّهِ الْكُبْرَىٰ ﴿١٨﴾

**«Ул Раббысының иң бөек аятьләреннән иң әһәмиятле бер өлешен [Мигъраҗ кичәсендә] күрде».**

«Ән-Нәҗм / Йолдыз», 53:18

Раҗәб аенда ураза тотарга ният кылсак, хәерле булыр. Билгеле ки, ураза тоту – Аллаһы һәм Аның колы арасында гына кала торган гыйбадәт төре. Нәкъ тә шуның өчен савабын да Аллаһы Тәгалә күпме бирергә теләсә, шуның кадәр билгелиячәк.

Бер хәдисендә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Раҗәб аенда ураза тотыгыз, чөнки бу айдагы ураза тоту Аллаһы тарафыннан аерым бер тәүбә буларак кабул ителә», – дип әйткән. Әгәр дә тулы бер ай ураза тоту мөмкинлеге юк икән, мәсәлән, кешенең сәламәтлегенә зыян килә яисә эше буенча мәшәкатьләре туа, бу очракта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм айның беренче, унбишенче һәм соңгы көннәрендә ураза тотарга киңәш иткән. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Исегездә тотыгыз: раҗәб – Аллаһы Тәгаләнең ае, бу айда берәрегез бер көн генә булса да ураза тотса, Аллаһы аннан разый булыр,» – дип хәбәр иткән.

Шулай ук Әбү Давыдтан китерелә торган сахих хәдистә болай дип әйтелгән: «...харам айларда ураза тот һәм авыз ач, харам айларда ураза тот һәм авыз ач, харам айларда ураза тот һәм авыз ач...». Күргәнегезчә, Аллаһының Расүле бер үк гыйбарәне өч тапкыр рәттән кабатлый: бу әлеге айларда ураза тотуның никадәр әһәмиятле һәм саваплы булуына ныклы дәлил, мөселман өммәтенә катгый киңәш.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әлхәмдүлилләһ, без янәдән, инде менә гомеребездә ничәнче кат Рамазан аена якынлашабыз. ИншәАллаһ, без исән-имин аңа бер халәттә кереп, икенче халәттә чыгарбыз. Хәзер исә без юлыбызның беренче баскычында – раҗәб аенда басып торабыз. Рамазан аен күңелебезгә бөтен фазыйләтләре белән кунакка кертергә телибез икән, бүгеннән үк әзерлек эшләрен алып барыйк: ураза тотыйк һәм авыз ачыйк, сугышлардан гына түгел, ә вак-төяк ызгыш-талашлардан, низаглардан тыелып торыйк, көнебезне Изге Коръән сүрәләрен уку белән бизик, гөнаһлардан тыелыйк һәм игелекле гамәлләрне тагын да арттырыйк.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ирек хәзрәт Нуриев,*

*«Менделеев» районы имам-мөхтәсибе*

*12 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 30 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Рәгаиб кичәсе

Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Расүле, ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барча мактау-хәмедләребез булсын. Әлхәмдүлилләһ, Аллаһы Тәгалә безгә бу көнне дә кояш нурын күрергә, саф һавасын суларга, кардәшләребез белән җылы, якты мәчетендә җәмәгать намазына җыелырга насыйп итте. Бүген без Исламда аерым урын алып торган изге кичәләрнең берсе – Рәгаиб кичәсе турында сөйләшербез.

Рәгаиб сүзе гарәп телендәге «рагәбә» сүзеннән барлыкка килә. Бу сүз нәрсәне дә булса теләргә, нәрсәне дә булса булдыру өчен көч куярга мәгънәсенә ия.

Рәгаиб кичәсе изге айлардан санала торган раҗәб аеның беренче җомга төненә туры килә. Билгеле ки, раҗәб ае фазыйләтләргә бик бай. Исебезгә төшерсәк, бу айда гөнаһлардан тыелу сорала, чөнки гөнаһларның авырлыгы, кешенең алар аркасында үз-үзенә китергән золымы арта. Шулай ук, бу айда дошман беренче булып сугыш ачмаса, сугышларны туктатып тору мәҗбүри. Нәкъ тә шушы сәбәпләр аркасында раҗәб аен харам ае, ягъни тыелу ае дип атыйлар. Ә менә игелекле гамәлләрне арттыру – ул савапларны бермә-бер арттыру дигән сүз.

Раҗәб аенда Ислам тарихында тирән эз калдырган ике зур вакыйга була. Шуларның берсе – Пәйгамбәребезнең Мәккәдәге Әл-Харам мәчетеннән Иерусалим җирендәге Әл-Әкъса мәчетенә күчеше һәм Аллаһы янына күтәрелүе – Мигъраҗ булса, икенчесе – Аллаһы Расүленең әтисе хәзрәти Габдулла белән әнисе хәзрәти Әминәнең кавышуы. Шушы

кавышу нәтиҗәсендә, Аллаһының рәхмәте булып, ахырзаман Пәйгамбәре дөньяга килә. Аның яралуы да шушы Рәгаиб төненә карый.

Рәгаиб кичәсе елга бер генә килә, ә нигъмәтләре чиксез, шуңа күрә бу нигъмәтләрне җыеп өлгерергә ашыгу кирәк. Бу төнне гыйбадәттә – намазда, зикердә, Коръән укуда, тәүбә итүдә, дога кылуда уздыру инсанга бетмәс-төкәнмәс әҗер-савап китерер. Алдагы пәнҗешәмбе көнне ураза тоту хәерле саналыр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Раҗәб аеның беренче, унбишенче һәм соңгы көнендә ураза тот, бер ай ураза тоткан кебек савап алырсың, чөнки Аллаһының рәхмәте ун тапкыр арттырыла. Шулай ук раҗәб аеның беренче җомгасы төне хакында да онытма».

Бу кичәне максималь дәрәҗәдә саваплар җыеп уздыру өчен берничә киңәш бар:

– тәүбә кылып, Аллаһыдан гафу сорап, догалар кылу;

– ярлы һәм мохтаҗ кешеләргә садака тарату;

– балаларга аеруча игътибарлы булу: бүләкләр бирү, вакытыгызны күбрәк алар белән үткәрү;

– туганлык җепләрен ныгыту, бигрәк тә әти-әниләрнең хәлен белү, якын туганнар белән кунакка йөрешү;

– калдырылган фарыз намазларны каза кылу;

– Аллаһыны зикер кылу, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтү;

– тәүбә намазын, шулай ук башка төрле нәфел намазларын уку;

– онытылып барган бурычларны кире кайтару.

Кардәшем, исеңдә тот: Аллаһы кешелеккә бүләк иткән Коръән һәм Сөннәттә бер генә кирәкмәгән гамәл дә юк. Һәрнәрсә кешенең үз-үзен танып белүгә, кыйбласын табуга, Раббыбыз, Пәйгамбәребез һәм башка кешеләр (гаилә әгъзалары, туганнар, дуслар) белән дөрес мөгамәлә кылуга ярдәм итүгә хезмәт итә. Раҗәб аендагы изге Рәгаиб кичәсе дә шушы

озын чылбырның бер төймәсе. Бу кичәне олы чакрымнарга чапканда хәл алу, алдыңны-артыңны күзәтү, юлым дөрес микән, дип бәя бирү өчен туктап калуга тиңләп була. Бу көнне күбрәк тәүбә, дога һәм игелекле гамәлләр белән тутырырга кирәк. Алдагы юлыбыз җил-буransсыз, тигез-такыр булсын дисәк, «хәл алу» бик мөһим. Ә барасы юлыбызда шактый көч-куәт кирәк булачак, чөнки раҗәб аеннан соң шәгъбан, ә шәгъбаннан соң Рамазан ае киләчәк. Фарыз уразабызны ни дәрәҗәдә сыйфатлы тотачакбыз, изге айны никадәр изгелекләр белән тутырачакбыз – болар барысы да безнең рухи һәм физик сәламәтлегебездән тора. Аллаһы Тәгалә әзерләгән баскычлардан югары дәрәҗәдә атлап, иң олуг бүләгенә – Фирдәвес җәннәтендә очрашуга лаек булсак иде. Әәмин!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ирек хәзрәт Нуриев,*

*«Менделеев» районы имам-мөхтәсибе*

*19 февраль вәгазе,*

*Раҗәб аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Пәйгамбәребезнең ир-атларга киңәшләре

Барча галәмнәрнең Раббысы, Тәрбиячесе, Яратучысы булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез ирешсен. Шулай ук йөрәкләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез, юлбашчыбыз, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ирешсен. Хөрмәтле мөселманнар, шушы изге җомга көне белән сезне тәбрик итәм. Аллаһы Тәгалә барчагызга да күңелләрегездәге изге ният, морад-максатларыгызга ирешергә насыйп әйләсен.

Аллаһы Раббыбыз җир йөзенә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне ни өчен җибәргән? Максаты нидә? Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин сезгә күркәм әдәп-әхлакны җиткерер өчен иңдерелдем», – дип әйткән. Ә ни өчен әдәпле, күркәм холыклы булырга кирәк соң? Әлбәттә, беренче чиратта, башка җан ияләренә золым кылмас, аларның хакына кермәс өчен. Шулай ук, фарыз гамәлләр буларак, өстебезгә намаз, ураза, зәкят, хаҗ гамәлләре йөкләнелде. Ни өчен? Раббыбызның ризалыгына ирешер, нәфесебезне тәрбияләр өчен.

Бу һәр мөселманның өстендә булган вазифаларыдыр, һәм алар ир-ат яки хатын булуга, яшь-карт буынга бүленми. Ләкин гаиләгә килгәндә, ир кешенең үз вазифалары, хатын-кызның – үзенеке. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сезнең иң күркәмегез, иң яхшыгыз, үз гаиләсәсенә иң хәерле булганыгыз», – дип әйтеп калдырган.

Хөрмәтле мөселманнар, гаилә башлыклары, әтиләр. Кодси хәдистә: «Намаз кабул ителүнең шартлары: тәкәббер булмау, гөнаһларда дәвамлы

булмау, Аллаһының бөеклеген тану, вә рәхимле булу», – дип килә. Ошбу шартлар үтәлмәсә, намаз кабул ителүе дә шикледер. Киләсе хәдистә: Иң хәерлегез – үз хатыннарына иң күркәм булганыгыз», – диелгән. Шулай ук Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кыямәт көнендә иң күркәм холыклы булганнарыгыз миңа якын булырлар», – дип әйткән.

Ошбу хәдисләрдән нинди нәтиҗә ясап була? Әгәр үз холкыбызны тәрбияләсәк, иншәАллаһ, без бар җирдә дә уңышка ирешәчәкбез. Аллаһы каршында да, Пәйгамбәребез каршында да, гаиләбез каршында да сөекле бәндәләр булачакбыз.

Шундый бер мәсьәлә турында сөйләшеп китәсе килә: кайбер кешеләр гыйбадәткә генә бирелеп, ошбу дөньядагы вазифаларын калдыра башлый. Андыйларның гаиләсенә, якыннарына мөнәсәбәте суына. Ә кайберләре, киресенчә, дөнья куа башлый, намазларын калдыра, Ахирәткә карата мөнәсәбәтен суыта. Күркәм холык дигән нәрсә – ул бу дөньяга да, Ахирәткә дә уңай мөнәсәбәттә булу дигәнне аңлата. Ягъни күркәм холыкка ирешкән кеше Аллаһы Тәгалә белән дә элемтәне өзми, гаиләсе белән дә күркәм мөнәсәбәттә була, туганлык вә дуслык җепләрен дә өзми. Менә шушы була да инде ул күркәм холык.

Мөхтәрәм дин кардәшләр, ир-ат – ул өйдә баш кеше, әмма бу әмер биреп кенә утыручы дигәнне аңлатмый. Ир – ул күркәм холык илә ихтирамлы булу. «Мин әйткәнне эшләргә кирәк», – дип йодрык белән сугып, хатынын вә балаларын куркытучы бу сыйфатка туры килми. Киресенчә, ир-атның күркәмлеге аркасында хатыны да, балалары да аны яратырлар, хөрмәт итәрләр һәм, ул нинди дә булса эшләр кушмаса да, ул теләгәнчә эшләрләр.

Аннан соң, хөрмәтле дуслар, безнең тагын бер йомшак ягыбыз бар: без хатыннарыбызга карата матур сүзләрне кызганабыз. Бу бик күркәм гамәл түгел бит. Йөрәктәге тормыш иптәшеңә булган матур уйлар телдә дә чагылырга тиеш. Без әйтмәсәк, кем әйтер?

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَعَاشِرُوهُنَّ بِالْمَعْرُوفِ ۚ فَإِن كَرِهْتُمُوهُنَّ فَعَسَىٰ أَن تَكْرَهُوا شَيْئًا وَيَجْعَلَ اللَّهُ فِيهِ خَيْرًا كَثِيرًا ﴿١٩﴾

**«Алар белән күркәм [мөнәсәбәтләрне саклап] яшәгез [аларга карата инсафлы булыгыз һәм матур сөйләшегез]. Әгәр аларны өнәмәсәгез, [янә дә сабыр итегез] [чөнки] сезгә, бәлки, нәрсәдер ошамыйдыр, әмма Аллаһ шуңа да бик күп хәер тәкъдир иткән [булуы мөмкин, тик сез генә моны белә алмыйсыз].**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:19

Бу мөгамәлә өчен бик мөһим чара. Пәйгамбәребез дә үз хатыннарына матур сүзләр белән генә дәшкән, алар белән шаярта торган булган, хөрмәт иткән, үз гомерендә бер тапкыр да хатыннарына тавыш күтәрмәгән, ачуланса, дәшми торган булган.

Шулай ук, күркәм холыклы булу – ул «Әссәләмү галәйкүм» белән «Вә галәйкүм әссәләм» генә түгел. Елмаеп, хәлләрне сорашу гына да түгел. Әмма гаиләләребездә анысын да күбебез үтәми дип әйтерлек. Дин – ул мөнәсәбәт, дин кардәшләрем. Әгәр мөнәсәбәтләребезне күркәм кылмасак, динебез үк күркәм түгел дигән сүз. Ә алай булса, балаларыбыз әдәп-тәртипкә кемнән өйрәнер? Без хөрмәт итмәсәк, безне хөрмәт итмәсәләр, алар ничек хөрмәт итсен вә ителсен ди.

Гади генә мисал, кешенең үз туган иленә, туган теленә хөрмәт булмаса, «Нәрсәгә инде ул, хәзер инглиз теле модада бит», – дип йөрсәк, әлбәттә, моның нәтиҗәсе дә аяныч булыр. Үзен, үз телен хөрмәт итмәгән кешене кем хөрмәтләсен? Пәйгамбәребез дә үз телен, үз илен бик сөйгән, хөрмәт иткән. Моңа аның тормыш юлыннан да бик күп дәлилләр бар. Шулай бит? Шуңа да, үз өстебездә эшлик, күркәм холык иясе булуга омты-

лыйк, без үзгәрмәсәк, безнең киләчәгебез үзгәрми, яхшырмый. Бәрәңге утыртып, карбыз үсеп чыгар дип көтү – акылсызлык.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَابْتَغِ فِيمَا آتَاكَ اللَّهُ الدَّارَ الْآخِرَةَ ۖ وَلَا تَنسَ نَصِيبَكَ مِنَ الدُّنْيَا ۖ وَأَحْسِن كَمَا أَحْسَنَ اللَّهُ إِلَيْكَ ۖ وَلَا تَبْغِ الْفَسَادَ فِي الْأَرْضِ ۖ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ الْمُفْسِدِينَ ﴿٧٧﴾

**«Аллаһы сиңа биргән [хәзинәләр һәм киң мөмкинлекләр тулы] нәрсәләрдә соңгы йортны [аның савапларын] эзлә. Дөньяңнан да насыйбыңны онытма! Аллаһы сиңа [моның кадәр нигъмәтләр биреп] игелек кылганы кебек, син дә [Аллаһының колларына] игелек кыл. Җирдә бозыклык [һәм золым чыгару юлларын] эзләмә. Һичшиксез, Аллаһы бозыклык чыгаручыларны сөйми».**

«Әл-Касас / Кыйсса», 28:77

Шушы аятьләргә тугры булыйк, ир-ат вазифаларыбызны үтик, халкыбызны яхшыртыйк, иншәАллаһ, бәхетле булырбыз.

Аллаһы Раббыбыз ошбу вәгазьләребездән разый булып, файдаланырга насыйп итсен. Күңелләребездәге барча начар сыйфатлардан арынырга насыйп әйләсен. Әәмин!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып

яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Динар Зыятдинов,*
*«Азан» радиосы редакторы*

*26 февраль вәгазе,*

*Ражәб аенынң 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Шәгъбан аенынң фазыйләтләре

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмед-сәналәребез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Мөхәммәд бине Габдулла – Аллаһыныӊ хак расүле, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифләрен бирсә иде.

Шәгъбан аеның унбишенче көнендә, Мәдинәи Мөнәүвәрәнең «Бәни Сәләмә» мәчетендә Расүлуллаһ саллəллаһу галәйһи вә сәлләм өйлә намазы фарызының ике рәкәгатен укып торган вакытында вәхи иңгән: Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм намазда торган хәлендә кирегә Кәгъбә тарафына борылган. Бу халәтне күргән сәхабәләр дә аңа ияреп намазны дәвам иттергәннәр.

Коръәни Кәримдә Хак Тәгалә болай дип әйтә:

قَدْ نَرَىٰ تَقَلُّبَ وَجْهِكَ فِي السَّمَاءِ ۖ فَلَنُوَلِّيَنَّكَ قِبْلَةً تَرْضَاهَا ۚ فَوَلِّ وَجْهَكَ شَطْرَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ ۚ وَحَيْثُ مَا كُنتُمْ فَوَلُّوا وُجُوهَكُمْ شَطْرَهُ ۗ وَإِنَّ الَّذِينَ أُوتُوا الْكِتَابَ لَيَعْلَمُونَ أَنَّهُ الْحَقُّ مِن رَّبِّهِمْ ۗ وَمَا اللَّهُ بِغَافِلٍ عَمَّا يَعْمَلُونَ ﴿١٤٤﴾

**«[Ий Расүлем!] Без [кыйбланың Кәгъбәгә кайтарылуы хакында вәхи иңгәнен көтеп] синең йөзеңнең күккә юнәлгәнен күрәбез. Инде хәзер сине, һичшиксез, үзең риза булган кыйблага борабыз. [Моннан соң намаз укыганда] Син йөзеңне Харам мәчете тарафына юнәлт! [Ий кешеләр!] Кайда гына булсагыз**

**да, йөзләрегезне шул тарафка юнәлтегез. Һичшиксез, китап әһелләре [булган яһүдиләр һәм насаралар] моның Раббыларыннан [килгән] бер хак икәнен бик яхшы беләләр. Аллаһы аларның ни кылганнарыннан гафил түгел. [Шул сәбәпле, Ул аларны үзләре лаек булган җәзага тартачак].**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:144

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Раҗәб ае – Аллаһы Тәгаләнеке, шәгъбан – минем ай, Рамазан ае – минем өммәтемнеке. шәгъбан – гөнаһларга кәффарәт була торган ай, ә Рамазан ае – гөнаһлардан пакьләнә торган ай», – дип әйткән.

Бу айда шәфкать капкалары ачыла, һәрнәрсәнең дә бәрәкәте арта, безнең көндәлек тормышыбызда белеп яки белмичә ясала торган хаталар кими, гөнаһлар гафу ителә. Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күп салаватлар әйтелә торган ай.

Шулай итеп, мөселманнарга тәүбәгә килеп, гөнаһлардан арынып һәм дә инде гафиллектән уянып, Рамазан аена хәзерләнү кирәк. Бу ай – Пәйгамбәрез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ае булу сәбәпле, Аллаһы Тәгаләдән белеп һәм белмичә эшләгән гөнаһлар өчен гафу-истигъфар сорап, Аңа якынлашу хәерле гамәлләрдән санала.

Мөселман булган бәндә бу файдалы эшләрне кичектерергә яисә иң куркынычы, бөтенләй дә калдырырга тиеш түгел, чөнки адәм баласының тормышы өч көннән тора: беренчесе – узган, гыйбрәт алыначак көн; икенчесе – бүгенге көн, ганимәт көне. Өченчесе – иртәгә яки киләчәк. Адәм баласы ул көнне күрә аламы? Анысы Аллаһы Тәгаләгә мәгълүм. Бу айга керә алабызмы, юкмы – моны безгә кем әйтә ала? Билгеле, беркем дә хәбәр бирә алмый. Раҗәб ае узып китте, киредән кайтмый, Рамазан ае киләчәктә, аны күрү-күрмәвебез билгесез, ә шәгъбан ае исә бу ике ай арасында бер күпер булып тора. Шуңа күрә дә бу айда гыйбадәттә булу, адәм баласы өчен иң мөһим эшләрдән булып тора.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَرَبُّكَ يَخْلُقُ مَا يَشَاءُ وَيَخْتَارُ ۗ مَا كَانَ لَهُمُ الْخِيَرَةُ ۚ سُبْحَانَ اللَّهِ وَتَعَالَىٰ عَمَّا يُشْرِكُونَ ﴿٦٨﴾

**«Синең Раббың теләгәнен бар кыла һәм [теләгәнен] сайлый. Аларда исә сайлау [хакы] юк. Аллаһы [һәртөрле кимчелекләрдән] пакь! Ул алар Аңа ширек кушкан нәрсәләрдән өстен».**

«Касас / Хикәя», 28:68

Раббыбыз Үзенең коллары өчен бары тик иң изге, яхшы, файдалы һәм гүзәл нигъмәтләрне генә сайлап алып бирә.

Ул һәрнәрсәдән дә дүртне сайлап алып, соңыннан шулар арасыннан берсен якынайтып, дәрәҗәсен күтәрә. Мәсәлән: фәрештәләрдән – Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Газраилне сайлап алып, Җәбраил галәйһиссәламне иң олугы итеп куя. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә пәйгамбәрлек вазифасын үтәү вакыты җиткәч, Үз сүзләрен җиткерер өчен Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештәне арадашчы итеп сайлый. Шуннан соң Җәбраил галәйһиссәлам аять-аять егерме өч ел дәверендә Раббыбыз сүзләрен җиткереп тора.

Кичәләрдән – Бәраәт, Гарәфә, Җомга һәм Бәйрәм кичәләрен аерып ала. Аллаһы Тәгалә каршында Кадер кичәсе башкаларга караганда югары урын алып тора.

Таулардан – Өхед, Сина, Зәйтүн һәм Любнан таулары арасыннан Сина тавы дәрәҗәлерәк.

Изге урыннардан – Мәккә, Мәдинә, Бәйт Әл-Мокаддәс һәм Мәшгәрул Харам (Гарәфәт белән Мина таулары арасындагы урын) мөселманнар өчен бик кадерле. Ләкин шулардан инде Мәккәи Мөкәррәмә җирлеген Раббыбыз аеруча кадерле итеп күрсәтә.

Мәчетләрдән – Харам, Мәдинә, Әкъса һәм Сина тавы мәчетен аерып алып, Харам мәчетенең дәрәҗәсе бүтән мәчетләргә караганда югарырак булып санала. Елгалардан – Сырдәрья, Амударья, Фөрат һәм Нилны сайлап алып, Фөратны дәрәҗәлерәк иткән.

Айларга килгәндә, алар да дүртәү: раҗәб, шәгъбан, Рамазан һәм мөхәррам. Аллаһы Тәгалә барысына караганда да шәгъбанны аерып алып, аны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ае итеп билгеле. Шулай итеп Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм башка пәйгамбәрләргә караганда өстен булган кебек, шәгъбан ае да башка айларга караганда өстенрәк.

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисендә болай дип әйтә: «Раҗәб аеның өстенлеге, Коръән Кәримнең башка китапларга карата булган өстенлеге кебек. Шәгъбанның башка айлардан өстенлеге: минем җир өстенә килеп киткән барлык пәйгамбәрләр белән чагыштыргандагы өстенлегем кебек. Ә Рамазан аеның өстенлеге: Аллаһы Тәгаләнең мәхлүкатларына карата булган өстенлеге кебек».

Шәгъбан ае бәрәкәтле ай. Бу айда Аллаһы Тәгалә нигъмәт капкаларын ача һәм колларына чиксез рәхмәтен ирештерә. Шуңа күрә дә бу айда ваемсызлыктан аерылып, вакытны күбрәк догада һәм зикердә үткәрү хәерле булыр.

Раббыбызның рәхмәтенә һәм нигъмәтләренә ирешү өчен сәбәпче һәм дә бәрәкәткә бай булган айны гыйбадәттә уздыру хәерле эш булып тора. Бу айда башкарылган барлык яхшы эшләр 70 тапкыр арта һәм бернинди каршылыкларсыз күккә күтәрелә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәгъбан аенда бик күп ураза тоткан. Бервакыт бер сәхабә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Әй Пәйгамбәр, мин синең шәгъбаннан да күбрәк ураза тотканыңны күргәнем юк (Рамазан ае уразасы – фарыз, ә шәгъбан аенда

ураза фарыз түгел һәм ул һәркемнең үз ихтыярында, бу очракта Рамазаннан кала башка айлар да күздә тотыла). Моның сәбәбе нәрсәдә?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу айда барлык гамәлләр дә Аллаһының хозурына ирешә. Мин гамәлләремнең үзем уразалы вакытта ашуын телим», – дип җавап биргән. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Шәгъбән аена шундый исемнең бирелү сәбәбе шундадыр, бу вакытта ураза тотучыларга Раббылары тарафыннан күп изгелек була, чөнки тоткан уразаның әҗере агач ботаклары кебек тармаклана, ишәя. Бу инде җәннәткә керергә сәбәпче була», – дип безгә бу айның фазыйләтен аңлатып биргән.

Шәгъбан ае бик тә кыйммәтле һәм дәрәҗәле ай. Безнең сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ае булу сәбәпле, мөселман бәндәсенең теле һәм яшәгән һәр көне салаватлар белән зиннәтләнергә тиеш. Салаватлар әйтү, ул беренчедән – Аллаһы Раббыбызның әмерен үтәү булса, икенчедән – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм каршында булган хакны үтәү була. Салават ул, Аллаһыдан – рәхмәт, фәрештәләрдән – истигъфар һәм мөэминнәрдән – дога, дигән сүз. Салаватның иң кыскасы: Әллаһүммә салли галә Мүхәммәдин вә галә әәли Мүхәммәд.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

*5 март вәгазе,*

*Раҗәб аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Мигъраҗ кичәсе нәрсәгә өйрәтә?

Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә һәм сәхабәләренә салават һәм сәламнәребез булсын.

Раҗәб аеның 26 нчы көненнән 27 сенә каршы кичә Мигъраҗ кичәсе дип атала. Быел 2021 елда бу кичә 10 мартка туры килә. «Мигъраҗ» – күккә ашу дигән мәгънәне аңлата һәм бу кичә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең олуг могҗизаларыннан берсе булып тора. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһының кодрәте һәм рәхмәте белән гадәти булмаган бөек сәфәр кыла.

Корәндә бу хакта Раббыбыз Аллаһы болай дип әйтә:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١﴾

**«[Бер айлык юлны бер төн эчендә үтү, Бәйтел Мәкъдисне зиярат кылу, бөтен пәйгамбәрләрне тере килеш күрү, җиде кат күктә аларның урыннарында булу һәм Җәмалыбызны күрү кебек] Аятьләребездән кайберләрен күрсәтик дип, бер төнне [бик кыска бер вакытта Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә сәлләм)] колын Харам мәчетеннән [алып] Без тирә-ягын бәрәкәтле иткән Әкъса мәчетенә күчерүче [булган Аллаһы нindидер бер урында булудан һәм бөек Затына килешми торган төрле**

**түбән сыйфатлардан ерак һәм бөтен] кимчелекләрдән пакъ. Һичшиксез, Ул – [һәрнәрсәне] Ишетүче, Күрүче».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:1

Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәи-Мөкәррәмә шәһәрендәге Харам мәчете, ягъни Кәгъбәтулла диварына таянып утырганда, йокы һәм уяулык арасында булганда, Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам Борак дип аталган хайван белән килә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Борак белән яшен тизлегендә Харам мәчетеннән Кодес шәһәрендәге Әл-Әкъса мәчетенә (Ерак мәчеткә) күчә. Шунда ул башка пәйгамбәрләргә имам булып, алгы сафта намаз укый. Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең башка пәйгамбәрләрдән өстен булуын күрсәтә. Соңрак Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ике савыт китереп куялар: аларның беренчесендә – сөт, икенчесендә – шәраб (хәмер) була. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөт салынган савытны сайлый. Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам Пәйгамбәребезнең сайлавын күргәч: «Сине пәйгамбәр итеп җибәргән Аллаһыга мактау булсын. Әгәр син хәмер салынган савытны сайлаган булсаң, өммәтең саташыр иде», – дип әйтә.[1] Сөтнең ак төстә булуы дөреслек, иминлек билгесе булып тора.

Имам Бохари хәдисләр җыентыгында хәбәр ителгәнчә, пәйгамбәребез Мөхәммәд Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам белән күккә күтәрелә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм, җиде кат күк аша үткәндә, күкнең һәр капусында үзенә кадәр җир йөзенә килеп киткән пәйгамбәрләр белән күрешә. Алар барысы да Пәйгамбәребезне сәламлиләр.

Пәйгамбәрләр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең киләсен белеп тордылар. Алар белән очрашканда, Мөхәммәд

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрбер күктә фәрештәләрнең аерым-аерым гамәлләрен күрде. Кайбер фәрештәләр фәкать сәҗдәдә генә, икенчеләре – рөкүгъта гына, өченчеләре – кыямда, башкалары – җәлсәдә иделәр.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мигъраҗ вакытында төрле вакыйгалар күрә. Бер өммәткә күз сала: ул кешеләрнең иреннәре дөянеке кебек була. Бер төркем хезмәтчеләр, аларның иреннәрен кисеп, авызларына таш салалар. Пәйгамбәребез Җәбраилдән: «Болар кемнәр?» – дип сорый. Ул: «Алар хаксыз рәвештә ятимнәрнең малларын исраф итүчеләр», – дип җавап бирә.

Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм икенче өммәтне күрә. Ул өммәтнең кешеләре үз йөзләрен һәм күкрәкләрен бакыр тырнаклар белән тырныйлар. Аллаһының Расүле Җәбраилдән: «Бу кешеләр кемнәр?» – дип сорый. Ул: «Алар гайбәт сөйләп, яла ягып, кешеләрнең итләрен ашадылар», – дип җавап кайтара.[1]

Соңрак Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәетләрне һәм үләксәләрне ашаучы зиначыларны, күпергән эчләре белән риба ашаучыларны, башлары белән аска таба асылынган үз балаларын үтерүчеләрне күрә.[2] Үз гөнаһлары өчен газапланучаларны күрү, әлбәттә, җиңелләрдән булмагандыр. Шуңа күрә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дигән: «Әгәр сез мин белгәнне белсәгез, аз көлеп, күп елар идегез»[3].

Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам махсус бер чиккә кадәр генә бара ала, ул – «Сидратүл-Мөнтәһә» дип атала. Шул урынга җиткәч, Җәбраил фәрештә галәйһиссәләм: «Миңа куелган чик шушында бетте, алга таба барырга миңа рөхсәт юк», – дип әйтә. Пәйгамбәребез

---

1 Имам Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Тәбари хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

сәфәрне үзе генә дәвам итә. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгалә белән сөйләшү бәхетенә ирешә. Аллаһы хозурына баргач ул: «Әт-тәхиййәәтү лилләәһи вәс-саләүәәтү вәт-таййибәәт», – дип сәламли, ягъни: «Тел һәм тән гыйбадәтләребезнең барысы да фәкать Аллаһы өчен генә». Аллаһы Тәгалә: «Әс-сәләәмү галәйкә әййүһәннәбиййү вә рахмәтул-лааһи вә бәракәәтүһ», – дип җавап бирә, ягъни: «Әй пәйгамбәр, сиңа Раббыңның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын». Моңа каршы Пәйгамбәребез: «Әс-сәләәмү галәйнәә вә галәә гыйбәәдил-ләәһис-саалихиин», – дип әйтә, ягъни: «Сәлам безгә һәм Аллаһы Тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә дә булсын». Шуннан соң фәрештәләр: «Әшһәдү әл-ләә иләәһә илләл-лааһу, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлуһ», – дип, шәһадәт кәлимәсен әйтә, ягъни: «Чын күңелдән шаһитлек бирәбез ки, бер Аллаһыдан башка һичбер илаһ юк, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм – Аның колы һәм расүле».

Без әлеге сүзләрне барыбыз да намазда, «Әттәхият»кә утыргач әйтәбез. Без өч Затның – Аллаһы Тәгаләнең, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәм фәрештәләрнең әйткән сүзләрен кабатлыйбыз, шуңа күрә хәдис-шәрифтә: «Намаз – мөэминнең мигъраҗы», – дип әйтелгән. Димәк, намазда без Аллаһы Тәгалә белән сөйләшәбез, Аңа мөрәҗәгать итәбез, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аңа якын булабыз. Шундый олуг бәхеткә көн саен биш тапкыр ирешәбез.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин нинди бүләк белән китәм?» – дип сорагач, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең: «Өммәтеңә илле вакыт намаз фарыз итәм», – дигән җавабын ишетте. Кайтканда Расүлебезгә Муса галәйһиссәлам очрады һәм киңәш биреп: «Аллаһыга кайт, минем өммәтем шулкадәр гамәлне күтәрә, башкара алмас, җиңеләйтүне сора», – диде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Муса галәйһиссәлам киңәше белән тугыз тапкыр

Аллаһы хозурына барып, намазны җиңеләйтүне сорады һәм илле вакыт намазны биш вакытка гына калдырды. Муса галәйһиссәлам: «Тагын сора, бу гамәлләрне бәндәләрең күтәрә алмаслар», – дигән. Ләкин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Юк, Аллаһы каршына кайтырга оялам», – дип җавап бирә. Шул вакытта Аллаһы Тәгалә: «Бер бәндә бер изгелек кылса, ун изгелек кылган шикелле әҗерле булыр», – дип фәрман бирде. Ягъни биш вакыт намазны вакытында укысак, илле вакыт намаз укыган кебек әҗерле булырбыз.

Җиде кат күккә күтәрелеп, күз ачып йомганчы гаҗәеп күп вакыйгалар булса да, нең хәтта урыны да суынырга өлгерми.

Мигъраҗ кичәсендә барлык мөселманнар өчен бик зур сөенеч булarак Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Пәйгамбәребезгә өч төрле бүләк тапшыра:

1) «Әл-Бәкара» сүрәсенең ахыргы аятьләре иңдерелә (285-286 нчы аятьләр);

2) Һәр мөселманга биш вакыт намаз фарыз кылына;

3) Аллаһ Тәгаләгә тиңдәшлек кылмаучыларның зур гөнаһлары гафу ителәчәк дигән хәбәр бирелә.[1]

Мигъраҗ кичәсендә әлбәттә күбрәк өстәмә намазлар уку, дога кылу, күбрәк Коръән уку зикер-салаватлар әйтү хәерле. Аллаһы Раббыбыз һәрберебезгә әлеге кичәне Үзе риза булырлык гамәлгыйбадәттә үткәрергә насыйп итсен!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рәдиф хәзрәт Тимергалиев,*

*Кукмара районы мөхтәсибе*

*12 март вәгазе,*

*Раҗәб аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Балаларыбызны милли рухта тәрбиялик

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Хөрмәтле җәмәгать, дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә адәм баласын хөрмәтле һәм шәрәфле итеп яраткан. Адәм баласының дәрәҗәсе акыл һәм иман белән бәйле булса, аларның гамәли ягы – ул кешенең әхлагы, тәрбиясе. Динебездә тәрбияле булу дигәндә – ул дөнья һәм Ахирәт тормышында бәхеткә, уңышка алып бара торган яшәү рәвеше, дип әйтеп булыр иде. Чыннан да, тәрбияле кеше үзенә дә, чит кешегә дә, җәмгыятькә дә файда, иминлек, тынычлык алып килә. Ә тәрбиясезлек, киресенчә, кешенең үзенә авырлык китерә һәм башкаларга да бәла була.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөреслектә, мин дөрес әхлакны (тәрбияне) аңлатырга җибәрелдем», – дип нәсыйхәт кылган. Шулай ук: «Иң хәерлегез – яхшы әхлаклы булганыгыз», «Миңа иң якыныгыз – яхшы әхлаклы булганыгыз», – дип тә әйтеп калдырган.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә җиткергәнчә, югары әхлаклы, яхшы тәрбияле булу – һәрбер мөселманның бурычы. Шуңа күрә, һәрбер мөселманга үзенең, балаларының һәм ул җаваплы булган

кешеләрнең тәрбиясе, әхлагы турында уйланып тәрбия кылу кирәк буладыр. Шулар арасыннан, бала тәрбиясенә аерым тукталып үтәргә кирәк.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Ата (ата-ананың) баласына биргән иң кыйммәтле нәрсә – ул яхшы тәрбия». Аллаһы Тәгалә адәм баласын дөньяга китергәндә, нарасый бала итеп тудыра. Бала күңеле ак кәгазь кебек чиста була, дөньяга ул фитрый иман белән килә. Бу ата-анага Аллаһыдан зур бүләк, нигъмәт һәм олы әманәт итеп бирелә. Әгәр ата-ана бала күңелендә яхшылык, изгелек юлларын сызып калдырса, бала да, ата-ана да дөньяда да, Ахирәттә дә бәхеткә ирешер. Бер хикмәт иясе: «Ятим булу – ата-анасыз гына үсү түгел. Ул – ата-ана булып та, алардан дөрес тәрбия алмау», – дип әйтеп калдырган.

Гамәли яктан караганда, тәрбияне шартлы рәвештә икегә бүлеп булыр иде:

1. Дөнья тәрбиясе.
2. Дин тәрбиясе.

Болай аерып карау шартлы рәвештә генә, чынлыкта, алар берсе артыннан берсе баралар, чөнки, асылда, матди һәм рухи кыйммәтләрне тормышта аерып карап булмый. Дөнья тәрбиясе дигәндә – җәмгыятьтәге кешеләр белән мөгамәлә тәрбиясе, сәламәт булу, кәсеп итү, гыйлем алу, милли тәрбия бирү һ.б. тормыш итү дәверендә кирәкле булган тәрбияләрне әйтеп булыр иде. Ә дин тәрбиясе дигәндә – бәндәнең Раббысы белән булган мөнәсәбәт тәрбиясе, бурычлары һәм хаклары.

Болар арасыннан милли тәрбия турында әйтеп үтү хәзерге заман өчен бик кирәкле булыр. Туган җиреңне сөю, ата-анаңны, нәселеңне белү һәм аларны якын итеп яшәү – ул динебездәге күркәм тәрбиянең асылы. Җир йөзендә адәм балаларының төрле милләттән булулары – ул, беренчедән, безгә Аллаһының нигъмәте, икенчедән, безгә карата әманәт, дип аңларга кирәк. Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләргә кадер-хөрмәт күрсәтеп, аны саклап, исраф кылмыйча яшәгән кебек, милләтеңне дә, телеңне дә белеп, саклап, хөрмәт

итеп яшәү кирәк була. Чыннан да, Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрне дөрес кабул итеп, кулланып, шөкер итеп яшәгәндә тормышыбызга бәрәкәт килә. Әмма, шәйтан тик тормый: ул безне шушы нигъмәтләрдән ваз кичтерергә тели. Хәтта, Аллаһы биргән нигъмәтләрне инкяр итүгә кадәр алып бара. Җавап итеп Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен җиткерәм:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«Ий кешеләр! Һичшиксез, Без сезне [Адәм исемле] бер ирдән һәм [Хавва исемле] бер хатыннан яраттык. [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның ни мәгънәсе бар?] Без сезне [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы хозурында иң кадерлегез – [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннанан сакланган] бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, [һәрнәрсәдән] Хәбәрдар».**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

Бу аятьтән аңлашылганча, адәм балаларының төрле милләттән булулары – Аллаһы Тәгаләнең кануны. Динебездә милләт бар, әмма милләтчелек юк, чөнки, аерым бер кешенең, милләтнең үзен башкалардан өстен куюы – ислам динендә тыелган гамәл. Аллаһы каршында бәндә иманы һәм гамәле белән олы дәрәҗәләргә ия булыр.

Хөрмәтле җәмәгать, йомгаклап шуны әйтергә телим: үзебезгә, якыннарыбызга, балаларыбызга дөрес һәм кирәкле булган милли тәрбия бирергә ашыгыйк.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Ибатуллин,*

*«Дин Ислам» мәчете имам – хатыйбы*

*19 март вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Рамазан аеның фазыйләте

Әгүүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи кәрим вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт булараk җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә безгә Коръәни Кәримдә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз булараk] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Рамазан аенда һәр көн ураза тоту, ягъни таң яктылыгы җәелгән вакыттан башлап, кояш батканчыга кадәр ашамый, эчми һәм якынлык кылмый тору – балигъ һәм акыллы булган һәрбер мөэмин кешегә фарыз.

Аллаһы Тәгалә: «Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек», дип әйтә, ягъни безгә кадәр булган барча халык та уразалы булганнар, хәтта археологларның тикшерүләренә караганда, безгә кадәр уразасыз халык яшәмәгән, диләр. Сәгыйт бине Җөбәер болай дип әйткән: «Безгә кадәр исламның әүвәлге вакытында да уразаны кичтән алып икенче кичкә кадәр тоталар иде», ягъни безнеңчә әйткәндә, бер тәүлек. Әмма инде шушы аять иңгәч бу йола туктатылды.

Шушы аятькә тагын күз салсак, Аллаһы Тәгалә:

لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

дип әйтә, ягъни «шәт тәкъвалы булырсыз», – ди. Әмма «ураза тотып, әлбәттә, тәкъвалы буласыз», димәгән, чөнки кешенең һәртөрле гөнаһтан, гайбәттән, харамга күз төшерүдән, сүгенүдән, талашулардан һ.б. саклана аламы яки юкмы икәне үзеннән тора.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә кеше бозык сүзләрдән, ялганнан, гайбәттән тыела алмаса, Аллаһы Тәгалә аның ашауэчүне ташлавына мохтаҗ түгел», – дип әйткән.

Шуңа күрә мөселман игелекле, күркәм әхлаклы, хәерле сүзле булырга тиеш.

Шулай ук Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۚ فَمَن شَهِدَ مِنكُمُ الشَّهْرَ فَلْيَصُمْهُ ۖ

> **«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән [ай]. Сездән берәү Рамазан аена ирешсә, аны ураза тотып үткәрсен ...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Аллаһының ураза тотарга биргән әмере: ирләргә, хатыннарга, яшьләргә, картларга, байларга, ярлыларга, патшаларга, эшчеләргә, укучыларга һәм хәрбиләргә. Эшнең авырлыгы, тормышның мәшәкатьле булуы, балаларның күплеге, яшьләрнең мәктәптә яки югары уку йортларында укулары һәм бәла-каза килүләр, ураза тотмаска гозер була алмыйлар. Фәкать ятып чирләгән, мәшәкатьле озын сәфәрдә булган, картлык зәгыйфьлегенә ирешкән, тоткында булган һәм йөкле, хәезле хатыннар – болар гозерле булалар. Картлык зәгыйфьлегенә ирешкән кеше һәм сәламәтләнми торган чирле кеше, болар көчләре җитмәү сәбәпле ураза тотмыйлар һәм каза да кылмыйлар. Маллары булса, фидия бирәләр.

Әлеге аятьнең дәвамы бар:

... وَمَن كَانَ مَرِيضًا أَوْ عَلَىٰ سَفَرٍ فَعِدَّةٌ مِّنْ أَيَّامٍ أُخَرَ ۗ يُرِيدُ اللَّهُ بِكُمُ الْيُسْرَ وَلَا يُرِيدُ بِكُمُ الْعُسْرَ وَلِتُكْمِلُوا الْعِدَّةَ وَلِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَىٰ مَا هَدَاكُمْ وَلَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ ﴿١٨٥﴾

**«...лəкин кем [ураза тота алмаслык дәрәҗәдә] авыру яки сәфәрдә булса, башка санаулы көннәрне [тотарга тиеш]. Аллаһы сезгә җиңеллек тели, сезгә авырлык теләми, [ураза тотарга кирәкле көннәр] санын тутырырсыз, һәм, сезгә туры юлны күрсәткәне өчен, Аллаһыны олыларсыз [дип]. Бәлки, [Аллаһының хисапсыз нигъмәтләренә, бигрәк тә шушы рөхсәтләренә] шөкер итүчеләрдән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Шушы аятьтән аңлашылганча, Коръән Рамазан аенда иңә башлаган, шуңа күрә Рамазан аенда Коръән уку мөстәхәб һәм савабы да артыграк. Риваятьләргә караганда, барча илаһи китаплар нәкъ менә Рамазан аенда иңгән. Зәбур китабы – алтынчы, Тәүрат китабы – уникенче, Инҗил китабы – унтугызынчы һәм Коръән китабы – егерме җиденче Рамазанда иңгән.

Әл-Багави дигән галим түбәндәге сүзләрне әйткән: «Дөреслектә, «Рамазан» дигән сүз «Рамдаа» дигән сүздән алынган, ягъни кыздырылган ташлар мәгънәсендә, чөнки алар кызу көннәрдә ураза тотканнар». Ул замандагы гарәпләр берәр айга исем бирергә теләгәндә, алар беренче чиратта вакыйгаларга яки фасылларга карый торган булганнар, әмма Рамазан ае кызу көнгә туры килгәч, алар ул айга «Рамазан», дип исем биргәннәр. Икенче бер галим: «Ул айны, гөнаһларны яндырганга күрә, «Рамазан» дип атадылар», – дип әйткән.

Рамазан уразасы икенче һиҗри елында фарыз була. Рамазан уразасы динебездә зарури, шуңа күрә аны инкяр иткән кеше көферлеккә төшә.

Рамазан уразасы турында күп кенә хәдисләр риваять ителә, шуларның кайберәүләрен карап үтик.

Әбү Һөрайрадан Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләре риваять ителә: «Рамазан ае кергәч, җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, шәйтаннар баглана», – диде. Шушы хәдистән аңлашылганча, Рамазан аенда Аллаһының рәхмәте иңәр, шәйтаннар бикләнер, багланыр һәм ураза тотарга комачауламаслар. Күпләребезнең сизгәне бардыр, башка айлардан аермалы буларак, Рамазан аенда ураза тоту аеруча җиңел һәм гөнаһлар да аз кылына.

Хәдис дәвамында Аллаһы Тәгаләнең әлеге сүзләре тапшырыла: «Әй хәерлегә омтылучы! Аллаһыга якынай! Әй начарлыкка омтылучы! Гөнаһыңнан тукта! Аллаһы һәр төнне бер ураза тотучыны җәһәннәмнән коткарыр».

Дәвам итеп Аллаһы Тәгалә болай дип әйтер: «Гафу сораучы бармы, гөнаһларын гафу итәрмен! Берәр ихтыяҗың бармы, сораганыңны бирермен! Тәүбә кылучы бармы, тәүбәләрен кабул итәрмен!» Һәм шушы мөрәҗәгать таң атканчы дәвам итәр. Һәм Аллаһы Тәгалә һәркөнне, һәр

ифтар вакытында меңләгән ураза тотучы мөселманнарны җәһәннәм утыннан коткарыр»[1].

Әй кардәшләрем! Шушы форсаттан мәхрүм кала күрмәгез, чөнки тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ни үкенеч шул кешегә, Рамазан үтеп китеп тә, гөнаһлары гафу ителмәсә», – дигән.

Сәлмән Әл-Фәриси Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәгъбан аеның соңгы көнендә сөйләгән вәгазен риваять итә: «Әй кешеләр! Сезгә бөек ай якынлашып килә, ул айда мең айдан да хәерлерәк булган Кадер кичәсе бар һәм Аллаһы Тәгалә бу айда уразаны сезгә фарыз итте, ә тәравих намазын сөннәт итте. Кем бу айда бер изгелек кылса, фарыз гамәлне үтәгән кебек булыр, ә кем фарыз гамәлне үтәсә, җитмеш фарызга тиң булыр. Рамазан – сабырлык ае, ә сабырлыкның нәтиҗәсе – җәннәт. Рамазан ае – уртаклашу ае. Ул айда мөселманның ризыгы киңәер, кем уразалы кешегә авыз ачтырса, ураза тоткан кешенең әҗерен алыр, гөнаһысы гафу ителеп, үзен уттан саклар». Шуннан соң сәхабәләр: «Йә Расүллуллаһ! Һәрберебез дә ураза тотучыга авыз ачтырырлык ризык таба алмыйбыз», – диделәр. Пәйгамбәребез җавап итеп: «Кем ураза тотучыга бер йотым сөт яки су яки бер бөртек хөрмә булса да бирсә, Аллаһы аның әҗерен шиксез бирер. Ә кем инде ураза тотучыны тукландырып ашатса, аның бөтен гөнаһлары ярлыканыр, Аллаһы аны үзенең чишмәсеннән су эчертер вә шуннан соң ул беркайчан да сусамас һәм Аллаһы Тәгалә аңа ураза тотучы кешенең әҗерен биреп, ураза тотучының да, аңа карап әҗерен киметмәс», – дип әйткән.

Тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Рамазан аеның беренче ун көне – рәхмәт, икенче ун көне – мәгъфирәт, өченче ун көне – җәһәннәмнән котылу ае. Кем бу айда үзенең малын сарыф итсә, Аллаһы аны уттан саклар».

[1] Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

Бу айда дүрт әйберне эшләргә тырышыгыз: икесеннән сез Раббыгызның ризалыгына ирешерсез, ә калган икесенә сез үзегез мохтаҗдыр. Раббыбызның ризалыгына ирештерә торган беренче ике гамәл – ул да булса «Ләә иләәһә илләллааһу», ягъни «Аллаһыдан башка илаһ юк», дип даими шушы кәлимәне әйтү һәм истигъфар кылу, ә сез мохтаҗ булган гамәл: ул да булса Аллаһыдан даими җәннәтне эстәү һәм җәһәннәмнән сыгыну.

Пәйгамбәребез бер кодси хәдистә болай дигән: «Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә: «Адәм баласы кылган һәр гамәл үзе өчен, уразадан кала, чөнки ураза Минеке һәм әҗерен дә Үзем бирермен», – диде[1].

Никадәр гүзәл гыйбадәт ул ураза! Аллаһы аны Минеке дип, безне шатландырды, чөнки ураза риядан ерак булган бердәнбер гамәл. Ураза тотасыңмы, юкмы – Аллаһыдан кала беркем дә белә алмый, гәрчә син үзеңне уразалы дисәң дә.

Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Рамазанда минем өммәтемә биш әйбер бирелде. Башка өммәтләргә ул бирелмәде»:

1. Ураза тотучының авызыннан чыккан ис, миск (ислемай) исенә караганда Аллаһыга күпкә күркәмрәк.

2. Авыз ачканчы фәрештәләр уразалы кешегә истигъфар укыр.

3. Шәйтаннар багланыр.

4. Һәр көнне ураза тоткан кеше өчен Аллаһы аның өчен җәннәтне бизәп торыр.

5. Рамазанның соңгы төнендә Аллаһы Тәгалә тулысынча аны гафу итәр.

Шунда сәхабәләр: «Йә Расүлуллаһ, ул Кадер кичәсеме?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм җавап итеп: «Юк, һәр кеше берәр эшен тәмамласа, ахырда хакын алыр», – дигән.

1 Имамнар Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Инде йомгаклап Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер гүзәл сүзен язып үтик. Расүлебез салләллау галәйһи вә сәлләм: «Ураза тотучы кешенең ике шатлыгы бар: берсе авыз ачкан вакытта, ә икенчесе, гөнаһыбыз гафу ителгән хәлдә Кыямәт көнендә Аллаһы белән очрашканда», – дип әйткән.

Аллаһы Тәгалә күңелләребезгә иман, тәкъвалык бирсен. Бер-беребезгә ярату, берләшүне кире кайтарып, урамда да, өйдә дә, мәчеттә дә, дөньяда да, үлгәч тә, Аллаһы Тәгалә мөселман булып калырга насыйп итсен. Аллаһы Тәгалә уразаларыбызны кабул әйләп, гөнаһларыбызны гафу итсә иде. Әәмин!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*26 март вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Бәраәт – мөселманнарның мәртәбәле кичәсе

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Быел Бәраәт кичәсе 28 нче марттан 29 нчы мартка каршы кичтә була. «Бәраәт» сүзе гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә «бурычтан вә җәзадан котылу», «пакьләнү» дигәнне аңлата.

Бәраәт – гөнаһлардан котылу, бәхет, иминлек, уңыш һәм изгелекләр иңә торган кичә дип санала. Шуңа күрә бу кичәдә мөселманнар Аллаһы Тәгаләдән үзләренең һәм мәрхүмнәрнең гөнаһларын ярлыкавын сорап дога кылалар. Шулай ук бу кичәдә Коръәни Кәрим Ләүхүл-Мәхфүздән күкләргә иңгән дип санала.

Кадер кичәсеннән соң иң изге кичә – Бәраәт кичәсе, чөнки Коръән беренче мәртәбә Бәраәт кичәсендә дөнья күгенә иңдерелгән һәм Кадер кичәсендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә вәхи иңә башлаган. Киләчәк бер ел эчендә бөтен мәхлукатның ризыклары, байлык вә ярлылык хәлләре, дөньяга мөнәсәбәтле дәрәҗәләре, яңа туачак вә ул ел эчендә вафат булачак кешеләр – барысы да бу кичне билгеләнер.

Бәраәт кичәсе, Кадер кичәсеннән соң, әһәмиятлелеге буенча, икенче зур бәйрәмнәрнең берсе. Имам Газали рахимәһуллаһи: «Мөселманнарга җир йөзендә ике көн гает булганы кебек, фәрештәләр дә күктә ике кичәне гает кылып үткәрәләр икән. Алар исә Кадер һәм Бәраәт кичәләре», – дип әйткән.

Әлеге кичәнең фазыйләтләре турында хәдис-шәрифләр дә шактый. «Бәраәт кичәсендә бер ел эчендә булачак эшләр хакында хөкем кылына, әҗәл һәм гомерләр билгеләнә»[1].

Танылган ислам галиме имам Субки үзенең тәфсирендә болай дип яза: «Дөреслектә, Бәраәт кичәсендә бер ел эчендә, җомга кичәсендә бер атна эчендә, ә Кадер кичәсендә гомер буе кылган гөнаһлар гафу ителә».

Тагын бер хәдистә түбәндәгеләр җиткерелгән: «Шәгъбан аеның унбишенче кичәсе керсә, аны гыйбадәт белән үткәрегез. Көндез исә ураза тотыгыз, чөнки Аллаһы Тәгалә ул кичне кояшның чыгуына кадәр дөнья галәменә рәхмәтен җибәрер һәм: «Тәүбә һәм истигъфар итүче булса, аны гафу итәм. Ризык сораучы булса, аңа ризык бирәм. Авыруга дучар булса, аңа саулык-сәламәтлек бирәм. Бармы андый кешеләр?» – дип сорар»[2].

Бу мөбарәк кичәдә Җәбраил фәрештә галәйһиссәлләм, пәйгамбәребез Мөхәммәд сәллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Йә, Аллаһының Расүле! Аллаһы Тәгалә бу кичәдә шактый күп кешене кичерер, шактыен гафу итмичә калдырыр. Шул гафу ителмәүчеләр – мөэминнәр белән талашучылар, мөселманнарны кимсетүчеләр, туганлык хисен, araларын кисүчеләр, тәкәбберләр, ата-анасын рәнҗетүчеләр, гомерләрен сәрхүшлектә үткәрүчеләр...», – дип әйткән.

1 Имам Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

**Бәраәт кичәсен ничек үткәрергә?**

1. Намаз уку. Әлеге гыйбадәт мөселман кешесе белән Аллаһы Тәгалә арасын якынайту чарасы булып тора. Шуңа күрә әлеге кичәдә нәфел (өстәмә) намазлар уку, каза гыйбадәтләрен кылу – бик тә күркәм гадәт.

2. Тәүбә итү. Иңнәребездәге ике фәрештә ел буена кылган гамәлләребезне язып баралар. Шушы кичтә фәрештәләр тарафыннан язылган безнең гамәл китабыбыз Аллаһы хозурына күчеп, аның урынына яңасы иңеп ачыла. Шуның өчен бу кичәдә кылган гөнаһларга үкенергә, тәүбә кылырга, Аллаһы Тәгаләдән гафу сорарга һәм бүтән бу гөнаһларыбызга кайтмавыбызны, изге юлда булуыбызны Аллаһы Тәгаләдән сорарга кирәк.

3. Коръән уку. Бу кичәдә өч мәртәбә «Йәсин» сүрәсе укылыр. Беренче мәртәбә «Йәсин» сүрәсен укыганда укучының нияте Аллаһы Тәгаләдән озын гомер сораудан гыйбарәт булыр, икенче мәртәбә Аллаһы Тәгаләдән бәла-казалардан иминлек сорар. Өченче мәртәбә бәрәкәт артсын дип укыр.

4. Зикерләр әйтү. Аллаһы Тәгаләне искә алу һәм мактау адәм баласының йөрәген йомшарта, күңелен чистарта. Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сүбехәналлаһи, вәлхәмдүлилләһи, вә ләә иләәһә иллаллаһу, вәллааһу әкбәр, вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләһ» (мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә барлык кимчелекләрдән азат. Аллаһыга барча мактауларыбыз. Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга лаек булган зат юк. Аллаһы – олуг, Аллаһыдан башка беркемнең дә көче һәм куәте юк»), – дип әйткән.

5. Салаватлар әйтү. Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ихлас күңелдән салаватлар әйтергә онытмыйк. Шул рәвешле без күңелебез белән Пәйгамбәребез тәкъвалыгына ирешергә омтылачакбыз.

6. Аллаһы Раббыбызга дога белән мөрәҗәгать итсәк, «рәхмәт ишекләре» төне буе ачык булачак. Шуңа да барлык ихтыяҗларыбызны

сорап, гаиләбез өчен, балаларыбыз, якын туганнарыбыз, өммәтебез өчен, бакыйлыкка күчкән кардәшләребез өчен дога кылырга кирәк. Әлеге кичәдән соңгы киләсе көндә ураза тотарга кушыла: «Шәгъбан аеның 15 нче төнендә гыйбадәт кылыгыз, киләсе көндә уразага керегез. Аллаһы Тәгалә әлеге төндә кояш чыкканчыга кадәр догага кулын күтәргән бәндәсен бәрәкәт-сәгадәт белән бүләкли»[1].

Бәраәт кичәсе – мөселманнарның мәртәбәле кичәсе. Шуңа да аны гыйбадәттә, Аллаһы тыйганнарыннан тыелып үткәрергә кирәк. Бәраәт кичәсе догасы:

اَللَّهُمَّ اِنْ كُنْتَ كَتَبْتَ اِسْمِي شَقِيًّا فِي دِوَانِ الْاَشْقِيَاءِ فَامْحُهُ وَ اكْتُبْ فِي دِوَانِ السُّعَدَاءِ وَ انْ كُنْتَ كَتَبْتَ اِسْمِي سَعِيدًا فِي دِوَانِ السُّعَدَاءِ فَاثْبُتْهُ فَاِنَّكَ قُلْتَ فِي كِتَابِكَ الْكَرِيمِ يَمْحُ اللَّهُ مَا يَشَاءُ وَ يُثْبِتُ وَ عِنْدَهُ اُمُّ الْكِتَابِ

«Аллаһуммә иң күнтә кәтәбтә исмии шәкыййән фии диүәәнил-әшкыйәә-и фәмхуһу вәктүб фии диүәәнис-сүгадәә-и. Вә иң күнтә кәтәбтә исмии сәгыйдән фии диүәәнис-сүгәдәә-и фәсбүтһу фә-иннәкә культә фии китәәбикәл-кәриим. Йәмхуллааһу мәә йәшәә-ү вә йүсбит вә гыйндәһу уммүл-китәәб».

Мәгънәсе: «Йә, Аллаһым, әгәр мине бәхетсез итеп, исемемне бәхетсезләр дәфтәренә язган булсаң, аны сөртеп юк итсәң иде һәм бәхетлеләр дәфтәренә язсаң иде. Әгәр мине бәхетлеләрдән итеп, исемемне бәхетлеләр дәфтәренә язган булсаң, әлеге язуны беркайчан да сөртелми торган ит. Дөреслектә, Син Коръәндә: «Аллаһы Тәгалә нәрсәне теләсә, Ләүхүл-Мәхфүздән шуны сөртер, юк итәр, теләгәнен исә беркетер, сөртелмәс итәр», – дип әйтәсең.

1 Имам Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ибраһим хәзрәт Шаһимәрдәнов,*
*Питрәч районы, Көек авылы мәчете имам-хатыйбы,*
*«ТҖ МДНнең Дәгъват бүлеге белгече*

*2 апрель вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Рамазанның иң зур бүләге – ураза

Галәмнәрнең Раббысы Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкераналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават, сәламнәр әйтәбез.

Хөрмәтле җәмәгать, дин кардәшләрем җомга көне мөбәрак булсын! Бу көннең дәрәҗәсен аңлап, аның фазыйләтләренә ирешергә, ошбу Рамазан аеның да әҗер-савабына, дәрәҗәләренә ирешергә насыйп итсен.

Чыннан да, Рамазан ае һәрберебез өчен дә көтеп алынган вакыт, зур нигъмәт, бәрәкәт, сәгадәт һәм шулай ук бүләкләр бирелә торган ай булып тора. Калган унбер айның берсен генә дә Рамазан ае белән чагыштырып булмый. Ураза ае – ул тәрбия ае, рухи үсеш ае. Аллаһы Тәгалә безгә тәкъвалыкка ирешү өчен шушы айны биргән.

Бу айда Аллаһы шәйтаннарны богаулап куя һәм шуның белән адәм балаларына гыйбадәт кылу җиңеләя, кеше гөнаһлардан да ансат кына тыела. Әлеге айда утыз көн буе уразасын да тотабыз, эшкә дә йөрибез, төнлә тәравих намазларын да укыйбыз. Шул рәвешле күбрәк гыйбадәт кылып, ихласлык-күндәмлек күрсәтеп, гөнаһ-хаталарыбыздан котылабыз, җаннарыбызны пакьлибез, дингә һәм Коръәнгә якынаябыз. Ураза аенда садакаларыбызны, зәкятләребезне түләргә ашыгабыз. Шуның белән мохтаҗларны-фәкыйрьләрне сөендерәбез. Бу айда Аллаһы Тәгалә җәһәннәмнең капкаларын ябып, җәннәт ишекләрен ача. Димәк, күбрәк гыйбадәт кылып, җәннәт әһелләре булу өчен тырышырга тиеш-

без. Уразаның сәламәтлек өчен булган зур нигъмәтен дә әйтергә кирәк. Мөселман кешесе өчен Рамазан аеның һәрбер көне һәм төне кадерле.

Аллаһы Тәгаләнең юмартлыгы һәм рәхмәте ташып торган, безгә бүләк итеп бирелгән бу ай хакында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә болай дип әйтелә:

«Рамазан – өммәтемнең ае»;

«Сезгә Рамазан килде, ул бәрәкәт ае. Бу айда Аллаһы сезне Үз рәхмәте белән колачлый, кимчелек-хаталарыгызны кичерә, кылган догаларыгызны кабул итә. Бу айда Аллаһы сезнең изгелек кылуда үзара ярышуларыгызга карый һәм сезнең исемнәрегезне фәрештәләр янында искә ала. Бу айда Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм калган кеше – бәхетсездер».

«Рамазан ае уразасын ихлас күңел белән һәм савабын бары тик Аллаһыдан гына өмет итеп тоткан кешенең кылган гөнаһлары ярлыканыр»;

«Әгәр кешеләр Рамазан аеның бөтен хасиятләрен, савапларын белсәләр, бөтен ел әйләнәсе Рамазан ае булуын теләрләр иде»;

«Ураза тоткан кешенең йокысы – гыйбадәт, эндәшмәве – тәсбих, гамәле даими, догасы кабул ителгән, ә гөнаһысы гафу ителгән булыр»;

«Ураза тотучыны сөендерә торган ике нәрсә бар. Берсе: ифтар вакытында авыз ачканда сөенү, икенчесе: Кыямәт көнендә, уразаның савабына сөенү»;

«Ураза тотучы кешенең ифтар вакытында кабул ителә торган догасы бар»;

«Җәннәттә Әр-Райан дигән бер ишек бар. Кыямәт көнендә бу ишектән бары тик ураза тотучылар гына керәчәк. Аннан ураза тотучылардан башка берәү дә керә алмаячак»;

«Ураза – ул кешене җәһәннәм утыннан саклый торган калкан»;

«Чисталык, пакьлек – иманның яртысы, ураза – сабырлыкның яртысы»;

«Өммәтем гади айда кылган бер яхшы гамәл өчен бер савап ала, әмма Рамазанда исә Аллаһы бер яхшы гамәл өчен җиде йөзгә хәтле һәм аннан да күбрәк әҗер бирә. Фарыз (мәҗбүри) гыйбадәт өчен башка айларда кылган җитмеш фарызның савабын, нәфел (өстәмә) гыйбадәт өчен башка айларда кылган фарызның савабын бирә»;

«Бер адәм Рамазан аен шатланып каршы алса һәм Рамазан аеның үтеп китүенә күңеле белән, яхшы айлар үтте, дип кайгырса, ул адәмгә мәңгелек сәгадәт, рәхәт йорты булган җәннәт вәҗиб (тиешле) булыр»;

«Кем дә кем Рамазан аенда ныклы иман һәм әҗер-савапка өмет итеп төнге намаз укыса, аның гөнаһлары кичерелер»;

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Нинди садака иң яхшысы?» – дип соралгач, ул: «Рамазан аенда бирелгән садака», – дип җавап биргән;

«Изге Рамазан ае җитте. Аллаһы Тәгалә бу айда безгә ураза тотарга кушты. Бу вакытта күк ишекләре ачыла, шәйтаннар богаулана. Бу айда шундый көн бар, ул башка мең кичтән дә яхшырак. Бу кичтән мәхрүм калучылар – барыннан да мәхрүм калучылар»;

«Рамазан аеның башы – рәхмәт, уртасы – мәгъфирәт, ахыры – җәһәннәм газабыннан котылудыр»;

«Ураза тотыгыз – сәламәтлегегезне ныгытырсыз»;

«Тотылган ураза һәм укылган Коръән Хисап көнендә колы өчен шәфәгать сораячак. Ураза әйтер: «Йә, Раббым! Мин аңа ашарга һәм нәфес теләкләрен үтәргә комачауладым. Минем шәфәгатемне кабул ит!» Коръән әйтер: «Мин аның төнге йокысына комачауладым. Минем шәфәгатемне кабул ит!»

«Өч кешенең догасы кабул ителми калмас: дөреслек белән идарә итүче дәүләт башлыгының, авыз ачканда ураза тотучының, кыерсытылган кешенең»;

«Иртәнге шәфәкъка кадәр (сәхәр) ашагыз, монда бәрәкәт бар»;

«Ураза тотучыны ашатучы үзе ураза тоткан кебек савап алыр»;

«Ифтар вакытында хөрмә җимеше белән авыз ачыгыз, монда бәрәкәт бар. Хөрмә тапмасагыз, су белән ачыгыз, чөнки ул чиста»;

«Кем уразалы була торып та ялганнан, гайбәттән тукталмый икән, аның ач йөрүеннән бернинди файда юк».

Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбызны, укыган тәравих намазларыбызны, кылган изгелекләребезне, биргән садакаларыбызны кабул итсен, хата-кимчелекләребезне гафу әйләсен. Күңелләребездәге изге теләкләребезгә, уй-ниятләребезгә, ике дөнья бәхет-сәгадәтенә ирешергә насыйп кылсын. Ил көннәребезгә иминлек, бәрәкәт ирешсен. Аллаһы Тәгалә барчабыздан да разый булсын.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Ибатуллин,*
*«Дин Ислам» мәчете имам-хатыйбы*

# Әңгәмә

# «Коръән – рухи азык»



**Раббыбызның иң соңгы китабы – ул Коръән. Мөселманнар Аллаһы Тәгаләнең шушы ахыргы Изге Китабын Кыямәт көненә кадәр, ягъни бу дөнья беткәнче, кешелеккә яшәү өчен өйрәтмә һәм Ахирәткә әзерләнү өчен кулланма буларак кабул итә.**

**ТҖ МДНнең Шәригать сораулары бүлегенең баш белгече, Коръәнне өйрәнү үзәгенең җитәкчесе, Коръән-хафиз Илнур хәзрәт Хәйруллин белән Аллаһының Изге Китабы булган Коръән, аны ятлауның фазыйләтләре хакында әңгәмә кордык.**

**– Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ, Илнур хәзрәт.**

– Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

**– Әңгәмәбезне башлап, сездән иң элек Коръән хакында сорыйсы килә. Әлеге Изге Китап турында күбрәк сөйләсәгез иде.**

– Коръән – ул Аллаһы Тәгаләнең сүзе, ул Коръәнне Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәлам аша безнең Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә 23 ел дәверендә аятьләп-аятьләп яки сүрә, кыска сүрәләр итеп

иңдерде. Кайбер аятьләр сорау сәбәпле иңдерелде, мәсәлән, сәхабәләр кайбер сораулар бирәләр иде. Кайберләренең ни өчен иңдерелгәннәрен Аллаһы Тәгалә Үзе генә белә.

Аллаһы Тәгалә Коръәнне ни өчен иңдерде? Аллаһы Тәгалә безне бу дөньяга яратты, шулай бит, һәм безне ташлап калдырмады. Яратучы Үзенең яраткан мәхлүгын белә: аңа нәрсә кирәк, нәрсә кирәкмәс, ничек яшәсен – менә боларны бары тик Аллаһы Тәгалә генә белә. Шуның өчен безгә менә бу Коръәнне иңдерде, без аларны (сүрә-аятьләрне) укып, фикерләп, шуның белән яшәсен өчен.

Асылда бөтен кеше бәхетле булырга тели, шулай бит? Бәхетне Аллаһы Тәгалә Ислам динендә яшергән. Әгәр кеше Коръән кушканча яшәсә, бәхетле була, бәхетен таба. Кем кире кага, бу бәхетсез кеше була.

**– Болай булгач, мөселман кешесе Коръәнне өйрәнергә тиешме? Ничек итеп? Коръәнне укый белмәсә, нишләргә кирәк?**

– Коръәнне укый белмәсә, күпмедер микъдар өйрәнү аңа фарыз булып тора, чөнки аятьтә Аллаһы Тәгалә Коръәнне тәртил белән укырга әмер итә. Тәртил дигән нәрсә – (хәрефләрнең) дөрес мәхраҗларын, сыйфатларын чыгарып, тәҗвид кагыйдәләренә буйсынып укырга әмер итә. Без инде аны намазда уку сәбәпле, безгә ул фарыз, чөнки намазда дөрес укымасак, безнең намаз дөрес буламы яки дөрес булмыймы, без аны белмибез. Күпмедер микъдар дигәндә, намазга җитәрлек «Фатиха» һәм берничә сүрәне әйтәбез. Шуның өчен без ким дигәндә, аларны дөрес итеп укырга өйрәнергә тиешбез. Бу инде фарыз булып тора. Ә инде Коръәнне ачып, аңа карап уку – бу сөннәт гамәл, ягъни кеше Коръән укымаса, гөнаһлы булмый, ләкин күп әҗер-саваптан, бәрәкәттән мәхрүм кала.

**– Кеше савап алу максатыннан көннең күпмедер өлешен Коръәнгә бүләк итәргә тиеш?**

– Әйе, әгәр кеше савап алырга теләсә, Коръәнне күпмедер микъдар укырга тиеш. Сәхабәләрнең: «Кешегә буш вакытында кулына Коръән алып

берничә аять укырга нәрсә комачаулый?» – дип әйткән сүзләре дә бар. Коръәннең фазыйләтен сәхабәләр безгә караганда яхшырак аңлаганнар. Безгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә: «Коръән укыгыз, Кыямәт көнендә ул сезгә шәфәгатьче булачак», – дип әйткән һәм Коръән укырга әмер иткән.

**– Илнур хәзрәт, әгәр кеше гарәп хәрефләрен генә белсә, ләкин тәҗвид фәнен белмәсә, ул кешегә Коръәнне ачып уку нинди фазыйләт булып тора? Әллә ул иң элек тәҗвидне өйрәнергә тиешме?**

– Әйе, әйткәнемчә, әгәр кеше Коръән укырга өйрәнергә теләсә, иң элек ул тәҗвидне өйрәнергә тиеш, чөнки дөрес итеп уку – фарыз. Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк, гарәп хәрефләрендә йомшак хәрефне калын әйтсәң яки калынны йомшак итеп әйтсәң дә, яки кайбер җирләрдә сузып җибәрсәң, йә киресенчә, сузмасаң, сүзнең мәгънәсе үзгәрә. Шуның өчен дә без Аллаһының сүзләрен укыганда сүзнең мәгънәсен үзгәртеп укысак, моның өчен савап булмый, киресенчә, кешегә гөнаһ язылырга мөмкин.

**– Яңа гына Исламга килгән, ләкин әле дини гыйлеме булмаган олы яшьтәге кеше остаз белән генә сүрәне ятлый аламы? Мәсәлән, шул ук «Фатиха» һәм берничә кыска сүрәне тәҗвид фәнен өйрәнмичә генә ятларга мөмкинме?**

– Әйе, алай да мөмкин, чөнки тәҗвид фәнен теория, ягъни фән буларак белү – фарыз кифая булып тора, хөкеме шундый. Фарыз кифая – бер мәхәлләдә берничә кеше белсә, башкаларның өсләреннән төшә торган гамәл, ягъни фарыз булмый. Әйтик, мәхәллә тирәсендә яшәүчеләрдән берәү дә белмәсә, барысы да гөнаһлы була. Арасыннан берсе булса да өйрәнергә тиеш була. Әгәр араларыннан берсе яки берничәсе өйрәнсә, башкаларның өстеннән төшә. Шулай да имам яки мөгаллим белән берничә сүрәне булса да дөрес итеп өйрәнү хуплана.

**– Әгәр кешенең Коръәнне тулысынча ятларга теләге булса, моның өчен аңа күпме вакыт таләп ителә?**

– Бу мәсьәлә күбрәк кешенең зиһене белән бәйле. Әгәр кеше тырышып, көненә Коръәннән берәр бит ятлап барса, уртача ике ел кирәк. Ләкин әле ул кешенең яшенә дә карый, ягъни олы яшьтәге кешеме, яшь кешеме. Анысы да мөһим, чөнки яшь кеше тизрәк үзләштерә, ә олы кешегә өйрәнер өчен күбрәк вакыт таләп ителә.

**– «Коръән укыйсыңмы яки ятлыйсыңмы?» – дигән сорауга кайберәүләр: «Эштән арып кайтам, моңа вакытым җитми», – дип җавап кайтаралар. Коръәнгә якынрак булу өчен сез бу кешеләргә нинди нәсыйхәт бирер идегез?**

– Минем бер шәкертем бар иде. Төзелеш өлкәсендә эшләде. Ул иң элек кыска сүрәләрне ятлаудан башлады. Юлда машинасында барганда һәм кайтканда да кабатлый иде, эштән кайткач та кабатлый иде. Шулай 2-3 ел эчендә Коръән ятлауны тәмамлады. Ул хәзер дә әле дәвам итә, хәдисләр ятлый. Бу инде кешенең кызыксынуыннан килә. Эштән арып кайтканны көтәргә кирәк түгел, киресенчә, эштә 5 кенә минут буш вакытың бар икән, шулчагында син Коръәнне ачып укый яки өйрәнгәнеңне кабатлый аласың. Транспортта йөргәндә күргәнегез бар бит, кулына китап тотып укып баручылар бар. Безгә дә кулыбызга Коръән алып, аны укып барырга беркем дә комачауламый. Без бит чәй эчәргә дә 5-10 минут кына вакыт табабыз. Теләк булганда Коръән укырга да вакыт табарга мөмкин. Әйткәнемчә, ул кешенең кызыксынуына бәйле. Кешенең ихласлыгы зәгыйфь икән, ул аны төрле сәбәп табып кичектерәчәк. Әмма дә ләкин кеше арыса да, Коръән уку кешегә ял бирә. Коръән ул – рухи азык. Сәхабәләр бит берберсен нәфел намазларын укырга, ял итеп алырга чакырганнар. Шуның кебек, Коръән укып кеше арымый, киресенчә, ял гына итә.

**– Хәзрәт, Коръәнне балаларга ничә яшьтән өйрәтү фазыйләтлерәк? Балаларга авыр да булмасын һәм шул ук вакытта соңга да калмас өчен.**

– Балаларны иртәрәк хәреф танырга өйрәтә башласак, шулчаклы әйбәтрәк. Гарәпләрдә шундый әйтем бар: «Карт чакта ятланган, суга таяк белән сызган кебек булса, ә яшь чакта ятланган ташка уеп язуга тиң». Ягъни ташка уеп язган нәрсә гомерлек, ул үзгәрми. Шуның кебек, яшь чакта ятланганны ул онытмый, искә төшерүе дә җиңел була. Олыгайган яшьтә ятласак, гел кабатлап торасы була.

**– Димәк, 40 яшьләрдә Коръәнне ятлау, ул инде соң? Кеше бит әле Ислам динен шул яшендә генә кабул итәргә мөмкин, ләкин Коръән ятларга зур теләге булуы бар.**

– Сәхабәләргә карасак, алар арасында күбесе Коръәнне 40 яшьләр тирәсендә ятлаганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә дә вәхи 40 яшендә генә иңә башлаган, ягъни ул да Коръәнне шул яшендә генә ятлады. Ләкин шуны да искәртеп үтәргә кирәк, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре дә гарәп телен камил, югары дәрәҗәдә белүчеләр. Сүз дә юк, гарәп телен белү, бигрәк тә камил дәрәҗәдә белү Коръән ятлауны күпкә җиңеләйтә. Әмма дә ләкин 40 яшендә ихлас күңеле белән ятласа, кешенең ихласы һәм тырышлыгы булса, авырлыкларга сабыр итсә, иншәАллаһ, бу кеше булдыра ала.

**– Казанда Коръән ятлау үзәкләре бар дип беләбез. Алар ничегрәк һәм нинди система белән эшлиләр?**

– Мәчетләр каршында эшләп килгән якшәмбе курсларыннан кала, Казанда Коръән ятлау буенча ике зур үзәк бар. Аларның берсе – Рәсәй Ислам институтына бәйле булган «Рәшидә» үзәге. Икенчесе – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә инде ничә еллардан бирле эшләп килә торган Коръән ятлау үзәге. Ләкин хәзерге вакытта мәдрәсәдә яңарту эшләре алып бару сәбәпле, әлегә «Галиев» мәчетендә ятлыйлар.

**– Шушы үзәкләргә керергә теләгән кешеләргә нинди таләпләр куела? Алар гарәп телен белергә тиешме, әллә күпмедер дәрәҗәдә Коръәнне инде яттан белүе шартмы?**

– Без иң элек керүчеләрнең санына карыйбыз. Мәсәлән, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә Коръән-хафизлар өчен билгеләнгән аерым урыннар исәбе бар. Әгәр укырга теләүчеләрнең саны бик күп булса, алар имтихан аша кабул ителәләр. Яшь категориясе дә исәпкә алына, ягъни 9 нчы сыйныфны тәмамлап, кулында аттестация булса, ул укырга керә ала, ләкин бер шарты бар: аз дигәндә Коръәннән берничә сүрәне укый белергә тиеш. Әйткәнемчә, укырга керергә теләүчеләрнең саны күп булган очракта, без аларның имтиханнар тапшыру нәтиҗәләренә һәм тел белүләренә игътибар итәбез. Килүчеләр арасында телне белмәүчеләр дә еш очрый, аларга тәҗвид яки гарәп телен укыту шактый авыр. Укулар рус телендә алып барылганга, укырга керүчеләр Рәсәй тарихы һәм рус теле фәне буенча имтиханнар тапшыралар.

**– Ятлаган Коръәнне онытмас өчен нишләргә кирәк?**

– Кеше Коръәнне ятлагач, ятлау белән генә эш тәмамланмый, ул аның белән гамәл дә кылырга тиеш. Әгәр ул аятьне белә икән, шуның белән гамәл кылса, ул аны онытмый. Әгәр инде кеше Коръәнне ятласа, ләкин гарәп телен белмәсә, Коръәнне ятлап бетергәч гарәп телен өйрәнү бу кешегә вәҗиб хөкемендә була. Хәрәкәләрне бутамас өчен дә гарәп телен белү кирәк. Кеше хәрәкәләрне бутап, сүзнең мәгънәсен үзгәртә. Гарәп телен белү Коръәнне аңлауны да җиңеләйтә. Аллаһы Тәгалә Үзе үк әйтә: «Бу Коръән турында кешеләр фикерләмәсләрмени?» Безнең максат – укып, фикерләп, шуның белән яшәү. Ә инде онытмас өчен һәрдаим кабатлап торырга кирәк, чөнки күп хәдисләрдә Коръән бик тиз кача дип килә. Әгәр дөяләрнең аякларын бәйләп куеп, аларны озак карамый торсаң, алар шул бауларын чишеп качалар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә Коръән ятлауны шуның белән чагыштыра, ягъни гел кабат-

лап тормасаң, Коръән дә кача. Шуңа да онытмау өчен гел кабатлап тору кирәк. Коръән-хафизга ким дигәндә көненә 20 бит кабатлап тору кирәк. Бу бигрәк тә яңа гына Коръәнне ятлап бетергән Коръән-хафизларга кагыла. Ә инде Коръәнне кабатлап торган кеше күпмедер вакыт кабатламый торса да, ул аңа зур зыян китерми. Коръән-хафизлар өчен иң яхшы кабатлау – Рамазан аенда тәравихта Коръәнне хәтем кылу, чөнки Рамазан аенда бик җиңел, Аллаһы Тәгалә Үзе җиңеллек бирә. Тәҗрибәдән дә күргән бар, әгәр кеше 3-4 ел дәвамында шулай Рамазан аенда Коръәнне хәтем чыкса, ягъни Коръәнне тулысынча укыса, ул аны онытмый.

**– Гарәп телен белгән һәм гарәп телен белмәгән кеше өчен дә Коръәнне ятлау нинди фазыйләтләр бирә?**

– Әгәр кеше Коръәнне ятласа, Коръән бу кешенең йөрәгендә була, ягъни ул Коръәнне йөртүче. Ул кешедән Коръәнне беркем дә тартып ала алмый. Коръән белән Аллаһы Тәгалә бу кешегә хикмәт, сәламәтлек, бәрәкәт бирә. Бу бәрәкәт аның киемендә дә, ризыгында да чагылыш таба. Коръәнне гел кабатлап тору хәтерне яхшыртуга да тәэсир итә. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Коръән әле кешене саклый да. Төрле бәлаләрдән, күз тиюләрдән, бозыклыклардан саклый. Болар барысы да бу дөньядагы фазыйләтләре. Коръән ятлауның Ахирәт тормышында фазыйләтләре дә бик күп. Бу турыда хәдисләрдә дә әйтелә. Мәсәлән, бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Фани дөньяда Коръәнне ничек укыган булсаң, Ахирәт тормышында да укы, чөнки һәр укыган аять белән кешенең дәрәҗәсе күтәреләчәк». Җәннәтнең дәрәҗәләре нәкъ менә Коръән аятьләренә тиң. Без җәннәтнең 8 дәрәҗәсе бар икәнен беләбез, ләкин бу дәрәҗәләр әле үз эчләрендә күп төрләргә бүленәләр. Аларның барысын да санап чыгарсак, Коръән аятьләренә туры килә. Кеше Коръәнне күбрәк ятлаган саен югары дәрәҗәләргә күтәреләчәк, иншәАллаһ. Тагын бер хәдистә болай дип килә. Әгәр Коръән-хафиз кеше Коръәнне укып, аның буенча яшәсә, мөэмин булган, ләкин ниндидер гөнаһлары сәбәпле җәһәннәмгә керергә

тиешле булган 10 (ә икенче бер риваятьтә 7) туганын Аллаһының рөхсәте белән шәфәгатьчелек кылып, үзе артыннан җәннәткә алып керә алачак. Бу да бик зур фазыйләт, минемчә. Бу туганнары үзләре иманлы, ләкин гөнаһлары бик күп һәм шул сәбәпле җәһәннәмгә керергә тиешләр. Әгәр бер туганы яки балаларының берсе Коръәнне ятлаган булса, ул аларны җәннәткә алып керә алачак. Җәһәннәмнән котылу бик зур нигъмәт ул. Шулай ук Коръәннең аерым сүрәләрен ятлауның фазыйләтләре хакында да хәдисләр бар. Мәсәлән, «Кем «Әл-Бәкара» сүрәсен еш укып (хәдистә укыса дип килә) торса, Кыямәт көнендә бу сүрә ул кеше өчен болыт кебек булыр һәм гөнаһларына шәфәгать кылыр». Икенче бер хәдистә болай дип килә: «Кем бу дөньяда бик еш «Әл-Бәкара» һәм «Әлү Гыймран» сүрәләрен укыса, алар ике болыт шикелле килер. Бу ике болытның араларында нур булыр һәм укыган кешегә шәфәгать кылырлар».

**– Илнур хәзрәт, хәдистә әйтелгән мондый сүзләр бар: «Коръән синең өчен яки сиңа каршы дәлил». Моны ничек аңларга? Ничек инде Коръән сиңа каршы дәлил булырга мөмкин?**

– Коръәндә безгә Аллаһы Тәгалә Үз кануннарын да әйтә. Әгәр кеше Коръән укып, шул кануннар буенча яшәсә, Коръән синең өчен, ягъни синең яклы дәлил була. Әгәр инде син укып та, укыганнарга каршы килсәң, кануннарга буйсынмый яшәсәң, Коръән инде бу очракта сиңа каршы дәлил булачак.

**– Гакыйдә фәне буенча кабер газабы хакында беләбез. Ялгышмасам, бер хәдистә көн саен «Әл-Мүльк» сүрәсен уку шул кабер газабыннан котылуның бер сәбәбе булып тора дип килә. Бу сүрәне кайчан укырга кирәк?**

– Хәдисләрдә ястү намазыннан соң һәм ахшам намазыннан соң, дип ишеткәнем бар. Шәхсән үзем ястү намазыннан соң укырга тырышам. Хәдистә әйтелә: «Кем төнлә белән «Әл-Мүльк» сүрәсен укыса, бу сүрә бу кешене кабер газапламасын өчен җиңгәнче көрәшер». Монда бер шарт

белән, ягъни көн саен, бер көн дә калдырмыйча. Тагын бер хәдистә «Әл-Мүльк» һәм «Әс-Сәҗдә» сүрәләрен бергә укыса дип килә.

**– Илнур хәзрәт, редакциябезгә килеп, шактый эчтәлекле һәм файдалы мәгълүмат бирүегез, әңгәмәгез өчен Аллаһының рәхмәте булсын сезгә. Алга таба да сезне үзебезнең редакциябезгә кунакка көтеп калабыз һәм киләсе әңгәмәләрдә аерым сүрәләрнең, аятьләрнең фазыйләтләре хакында сөйләшербез, иншәАллаһ. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!**

– Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

*Әңгәмәне Ленар Хамматов оештырды*

# Үрнәк затлар

# Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһе

## Исеме

Әбү Гобәйдә Әмир бине Габдулла бине Әл-Җәррах бине Хиләл бине Ухәйб бине Дәббә бине Әл-Харис бине Фихр бине Мәлик бинеӘн-Надр Әл-Кораши Әл-Фихрий.

## Тууы

Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһе 582/583 елда Мәккә шәһәрендә Габдулла бине Әл-Җәррах гаиләсендә дөньяга килгән. Җәннәт белән шатландырылган ун сәхәбәнең берсе.

## Сыйфатлары

Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһе күркәм йөзле, зифа буйлы, шат күңелле кеше булган. Матурлыгы, күркәмлеге, яктылыгы белән һәрвакыт кешеләрне үзенә җәлеп итә торган булган. Шул ук вакытта ул тыйнак, итагатьле, оялчан, ләкин берәр куркыныч янаган авыр вакытларда ул батыр арыслан һәм үткен кылыч кебек була алган.

## Һиҗрәт кылуы

Беренче мөселманнар кебек үк, Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһегә дә авыр сынаулар аша үтәргә туры килгән. Мәккә җирендәге ислам динен кабул итүче мөселманнарга төшкән кыенлыкларның әчесен һәм төчесен дә татыган ул. Башка мөселманнар кебек ул да диненә тугры булып, бу сынауларга нык торган.

Ислам динен кабул итү белән, гаиләсендә әтисе Исламга каршы булып, улының бу гамәлен кабул итмәгән һәм Әбү Гобәйдәне өеннән чыгарып җибәргән.

Әбү Гобәйдә бине Җәррах иң беренче һиҗрәт кылучылар арасында булган. Башка мөселманнар кебек ул да үз динен саклап калу максатыннан иң элек Хәбәшигә (Эфиопия), соңыннан Мәдинәгә һиҗрәт кылган. Мәдинәдә мөселман дәүләте төзүдә һәм аны ныгытуда үзеннән зур өлеш керткән.

## Ислам динен кабул итүе

Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу анһе Ислам динен Әбү Бәкер Әс-Ситдыйк радыяллаһу анһедән соң икенче көндә үк кабул иткән. Ислам динен кабул иткәнче дә ул дәрәҗәле һәм хөрмәткә лаеклы шәхес буларак танылган. Күркәм сыйфатлары өчен халык арасында аларның икесен дә «Корәешлеләрнең башлыклары» дип йөрткәннәр.

Икенче һиҗрәт вакытында ул Хәбәшидә яшәгән, аннан соң, Бәдер, Өхед һәм башка дәһшәтле сугышларда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән янәшәдә булу өчен, Аллаһының Расүле янына кайткан.

## Аллаһы юлында үтелгән гомер

Аллаһы Тәгаләнең Расүленә тугрылыклы булырга сүз биреп, үз гомерен Аллаһы юлына багышлаганнан соң, Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу анһе чын мәгънәсендә «Аллаһы юлы»ның нәрсә икәнен төгәл белгән һәм аңлаган. Шушы юлда төрле сынауларны үтәргә, төрле каршылыкларга, корбаннарга әзер булган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән үзара килешү йөзеннән кул бирешкәннән соң, Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу анһе үзенә бирелгән гомерне башкачарак кабул иткән. Ул тормышының

барлык мәгънәсен Аллаһы юлында хезмәт итү, тормыш ләззәтләреннән баш тарту һәм төрле каршылыкларга каршы торуда күргән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә аның шушы юлда тырышлыкларына, намуслыгына, төгәллегенә игътибар иткән.

Шулай бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына Нәҗраннан илчеләр килгәннәр һәм Аллаһы Расүленнән ышанычлы булган кешесен үзләре белән җибәрүен үтенгәннәр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларның үтенечләрен кабул итеп, үзенең иң ышанычлы булган кешесен җибәрергә әзер булуын белдергән. Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, әлбәттә, һәр сәхабә Аллаһының Расүле нәкъ менә аны сайлап алыр дип өметләнгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм җыелган сәхабәләр арасыннан Әбү Гобәйдә бине Җәррахның торып басуын үтенгән һәм аның турында түбәндәге сүзләрне әйткән: «Һәр өммәтнең саклаучысы бар. Безнең өммәтнең саклаучысы – Әбү Гобәйдә бине Җәррах!»

Әбү Гобәйдә бине Җәррах ислам дине өчен бик күп хезмәт куйган һәм мөселманнар белән Мәккә мөшрикләре арасында барган барлык сугышларда да катнашкан. Бәдер сугышында ул үз әтисенә каршы көрәшкән, чөнки әтисе мөселманнарга каршы булып, мөшрикләр ягында булган. Риваятьләрдән күренгәнчә, Коръәни Кәримдәге «Әл-Мүҗәдәлә» сүрәсенең 22 нче аяте нәкъ менә Әбү Гобәйдә бине Җәррах һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең башка сәхабәләренә бәйле рәвештә иңгән дип санала.

لَّا تَجِدُ قَوْمًا يُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ يُوَادُّونَ مَنْ حَادَّ اللَّهَ وَرَسُولَهُ وَلَوْ كَانُوا آبَاءَهُمْ أَوْ أَبْنَاءَهُمْ أَوْ إِخْوَانَهُمْ أَوْ عَشِيرَتَهُمْ ۚ أُولَٰئِكَ كَتَبَ فِي قُلُوبِهِمُ الْإِيمَانَ وَأَيَّدَهُم بِرُوحٍ مِّنْهُ ۖ وَيُدْخِلُهُمْ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ

خَالِدِينَ فِيهَا ۚ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ وَرَضُوا عَنْهُ ۚ أُولَٰئِكَ حِزْبُ اللَّهِ ۚ أَلَا إِنَّ حِزْبَ اللَّهِ هُمُ الْمُفْلِحُونَ ﴿٢٢﴾

**«Аллаһыга һәм Соңгы көнгә иман китергән кешеләрне – Аллаһыга һәм Аның пәйгамбәренә дошман булган кешеләрне дус иткән хәлдә тапмассың, хәтта ки алар, аларның аталары яки уллары, яки кардәшләре, яки ырулары булса да. Аларның йөрәкләренә Ул иманны язды [аны нык итте] һәм аларны Үзеннән бер рух [булган һәм җаннарының җаны урынында торган иман һәм Коръән нуры] белән куәтләндерде. Ул аларны [сарайлары һәм агачлары] асларыннан елгалар агып торган җәннәтләргә кертәчәк, һәм алар анда мәңге калачак. Аллаһы алардан разый, алар исә Аннан [Ул вәгъдә иткән әҗер-саваплардан] разый. Алар – Аллаһының тарафдарлары. Әйе, Аллаһының тарафдарлары, һичшиксез, [ике җиһан бәхетен казаначак] уңышка ирешүчеләр».**

«Әл-Муҗәдәлә / Бәхәсләшү», 58:22

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, өммәтебез белән Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе, ә аннан соң Гомәр хәлифә идарә иткән дәверләрдә дә Әбү Гобәйдә бине Җәррах дине өчен төрле сынауларга да каршы торуын дәвам иткән, көчле һәм ышанычлы булып калган. Бу тормышның әчесен-төчесен татыса да, тәкъвалыгы һәм ныклыгы куелган максатларына ирешүдә һәм сайланган туры юлдан баруына нык ярдәм иткән.

Әйткәнебезчә, Әбү Гобәйдә бине Җәррах күп сугышларда катнашкан һәм үзен оста сугышчы буларак таныткан. Һәр сугыш вакытында ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә якынрак булырга тырышкан. Янында була алмаган вакытларында аннан бер дә күзен алма-

ган. Күркәм сыйфатлары өчен Әбү Гобәйдә бине Җәррах Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм алдында гына түгел, күп сәхабәләр алдында да абруй казанган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, Гомәр һәм Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһүмәләргә ишарәләп, Әбү Бәкер Әс-Ситдыйк радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Икесеннән берсе хәлифә булса, мин рәхәтләнеп моны кабул итәр идем. Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһе әле миннән соң да яшәячәк. Мин аны үземнән соң хәлифә буларак калдырачакмын». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вафат булганнан соң, Әбү Гобәйдә бине Җәррах беренче хәлифәләр – Әбү Бәкер һәм Гомәр радыяллаһу ганһүмәләргә ислам дәүләтен төзүдә һәм саклауда нык ярдәм иткән.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе хәлифәлек иткән дәвердә, Шам җирләрен басып алган вакытта, Әбү Гобәйдә бине Җәррах мөселман гаскәре башлыгы булган. Гомәр радыяллаһу ганһе идарә иткән вакытта, Халид бине Вәлид урынына мөселман гаскәрен җитәкләгән. Шам җирләрен басып алганнан соң, ул монда илче буларак билгеләнә. Җирле халык үз җитәкчесеннән бик разый булганнар. Хөрмәт йөзеннән аңа ат бүләк итәргә теләгәннәр, ләкин Әбү Гобәйдә бине Җәррах аларның бүләкләреннән баш тарткан.

Әбү Гобәйдә бине Җәррахның оста җитәкчелегендә Димәшкъ, Хомес, Кодес (Иерусалим) һәм башка бик күп шәһәрләр яулап алынган.

## Искиткеч ихласлыгы һәм тугрылыгы

Үзенә куелган вазифаларны намус белән башкаруы һәм әдәплелеге белән Әбү Гобәйдә бине Җәррах башкалардан шактый аерылып торган. Мәсәлән, Өхед сугышында дошманның төп максаты җиңү түгел, ә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үтерү икәнлеген аңлагач, ул шуңа гел Аллаһы Расүле янында булырга тырышкан. Аңа куркыныч

янаган вакытларда үз-үзен аямыйча мөмкин булганча Пәйгамбәребезне саклаган. Сугышның иң көчәйгән вакытында Әбү Гобәйдә бине Җәррахны берничә мәҗүси камап алган. Шулвакытта ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ук кадалганын күргән һәм дошман кулыннан ычкынып, тиз арада Аллаһының Расүленә ярдәмгә ашыккан. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең битенә кадалган тимерләрен теше белән суырып алган һәм үзенең ике тешен сындырган.

Икенче бер хәрби поход вакытында аңа үз гаскәриләре белән ач хәлендә күп чакрымнар үтәргә туры килгән. Монда да ул сынатмаган, үзен оста, көчле һәм ышанычлы җитәкче буларак таныткан.

## Тыйнаклыгы

Әбү Гобәйдә бине Җәррахның гаскәре көчле һәм башка мөселман гаскәрләренә караганда шактый нык коралланган булган. Гаскәр җитәкчесе булса да, Әбү Гобәйдә бине Җәррахны гади гаскәридән аеруы бик авыр булган, чөнки ул бервакытта да таләпчән булмаган.

Сүриядәге халыкның аның җитәкче булып билгеләнүенә шатланганын белгәч, ул аларны бергә җыеп, түбәндәге сүзләр белән аларга мөрәҗәгать иткән: «Дусларым, мин Кораеш кабиләсеннән булган мөселманмын. Әгәр берәрегез миңа караганда тәкъвалырак һәм гаделрәк булса, мин аның тән төсенә дә карамыйча, шәүлә булып аңа иярәчәкмен».

Күргәнебезчә, Әбү Гобәйдә бине Җәррах тыйнак кына үзен Корәеш кабиләсеннән булган мөселман дип таныштырган. Үз-үзен сыйфатлау өчен шул сүзләр дә җиткән аңа. Ул күпсанлы көчле мөселман гаскәренең җитәкчесе булган, ләкин шундый олы дәрәҗәле кеше булса да, тәкәбберләнмәгән. Чынлыкта, барлык булган дәрәҗәләре аның өчен олуг максатларына ирешү чарасы кебек кенә булганнар.

Бервакыт Гомәр радыяллаһу ганһе Сүриягә килгән һәм үзен каршы алган күренекле кешеләрдән: «Минем Әбү Гобәйдә бине Җәррах

кардәшем кайда?» – дип сораган. Озакламый Әбү Гобәйдә бине Җәррах килеп җиткән һәм Гомәр радыяллаһу ганһене кочаклап, үз өенә кунакка дәшкән. Гомәр радыяллаһу ганһе аның өенә кергәч гаҗәпкә калган, чөнки Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһенең өендә кылыч, калкан һәм иярдән башка бернәрсә дә булмаган. Гомәр радыяллаһу ганһе аннан: «Син үзеңә берәр нәрсә алыр идеңме?» – дип сораган. Әбү Гобәйдә бине Җәррах аңа болай дип җавап кайтарган: «Йоклар өчен өем бар һәм миңа шул җиткән».

Шамда ваба чире тарала башлагач, ул вакытта хәлифә булган Гомәр радыяллаһу ганһе Әбү Гобәйдә бине Җәррахка хат юллаган. Хатында Әбү Гобәйдә бине Җәррахка бер йомышы булуын һәм тиз арада юлга чыгарга кирәклеге хакында язган. Гомәр радыяллаһу ганһенең шушы чирдән сакларга теләгәнен аңлаган Әбү Гобәйдә бине Җәррах җавап хаты язган һәм хатында үз гаскәре белән бергә калу теләге хакында әйткән. 638 елда Әбү Гобәйдә бине Җәррах шушы чирдән вафат булган.

Әбү Гобәйдә бине Җәррахның вафатыннан соң Гомәр радыяллаһу ганһе нык кайгырган, аның белән бәйле булган вакыйгаларны хәтерендә яңарткан. Күз яшьләрен тыя алмыйча Аллаһы Тәгаләдән дин кардәше өчен дога кылып сораган: «Әгәр дә мин теләк тели алсам, мин өйле булуны һәм ул өйнең Әбү Гобәйдә бине Җәррах кебек ирләр белән тулы булуын теләр идем», – дип әйткән.

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

## Яңалыклар

**ОКТЯБРЬ – ДЕКАБРЬ**

# Казанда IX Якупов укулары узды

Быел укулар Вәлиулла хәзрәт Якупов нигез салган «Иман» нәшрияты оешуга 30 ел тулуга багышланды. Җыенны ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Рәсәй ислам институты һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе оештырды. Анда зыялылар, галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре, мәдрәсә җитәкчеләре, Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре, Вәлиулла хәзрәт Якуповның фикердәшләре һәм дуслары катнашты.

## Татарстан мәчетләрендә татар теле дәресләре башланып китте

Сафәр аеның 14 нче көнендә (1 октябрьдә), рәсми рәвештә Татарстан мәчетләре каршындагы курслар кысаларында янәдән татар теле дәресләре башланып китте. Башка еллардан аермалы буларак, яңа уку сезонында тел үзләштерү дәресләре 100 мәйданчыкта оештырыла. Узган уку елында исә татар теле курсларын 436 тыңлаучы уңышлы тәмамлады һәм телне башлангыч дәрәҗәдә үзләштерү хакында сертификатларга лаек булды. Гомумән, Татарстан мәчетләре каршында татар теле курсларын оештыру тәҗрибәсе 2018 елдан бирле тормышка ашырыла. Барлыгы әлеге курсларны 1327 кеше тәмамлады.

## «Таян Аллага» әдәби бәйгесе җиңүчеләрен бүләкләделәр

Бәйге нәтиҗәләрен «IX Якупов укулары» төбәк фәнни-гамәли конференциясе кысаларында игълан иттеләр. Конкурсның махсус бүләгенә Ландыш Әбүдәрова (Казан) ия булды. «Шигърият» номинациясендә җиңүчеләр булып Дания Галәветдинова (Казан), Зилә Таҗитова (Яшел Үзән районы), Рамилә Хәмитова (Лаеш районы), Рәмзия Йосыпова (Казан), Илһамия Гыйззәтуллина (Яшел Үзән районы) табылды. Чәчмә әсәр язучылар арасында Гөлназ Гафарова (Башкортстан), публицистикада Ильяс Хәбибуллин (Мари Иле) җиңде. Бәйге ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Рәсәй ислам институты һәм «Идел» журналы белән берлектә оештырыла.

## Мөфтинең татар телендә «Ислам. 75 дәрес» китабы нәшер ителде

Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йорты, үз укучыларын сөендереп, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның зур популярлык казанган «Ислам в 75 уроках» китабының татарча вариантын – «Ислам. 75 дәрес» китабын бастырып чыгарды. Күпләгән халыкның үтенечен исәпкә алып, нәшрият китапны татар теленә тәрҗемә итте. Җиңел, аңлаешлы телдә язылган бу хезмәт киң катлам укучыларга адреслана.

## Чистайда X Саматов укулары узды

Чара сафәр аеның 28 нче көнендә (15 октябрьдә) Татарстан Республикасы Диния нәзарате, Рәсәй ислам институты һәм Чистай районы мөхтәсибәте тарафыннан Чистайның «Нур» мәчетендә оештырылды. Конференция татар халкының күренекле дини тәгълиматчысы, Татарстанның беренче казые, галим Габделхак хәзрәт Саматовка багышланган иде. Әлеге мәртәбәле җыенда катнашучыларга Габделхак Саматовның «Милләтебездә

Ислам», Ришат Курамшинның «Хикмәтле остаз» (Габделхак хәзрәт Саматов киңәшләре, нәсыйхәтләре) китаплары, «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасы өләшенде. Саматов укулары 2010 елдан бирле үткәрелеп килә.

## Нәзарәт 50-дән артык кешене намазга бастырды

Проект Татарстан мөфтияте тарафыннан 2018 елдан бирле дәгъват эшчәнлеге кысаларында оештырыла. Халык арасында шактый популярлык казанган кыска вакытлы әлеге курсларга язылучылар 7 дәрестә намаз уку күнекмәләрен һәм ислам дине нигезләрен бушлай үзләштерә ала. Дәресләр Галиев мәчетендә һәм нәзарәтнең конференц-залында һәр шимбә көнне узды. Укулар татар һәм рус телләрендә алып барылды һәм барлык санитар-эпидемиология шартларны истә тотып үткәрелде. «Ислам. Беренче адымнар» проектын тормышка ашырган алты сезон дәвамында 600-гә якын кеше белем алды һәм намазга басты.

## Татарстанда Гошер көне – 2020: мохтаҗларга якынча 1 000 000 кг азык-төлек таратылды

Татарстанда 26 сентябрь ТР мөселманнары Диния нәзарате тарафыннан «Гошер көне» дип игълан ителгән иде. Бу уңайдан өч атна дәвамында республиканың барлык үзәк мәчетләрендә гошер садакасын җыю һәм азык-төлекне мохтаҗларга һәм социаль учреждениеләргә бүлеп бирү оештырылды. Әлеге кампания нәтиҗәләренә караганда, бөтен республика буенча якынча 1 млн. килограмм гошер садакасы җыелды. Мөхтәсибәтләр арасында беренче урынны Балык Бистәсе (152 т), Балтач (87 т) һәм Арча (60 т) районнары алып тора. Шулай ук Чирмешән районы (59 т), Саба районы (46 т), Кукмара районы (43 т), Әтнә һәм Буа районнары (40-ар т), Бөгелмә һәм Апас районнары (35-әр т), Чүпрәле районы (34,3 т), Сарман районы (29

т), Теләче районы (27 т), Аксубай районы (26,5 т), Әлмәт районы (20 т) зур активлык күрсәтте.

## Болгарда илебезнең төрле төбәкләреннән җыелган кунаклар катнашында Мәүлид Ән-Нәби узды

Рабигыль-әүвәл аеның 12 нче кичен каршылап, Болгарда пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көненә багышланган традицион Мәүлид Ән-Нәби кичәсе узды. Әлеге уңайдан оештырылган тантаналы чарага Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте дин кардәшләрен инде сигезенче тапкыр җыйды. Соңгы елларда кичә күркәм гадәт буенча Болгар ислам академиясендә үткәрелә. Бирегә голәмәләр, мөфтиләр, мөхтәсибләр, имамнар, ислам белем бирү йортлары мөгаллимнәре, шәкертләр, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләре, Рәсәйнең төрле төбәкләреннән мөселман дин әһелләре килде. Алар Дагыстан, Башкортостан, Коми, ХМАО, Ульян, Сарытау, Иркутск һәм башка өлкәләрдән җыелды.

## «Азан» радиосы сайтында Коръәннең мәгънәви тәрҗемәләрен аудио рәвешендә бушлай күчереп алып була

Диния нәзарәтенең «Азан» радиосы сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көне – Мәүлид уңаеннан тыңлаучыларына бәяләп бетергесез бүләк әзерләде. Татар һәм рус телләрендәге «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» һәм «Калям Шариф. Перевод смыслов» басмаларының аудиоверсияләрен теләгән һәркем бушлай күчереп алырга мөмкин. Аудиоязмалар azan.fm радиостанциясе сайтында урнаштырылган. Фундаменталь хезмәтләрнең аудиоязмалары «Азан» радиосы ре-

дакциясе тарафыннан әзерләнгән. Рус телендәге тәрҗемәләрне 40 сәгать дәвамында Биектау районының Калинин бистәсендәге «Карадениз» мәчете имам-хатыйбы Айбек Токтосопиев укыды, ә татар телендәгесен 35 сәгать дәвамында танылган журналист һәм телетапшырулар алып баручы Илдар Кыямов яздырды.

## Камил хәзрәт Рәсәйнең иң абруйлы мөфтиләре исемлегенә кертелде

Татарстан мөселманнары башлыгы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин «Религия сегодня» мәгълүмати-консалтинг компаниясе тарафыннан Рәсәйнең иң абруйлы мөфтиләре исемлегенә кертелде. Рейтингта Камил хәзрәт 2 урынны били.

Мөселман башлыклары карамакта булган мәчетләр саны, хакимияттә казанган абруеның дәрәҗәсе, Рәсәй мөселманнары арасында хөрмәт ителү һәм чит ил мөселман оешмалары белән мөнәсәбәтләрдән чыгып сайлап алынды.

## ТР МДН Пленумында Туган тел елына беренчел нәтиҗәләр чыгардылар

Лаеш районы «Волга» яшьләр үзәге нәзарәт Пленумының күчмә утырышы уздырылды. Анда мөфтият тарафыннан игълан ителгән Туган тел елына беренчел нәтиҗәләр чыгарылды. Казанышлар арасында – «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» хезмәтенең махсус тираж булып бастырылуы, хезмәтнең рус һәм татар телендә аудиоверсиясе чыгуы, әлеге аудиоязманың Төркиядә җитештерелә торган Коръән каләменә кертелүе, 100 мәчеттә татар теле курслары ачылуы һәм татар телендә онлайн-мәдрәсә эшли башлавы. Пленум утырышында катнашкан Татарстан Президенты каршын-

дагы татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов әлеге эшчәнлекне югары бәяләде.

## Казанда ислам фәннәре буенча Республикакүләм олимпиада ачылды

Татарстан Республикасы дини уку йортлары студентлары Ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча олимпиадасында көч сынашты. Быел әлеге чара Татарстан мөфтияте тарафыннан Казан ислам университеты белән берлектә икенче тапкыр үткәрелде. Белемнәрне сынау бәйгесенә республикабызның барлык мәдрәсәләреннән – Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Кукмара, Буа, Мамадыш шәһәрләре һәм Ютазы районы Урыссу бистәсеннән иллегә якын егет һәм кыз катнашырга теләк белдереп, Татарстан башкаласына килде. Быелгы Республикакүләм олимпиадада мәдрәсә шәкертләре генә түгел, РИИ, КИУ һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең югары курс студентлары да катнашты.

## Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк вафат

Рабигыль-ахыр аеның 5 нче көнендә (20 ноябрьдә), 81 нче яшендә танылган мөгаллим, күпсанлы китаплар авторы Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк вафат булды. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин бу сәбәптән мәрхүмнең якыннарының кайгысын уртаклашты. Җәгъфәр хәзрәт совет чорында ук дин юлында хезмәт итә башлый һәм 60 тан артык исемдә китап бастыра. Алай гына да түгел, ул – революциягә кадәр татар галимнәре тарафыннан язылган дини-фәнни хезмәтләрне өйрәнеп, кириллицага күчереп, беренчеләрдән булып халыкка җиткерүче. Хәзрәт Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә озак еллар дәвамында хезмәт куйган остаз. Дингә ирек бирелгәннән соң, узган гасырның 90 нчы елларыннан Җәгъфәр хәзрәттә күп кенә булачак


мөфтиләр, дин әһелләре, имамнар белем алган. Аллаһы Тәгалә Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәкнең белеп һәм белми кылган гөнаһларын гафу әйләсен, урынын җәннәттә кылсын!

## Нәзарәт Рәсәй төбәкләренә Коръәннең татарча мәгънәви тәрҗемәләре белән «китаплы рейслар» җибәрде

Диния нәзарәте «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасының тиражын Рәсәй төбәкләренә җибәрде. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин йөкләмәсе буенча, Коръән мәгънәләренең татар теленә тәрҗемәләре Туган тел елы кысаларында татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдәге милләттәшләр өчен 40 меңлек максатлы тираж буларак дөнья күргән иде. Хәзер китап читтә яшәгән татарлар арасында бушлай таратыла башлады. Мисал өчен, китаплар Иваново мөфтияте, Рәсәйнең Азия өлеше мөселманнары Диния нәзарәте, Сарытау, Ханты-Манси, Омск шәһәре һәм Омск өлкәсе, Иркутск өлкәсе, Коми Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтләренә җибәрелде. Моннан тыш, басма Рәсәй мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте, РФ мөселманнарының Диния нәзарәте һәм Рәсәй мөселманнарының Дини җыены адресына юлланды. «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» шулай ук дини булмаган татар оешмаларына да җибәрелде. Алар арасында – ТР Санкт-Петербург шәһәрендә һәм Ленинград өлкәсендәге вәкиллеге, «Штаб татар Москвы».

# Тарих

# Татарларның Таллиндагы янгын сүндерү депосын мәчет итүләре




*Эстония татарларының тарихы*

Алдагы саннарда без төньяк Балтыйк илләренә ислам диненең үтеп керү тарихы һәм XIX гасырда татарларның Эстониядәге тормышы турында язган идек. Әлеге мәкаләне дәвам итеп, Эстониядә татарларның XX гасырның беренче яртысындагы тормышы турында бәян итик.

1860 елда татар сәүдәгәрләре, нигездә, Эстониянең өч шәһәрендә төпләнгән. Алар: Нарве, Таллин һәм Раквере шәһәрләре. Өстәвенә, иң алга киткәннәре булып, Нарведагы татар җәмәгатьчелеге санала. Бу шәһәрләрдә татарларның даими яшәүләренең бер күрсәткече – аларда мөселман зиратларының булуы.

1897 елда Беренче Халык санын алу мәгълүматларына караганда Таллинда 109 татар кешесе яшәгән. Әмма хәрби хезмәттә булучылар әле исәпкә кертелмәгән. Шуңа күрә чынлыкта татар-мөселманнарының саны күбрәк булган. Кайбер фикерләргә караганда, 1914 елда Таллинда чама белән 2000 татар яшәгән.

XIX һәм XX гасыр чикләрендә татар җәмәгатьчелегенең саны шулхәтле арткан ки, хәтта дини бәйрәмнәр вакытында зур биналар

арендалау ихтыяҗы туган. Мәсәлән, Эстония татар җәмәгатьчелеге җитәкчеләренең берсе булган Надира Айзатуллина (1928-2007) хәтирәләреннән, XX гасыр башында, бәйрәм намазын үткәрер өчен, Таллин татарларының янгын сүндерү депосын арендалаганы билгеле. Бу бина шәһәрнең үзәгендә урнашкан Виру мәйданында була.

Депо бинасы бүгенге көнгә хәтле сакланып калган. Әгәр дә бинаның архитектурасына игътибар итсәк, ул ачыктан-ачык мәчет бинасын хәтерләтә, чөнки манарага охшаган каланчасы бар. Шуңа күрә татарларның әлеге бинаны арендалавы юкка гына түгел.



*Элеккеге янгын сүндерү депосы.*
*Хәзерге заман фотосы*

Эстониядә төпләнүче татарлар үзләренең туган яклары булган Идел буе белән элемтәдә булырга һәм якташларына ярдәм итеп торырга тырышалар. Мәсәлән, сәүдәгәр Закир Закиров (Zakir Zakerov) Эстониядә XIX гасыр азагында төпләнә. Аның Таллин үзәгендәге Виру мәйданында шәхси кибете була. Закиров янында һәрвакытта да, укучылары буларак, Түбән Новгород губерниясеннән булган алты-җиде, ә кайвакытларда уникеләп якташы була. Биредә алар сәүдә кәсебенә һәм рус теленә өйрәнә. Укыту, гадәттә, ике елга сузыла. Бер ай дәвам иткән яллар вакытында укучылар туган авылларына кайтып килергә өлгерә.

1917 елгы революциягә кадәр Эстония татарлары арасында иң хөрмәтле һәм бай кеше булып Сибгатулла Мәһдиев (Sigbatulla Magdejev) санала. Җирле халык аны «татар короле» дип атый. Сибгатулла Мәһдиев Таллинга 1885 елда килеп, тиз арада бай һәм уңышка ирешкән сәүдәгәргә әйләнә. Аның байлыгы тире, келәм һәм зәркән (ювелир) эшләнмәләре белән бәйле була. Ул Санкт-Петербург, Псков белән эшлекле элемтәләрдә тора. Заказ бирүчеләре арасында хәтта зур кенәзләрнең дә булуы билгеле.

Мәһдиев Таллин шәһәр зираты янәшәсендә җир участогы сатып алып, анда аерым мөселман зираты булдыра. Зират таш дивар белән әйләндереп алына, ә тимер капкалары ислам символы булган ярымай белән бизәлә. Бөек Ватан сугышы вакытында зират бомбалар астында кала. Кызганычка, 1950 еллар башында зират тулысынча юкка чыгарыла. Шуңа да карамастан, зиратның иске диварлары сакланып калган.

Беренче Бөтендөнья сугышы, патша хакимиятенең бәреп төшерелүе һәм гражданнар сугышының ыгы-зыгылары аркасында Таллин татар җәмәгатьчелегенең кешеләре саны кими. 1918 елның 24 нче февралендә Рәсәй империясенең таркалуыннан соң, Эстония үзенең бәйсезлеген игълан итә. 1928 елда Нарведа рәсми рәвештә беренче ислам җәмәгатьчелеге оеша.

Татарлар Нарведа зур агач йорт сатып алып, аннан мәчет ясыйлар. Нарве җәмәгатьчелеге актив рәвештә татар милли үзаңын саклап калырга тырыша. Ислам җәмәгатьчелегенең икенчесе 1939 елда Таллинда теркәлә. Ислам җәмәгатьчелегенең барысының да эшчәнлеге тыела. 1944 елда, сугыш вакытында ике җәмәгатьчелекнең дә биналары җимерелә. Совет чорында ислам җәмәгатьчелеге рәсми булмаган рәвештә үз эшчәнлеген алып бара: намазлар укыла, дини йолалар үткәрелә, дини бәйрәмнәр билгеләп үтелә.

# Беренче бөтендөнья сугышы: татар солдатлары күргән авырлыклар



*Яшь мөселман солдатларының хәрби ант бирүләре*

1914 елның 1 нче августында Алмания Рәсәйгә сугыш игълан итү белән, Беренче бөтендөнья сугышы (1914-1918) башлана. Иң зур хәрби конфликтта катнаша торган илләр XX гасыр башында ике лагерьга бүленә. Өчлек союзына Алмания, Австро-Венгрия һәм Госманлы империяләре, ә Антантага исә Рәсәй һәм Британия империяләре һәм Франция республикасы керә.



*Татар морзалары нәселеннән булган Зөлкарнәен Дашкин. Ул Беренче бөтендөнья сугышында 14нче Ырынбур казак полкын җитәкләгән*

Бу сугышны юкка гына «Беренче бөтендөнья сугышы» дип атамаганнар, чөнки бередә 70 миллионнан да күп кеше катнашкан. Шуларның 10

миллионы сугыш кырында мәңгелеккә ятып калган. Кайбер фаразлар буенча, гражданнар арасында корбаннар саны 12 миллионга җиткән. Беренче бөтендөнья сугышын «империяләр зираты» дип тә атыйлар, чөнки бу сугыш аркасында Рәсәй, Госманлы, Австро-Венгрия һәм Алмания кебек зур империяләр юкка чыккан.

Бу сугышта Рәсәй империясенең мөселман гражданнары да катнашкан. Петр патша заманыннан алып, татарлар Рәсәй армиясенә чакырыла торган булган. Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан, түбән катлау мөселман татарларының якынча 40 меңе Рәсәй армиясе сафларында хезмәт иткән. Бу барлык түбән катлау кешеләренең 3%нан бераз күбрәге иде.

Ислам динендә булган күпчелек офицерлар татар милләтеннән булган. Ә гомуми мобилизация игълан ителгәннән соң, хәрби хезмәткә чакырылучы солдатлар саны йөзләрчә меңгә җитә башлаган. Кайбер мәгълүматларга караганда, Беренче бөтендөнья сугышында 1 миллионга кадәр татар солдаты катнашкан. Сугыш вакытында Рәсәйдә 19 миллион кеше мобилизацияләнгән, бу ил халкының 10% тан артыграгы иде.

Аерым полклар булып формалашкан кавказ мөселманнарыннан үзгә буларак, татарлар катнаш гаскәрләрдә хезмәт иткәннәр. Шуңа күрә хәрби тормышның начар туклану, һава торышы үзгәреп тору, йокы туймау һәм шуның сыман калган авырлыклардан тыш, мөселман татарларына башка өстәмә кыенлыклар белән дә очрашырга туры килә. Мәсәлән, тел белмәү аркасындагы уңайсызлыклар, милли яктан кысрыклаулар, татар телендә аралашуда тыюлар, рационда күпләп яшелчә куллану (ул вакытта татарлар бик аз күләмдә яшелчә ашаганнар), пешекчеләрнең дуңгыз итен әзерләүләре, хәрби имамнарның юклыгы һ.б. бик күп мәшәкатьләр мөселман татарларының тормышын бик нык катлауландырган.

Авыр вакытларда кеше рухи азыкка тагы да мохтаҗ була. Мөселман татарлары мәрхүм булган солдатларны озату, җомга һәм бәйрәм намаз-

ларын үткәрү өчен генә түгел, ә яу кырында рух ныклыгын күтәрү һәм тәртип булдыру өчен дә хәрби имамның кирәклеген белдерәләр. Чөнки сугыш кешелек кыйммәтләрен юкка чыгара. Шуңа да кешегә рухи һәм әхлакый яктан нәсыйхәтләр бирелү ихтыяҗы туа.

Бары тик 1916 елда Николай IIнең указы белән Рәсәй гаскәрләренә штатлы дивизион муллалар вазифасы кертелә.



*Беренче бөтендөнья сугышы. Мөселман солдатлары намаз укый*

# Император гаиләсенең шәхси кучеры

## Әҗе авылыннан булган татар кешесенең император гаиләсендә кучер булып хезмәт итүе



Белүебезчә, революциягә кадәр Царское село һәм Патша Сараенда император йортында билгеле бер вазифалар башкаручы татарлар хезмәт иткән. Аларны барыннан да бигрәк хезмәт сөючән, аз сүзле, намуслы һәм пөхтә булганнары өчен яратканнар. Татар хезмәтчеләре янәшәсендә төрле мәсьәләләр хакында сөйләшә алганнар, чөнки Романовлар сөйләнгәннәрнең читкә чыкмавына тулысынча ышанган.

1856 елны Әҗе исемле татар авылында (хәзерге Рязань өлкәсе), ярлы крестьян гаиләсендә туып үскән Сәйфулла Хәбибулла улы Борнашевның

тормышы аеруча да игътибарга лаек. Әҗе XX гасыр башында зур авыл булган. Биредә җиде мәчет һәм ике мөселман мәктәбе эшләгән.

Гаилә әһелләренең сөйләвенчә, авылның бер имамының улын хәрби хезмәткә алырга тиеш булганнар. Ул Сәйфулла Борнашевның әтисе Хәбибуллага, үз улын җибәрсен өчен, 25 көмеш тәңкә акча тәкъдим иткән. Хәбибулла әфәнде моңа ризалашкан.

Сәйфулла уртача буйлы кешедән озынрак гәүдәле, төз, киң җилкәле, кара чәчле, өстәвенә, атта оста йөри белүче кеше була. Үзенең билгеләре белән ул тулысынча гусарлар өчен куелган таләпләргә туры килә, һәм, нәтиҗәдә, гусарлар полкына алына. Армия сафларында хезмәт иткәндә Сәйфулла Борнашевка Николай IIнең абыйсы, император Александр IIнең улы – бөек князь Алексей Александр улы игътибар итә. Ул аны үзенә кучер итеп хезмәткә ала.

Уңайлы булсын өчен князь үзенең кучерын русчалаштырып, Степан Николаевич дип йөртә башлый. Алексей Александр улы үзе зиннәтле сарайда яши, флот адмиралы дәрәҗәсендә санала һәм Рәсәй империясенең иң бай кешеләренең берсе булып тора.



*Сәйфулла Борнашев гаиләсе (А.Б. Беляевнең шәхси архивыннан)*

Ул Сәйфулланы эшне төгәл башкаруы өчен генә түгел, баһадирдай гадәттән тыш көче һәм тугрылыгы өчен хөрмәт иткән, дип әйтәләр. Әмма, моннан тыш, Сәйфулла Борнашев горур холыклы кеше була. Берьюлы ул, бөек князь сәфәрдә булганда князьнең утарында идарә итүче белән бәхәскә керә һәм барысын да ташлап, үзенең туган авылы Әҗегә

кайтып китә. Моның хакында белгән князь Мәскәү генерал-губернаторына Сәйфулла Борнашевны эзләп табуларын сорап телеграмма җибәрә. Нәтиҗәдә, аны табып Петербургка кайтаралар. Моннан соң Алексей Александр улы еш кына Сәйфулла Борнашевка карап: «Йә, Степан, оят түгелме сиңа, мин китәргә дә өлгермәдем, ә син югалгансың», – дип әйтә торган була.

Сәйфулла Борнашев куе кара сакаллы кеше иде. Иң мөһим атрибутларының берсе: Романовлар династиясе бүләк иткән, Рәсәй империясе гербы төшерелгән алтын чылбырлы сәгать булган. Невский проспекты буйлап йөрергә чыккан Сәйфулла Борнашев чуклы төрек баш киемен кигән. Бу бик күпләрнең игътибарын җәлеп иткән.

Сәйфулла Борнашевның сигез улы була. Һәрберсенең тууыннан соң Алексей Александр улы үзенең кучерын 50 сум акча белән бүләкли торган иде. Үз вакытына күрә бу зур акча була. Петербургта С. Борнашев йортның тулы бер катын биләп торган биш заллы киң фатир булдыра. Ул балаларын укытуга зур әһәмият бирә. Аларны тәрбияләр өчен татар милләтеннән булган махсус гувернантка яллана.



*Сәйфулла Борнашев (А.Б. Беляевнең шәхси архивыннан)*

1908 елда бөек князь Парижда грипп авыруыннан үлә. Үлеме алдыннан үзен кучер Степан җирләвен васыять итеп калдыра. Һәм император Нико-




*Әҗе авылы (хәзерге Рязань өлкәсе)*

лай IIгә киләчәктә кучерын үзенә хезмәткә алырга куша. Император бу үтенечне үти: Сәйфулла Борнашев Николай IIгә кучер булып билгеләнә. Патша аны бик юмарт бүләкли һәм ул эшләп тапкан акчаларына Әҗедә ике катлы йорт төзи һәм тегермән сатып ала. Бу аны лаеклы ялга чыкканнан соң да җитеш тормыш белән тәэмин итәргә тиеш була.

Әмма 1917 елда килеп чыккан революция бик күпләрнең тормышын үзгәртә. Рәсәйдән күченеп китәргә чакыруларына карамастан, Сәйфулла Борнашев туган иленнән китми. Ул җыйган малының күп өлешен югалта, тик үзенең эшенә тугры кала. Моннан соң ул император каретасы белән түгел, совет хөкүмәте әгъзаларының пролеткасы белән идарә итә. Сәйфулла Борнашев 1933 елда 77 яшендә вафат була. Аны туган авылы Әҗенең мөселман зиратында җирлиләр.



*Равилә Хәлил кызының яшь вакыты*

Моның белән Сәйфулла Борнашев гаиләсенең тарихы тәмамланмый. Әгәр ул үзе Рәсәй империясенең соңгы императорында кучер булып хезмәт итсә, аның икенче улы – Вәли Борнашев Совет Рәсәенең беренче җитәкчесе Владимир Ленинның шәхси шоферы була. Ә ике оныгы: Тәлгать (Вәли Борнашевның улы) һәм Җәгъфәр (Хәлил Борнашевның улы) очучылар булып, Бөек Ватан сугышы вакытында хәрби очкычлар белән идарә итә. Ә оныгы Равилә Хәлил кызы Борнашева медицина фәннәре докторы, Татарстанда танылган табиб-аллерголог була. Ул Казан Аллергология мәктәбенә нигез сала.

# Рус императорларын Ислам белән таныштырган беренче кеше

XVIII гасыр башына Рәсәй империясе Исламга аеруча да кызыксыну белдерә башлый. Моңа Петр I нең мөселман илләре белән сәүдә элемтәләрен җайларга теләве дә, ислам динен тотучы гражданнарны аңларга тырышуы да, шулай ук Рәсәйнең Госманлы империясе һәм Иран белән сугышлар барлыкка килүгә китергән, көньяк чикләрендәге геополитик активлыгы да йогынты ясый.

Югары катлам кешеләрен Ислам дине белән таныштыруда Рәсәйнең һәм Молдавиянең танылган галиме, Петр I заманында дәүләт эшлеклесе һәм дипломат Дмитрий Константин улы Кантимер (1673-1723) зур роль уйный. Ул Молдавиянең хөкүмәт җитәкчесе Константин Кантимер улы, ә аның бабасы – татар морзасы Кантимер, Нугай Урдасына нигез салучы Алтын Урда башлыгы Идегәй нәселеннән була.


Константин Кантимер идарә иткән елларда Молдавия Госманлы империясенә вассал рәвештә, ягъни икътисадый һәм сәяси яктан бәйле иде. Ул вакытлардагы традицияләр буенча, 15 яшьлек Дмитрийны Стамбулга тоткын итеп җибәрәләр. 1693 елда ул кыска вакытка Молдавия җитәкчесе булып ала, әмма озакламый вазифасыннан алына һәм яңадан Стамбулга җибәрелә. Госманлы башкаласында булган вакытта Дмитрий төрек, гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнә. Ул үз заманының бик укымышлы кешесе була. Санап үтелгән көнчыгыш телләреннән тыш, ул молдав, латин, рус, грек, итальян һәм француз телләрен дә белгән. Үз вакытында хәтта Петербургтагы Фәннәр Академиясе президенты вазифасына кандидат буларак та каралган.

Госманлы империясе белән Рәсәй арасында барган сугыш вакытында, 1710 елда Дмитрий Кантимер Молдавия господаре (Молдавия җитәкчесе титулы) була. Әмма үз илен Госманлыларга бәйлелектән азат


итәргә теләп, Петр I белән союз төзи һәм руслар ягына күчә. Моннан соң ул Петербургта, Мәскәүдә һәм Дмитровкадагы утарында (хәзерге Орловка өлкәсе) яши һәм эшли.

1719 елда Дмитрий Кантимер тарафыннан «Книга Систима, или Состояние мухаммеданския религии» («Sistema de religione et statu Imperii Turcici»), шулай ук «Система турецкого вероисповедания» исеме белән танылган китап языла. Аның нигезенә Кантимер «Коран» («Curanus») китабының латин текстын куллана. 1722 елда китап Иван Ильин тарафыннан латин теленнән рус теленә тәрҗемә ителә. 1722 елның 18 июлендә Петр I дини эшләр белән идарә итә торган төп орган – Синодка аны кичектермичә басмага куярга һәм Каспийдагы армиягә җибәрергә куша. 1722 елның 22 декабрендә китап нәшер ителә. Бу – императорның түземсезлек белән китапның басылуын көткәнен күрсәтә.

Бу китап Ислам турындагы бар мәгълүматны үз эченә алган рус телендәге беренче хезмәт. Дмитрий



*Царицынода Дмитрий Кантемирга куелган һәйкәл*


КНІГА

СѴСТІМА

ИЛИ

СОСТОЯНІЕ

МУХАММЕДАНСКІЯ РЕЛІГІИ.

НАПЕЧАТАСЯ ПОВЕЛѢНІЕМЪ ЕГО ВЕЛІЧЕСТВА

ПЕТРА ВЕЛІКАГО

ІМПЕРАТОРА И САМОДЕРЖЦА ВСЕРОССІИСКАГО.

ВЪ ТѴПОГРАФІИ ЦАРСТВУЮЩАГО

САНКТЪПІТЕРБУРХА.

Лѣта 1722, Декабря вЪ 22 день.

*«Книги Систима»ның беренче бите*

Кантимер аны көнбатыш Аурупа һәм рус чыганакларына гына түгел, ә мөселман чыганакларына һәм шәхси күзәтүләренә дә таянып яза. Кантимер үзенең китабында Исламны гомуми үзенчәлекләрдә аңлата, әмма күп вакыт Стамбулда яшәгәнгә күрә, төрекләр арасында таралган Исламның үзенчәлекләренә зур игътибар бирә. Мәсәлән, Дмитрий Кантимер Изге Коръән Китабы турында түбәндәгеләрне яза:

«Куран сложен есть на Арапском языке, изряднейшим штилем, и по болшеи части рифмическим, речию Арапскою, так глубокою, что не токмо подражать того, всячески несть мощно, но и ко истолкованию зело труден есть, паче же рещи, весма не объятен. Аще сам Муфти, или кто от ученнеиших Турков, и в Арапском языке искуснеишии, вопрошен бы был, может ли хотя един каковыи стих, или Сентенцию Курана, по словам и по разуму купно, и совершенно разумети? по правде ответствуют, что никакоже разумеют, но отсылают к древнеишым Курана толкователем, и в них слова, или Сентенции, о которых сумнение есть, искать повелевают».

Рәсәйнең югары җәмәгатьчелеге китапны төрлечә кабул итә. Кайберәүләр, автор Ислам турында артык яхшы фикер белдерә дип саный. Гәрчә Кантимер христиан динендә була һәм исламга христиан дине күзлегеннән карап язган була. Әмма үзенең күп әйберләргә аек акыллы карашы белән, бу хезмәт шул чорның башка христиан хезмәтләреннән аерылып тора. Биредә Кантимер үзен Ислам белгече, шул исәптән Коръән, суфичылык, гарәп, фарсы, госманлы телләре белгече буларак күрсәтә алган.

Һичшиксез, Кантимерның китабы үз вакыты өчен алга киткән хезмәт була. Көнбатыш Аурупада «Книги Систима» кебек хезмәт 150 ел үткәч кенә языла. Ул И. Гольдциерның немец телендә язылган «Магометанские исследования» (Halle, 1889–1890) китабы була.

*Мөхсин Нурулла язмалары,*

*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Мирас

# Борындык мәчете

Халкыбызның дини һәм мәдәни тормышында, аның мәгърифәти, рухи-әхлакый үсешендә мәчетләр гаять мөһим роль уйный.

Авылыбыз Борындык элек-электән үк мәгърифәт учагы булуы белән тирә-юньдә дан тоткан. Бу уңайдан Каюм Насыйри мондый мәгълүмат бирә: «Борындык бик күптәнге иске авылдыр һәм иске заманда бик бай авыл булгандыр. Фабрика һәм завод тотучы байлар күп булган. Зур мәдрәсәләр булып, дәрес әйтүче мөдәррисләр, галимнәр була килгән. <...> Борындыкта бер бик галим кеше булган икән, тәхминнән 1720 нче елларда вафат булгандыр. Яки 1700 нче елларда. Мансур дигән бер гаярь кеше булган, Мансур ахун, диерләр икән. <...> Каргалыга барып тәгълим алган икән. Аннан кайтып, Борындыкта берничә заман дәрес әйткән. Нәхү гыйлеменә бик оста – маһир кеше булган. «Мансурия» дигән тәркип шәрхен тасниф кыйлган кеше шул Мансур ахундыр».

Димәк, XVII гасырда ук инде Борындыкта мәчет-мәдрәсәләр гөрләп эшләгән. Мөгаен, Ислам дине, Болгар дәүләте җимерелгәннән соң, XIII гасырда ук бу якларга килеп авылга нигез салган Борындык бабай белән таралгандыр. «Мансур мулла нахак гаеп белән төрмәгә утыртылганнан соң, Борындыкта мәчет-мәдрәсәләр эшләгәнме икән соң?» дигән урынлы сорау туа, чөнки бу вакытта элеккеге Казан ханлыгына кергән җирләрдә Ислам диненә каршы сәясәт алып барыла, мәчетләр җимерелә, халык көчләп чукындырыла.

1773 елда Екатерина II нең дин иреге турында указы чыга. 1778 елда Рәсәй дәүләтенең Оренбург каласында бер мөфти һәм өч казыйдан торган «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе» ачыла. 1788 елда дини идарә Уфа шәһәренә күчерелә. Рәсәйнең беренче мөфтие итеп безнең авыл мулласы Мансур ахунның оныгы Мөхәммәтҗан бине Әл-Хөсәен бине Мансур бине Габдрахман бине Әнәс Әл-Җәбәли Әл-Борындыкый билгеләнә. Ул бу ва-

зифада 50 елга якын идарә итә. Мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов тырышлыгы белән Россиядә бик күп мәчетләр төзелә, Ислам дине үсеше өчен шартлар тудырыла. Ә менә Борындыкта мәчет һәрвакыт эшләгән булса кирәк. Ни өчен дигәндә, бары тик Мансур мулладан соң гына кемнең мулла булып торуы билгесез, ә аннан соңгыларының исемнәре тарихи истәлекләрдә сакланып калган. Шулай булгач, Борындыкта азан тавышы гасырлар дәвамында тынып тормаган дияргә була.

XIX гасыр урталарында Борындыкта ике мәчет булганлыгы мәгълүм: аларның берсе – Бәрленең сул ягында, ә икенчесе уң ягында урнашкан була.

Борындык авылына беренче мәчет салдыруны Яшел Үзән районы Акъегет авылыннан Заһидулла Шәфигуллин (1840-1919) исемле бай үз өстенә ала. 1869 елда Бәрле елгасының сул ягында нарат бүрәнәләрдән мәчет салына. 69 ел дәвамында авыл халкына хезмәт иткән Агач мәчет 1938 елда манарасы киселеп эшләвеннән туктый. Шулай да мәчет урынында 32 ел берөзлексез башта җидееллык, аннары сигезьеллык һәм урта белем бирү мәктәбе була. Аннары бу нигездә балалар бакчасы оеша, һәм анда 28 ел дәвамында яшь буын тәрбия ала.

Шулай итеп, күп еллар дәвамында биредәге җир авылыбыз халкына игелекле хезмәт күрсәтелүнең тере шаһиты булып тора. Агач мәчетне сүтеп, материалларын яңа мәктәп төзелешендә файдаланалар.

Борындык авылы халкының кирпечтән икенче мәчет төзүгә рөхсәт сорап язган үтенеч-мөрәҗәгатен Казан губерна идарәсе 1893 елның 16 нчы октябрендә канәгатьләндерә һәм төзеләчәк мәчетнең проектын раслау турында карар чыгара. Мәчетнең проекты Оренбургта раслана, Мәскәүдә Диния нәзарәтендә теркәлә. Төзүчеләр читтән килгән осталар була. Ярдәмче эшләргә авыл халкы җәлеп ителә. Төзелеш өчен ташны Зөя елгасы аръягыннан, Стрикау тавыннан (тауның исеме русчадан «стрелоклар», ягъни «укчылар» дигән сүздән алынган) чыгарып, атлар белән

ташыйлар. Икенче таш мәчетне төзү эшләре 1893 елда башланып, 1895 елның июлендә тәмамлана. Шулай итеп, 1895 елда икенче мәхәллә оеша. Анда ул вакытта 352 ир-ат һәм 348 хатын-кыз исәпләнә. Беренче мәхәллә мәктәбендә 128 (78 ир һәм 50 кыз), икенче мәхәллә мәктәбендә 100 (70 ир бала, 30 кыз) шәкерт дәресләр алган.

Оренбург шәһәренең беренче гильдия сәүдәгәре Әхмәт Гали улы Хөсәенов мәчет төзелешенә бик зур матди ярдәм күрсәтә. Ул чыгышы белән Борындыктан булгандыр, дигән фикерләр дә бар, чөнки Борындык мәчетенә мулла билгеләүдә аның фикере хәлиткеч роль уйнаган. Өстәвенә, аңа тагылган «Суслик» кушаматы да бу фаразларның дөреслегенә ишарәли кебек. Мәчет төзелешеннән тыш, сәүдәгәр мәхәлләнең руханиена хезмәт хакы билгеләргә тиеш була, ул өч ел дәвамында муллага елына 100 сумнан түләргә ризалаша. Ә Әхмәт Хөсәенов үз чиратында мулланы аның фатихасы белән билгеләү шартын куя. 1937 елда таш мәчетнең манарасын кисеп төшерәләр. Манарасы киселгән таш мәчетне башта мәдәният йортына, аннары Көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатына әйләндерәләр.

## Мәчет манарасын кисүчеләр



1937-1938 еллар. Бу елларда ил күләмендә татар авылларындагы мәчетләрнең манараларын кисү шаукымы башлана. Бу шаукым Борындыкны да читләтеп үтми. 1937 елда башта Таш мәчетнең манарасын кисеп төшерәләр. Бу эшне башкаруны башта авылның сөйләшә алмаучы телсез кешесе Бикмуллин Гаделшадан таләп итәләр. Ләкин ул бу эштән баш тарта, риза булмый, төрлечә янауларга да бирешми. Ул тыңламагач, Кәримов Гарәфетдин атлы кешегә кушалар. Кәримов Гарәфетдиннең Со-

вет хөкүмәте каршында ниндидер гаебе булгандыр, шуңа аны көчләп мәҗбүр иткәннәрдер дип фаразлыйлар. Бу абзыйга ике юлның берсен сайларга туры килә: йә гомерлек төрмә, йә мәчет манарасын кисү. Ул, үз гомерен саклау хакына, соңгысын сайлый.

Агач мәчет манарасын колхоз рәисе булып эшләүче Нигъмәтҗанов Нургали дигән кеше 1938 елда кисеп төшерә. «Күрәсең, ул заманасына карата «үтә кызыл» булгандыр, бәлки, башкалар тыңламагач, үзе кисәргә мәҗбүр булгандыр,» – дип яза Бикмуллин Равил истәлекләрендә.

Манараларны кискәндә, авыл халкы арасыннан берәү дә каршы чыгып сүз әйтми. Мәчет янында хатын-кызлар, карчыклар, балалар күп җыела. Манараны кисеп төшергәч, карчыклар, хатыннар бик елашалар. Ул вакытта 9-10 яшьләрдә булган мәчет картлары бу күренешне бик яхшы хәтерлиләр.

Мәчет манаралары киселсә дә, халык дин тотудан туктамый. Алар намазларын, җомга-гаетләрне авылыбызның аерым өйләрендә качапоса җыелып укырга мәҗбүр булалар. Бу эшне беренче Гарәфетдинова Мөнирә апалар йортында башлыйлар. Аннары Гатауллин Гарифулла һәм Нигъмәтуллин Нурулла бабайлар йортларында укып йөриләр. Алар дини йолаларны шәригать кушканча үткәрергә тырышалар. Гает намазлары җәй көненә туры килсә, качып зиратта укыганнар.

## Таш мәчетне яңадан торгызу

1991 елның июль аенда илле өч ел дәвамында авыл халкына мәдәният һәм көнкүреш хезмәте күрсәткән таш мәчет бинасына манара урнаштырыла, бинаның эчендә төзекләндерү эшләре алып барыла. Мәчетне яңадан торгызу эшләрен мулла Гарифуллин Бари Гарифулла улы башлап йөри. Авыл Советы рәисе Әфлиев Рөстәм Әгъләм улының өлеше дә искиткеч зур була.

Таш мәчетне яңадан торгызуга фидакарь хезмәтләрен кертүче авылдашларыбыз арасында Гарифуллин Фаил Кәбир улы җитәкчелегендәге бригада әгъзалары – Низамиев Мансур Ярхәметдин улы, Мөхәммәтҗанов Искәндәр Галәветдин улы, Сәгъдиев Равил Зиатдин улы, Әхмәтҗанов Равил Сабирҗан улы һәм Җиһангиров Шәйхулла Кәлимулла уллары була.

2008 елның 13-17 нче август көннәрендә мәчеткә газ кертелә. Бу изге эш Казан шәһәренең «Ялкын» ачык акционерлык җәмгыяте төзелеш оешмасы тарафыннан башкарыла. Аның җитәкчесе Рафаэль Котыб улы Фәсәховның да турыдан-туры ярдәме бик зур була. Авыл җирлеге Советы рәисе Сафиуллин Равил Нуретдин улы һәм күмәк хуҗалык рәисе Сибгатуллин Шәүкәт Сөнгать улы кәгазь эшләре белән Кайбыч, Буа, Казан шәһәренә һәрдаим йөреп торалар, мәчет әһелләренә бу өлкәдә борчылырга туры килми.

Мәчетне газлаштыру тулысынча авыл халкыннан һәм шәһәрдә яшәүче авылдашларыбыздан кергән хәер садака акчасына башкарыла. Бу максат өчен, беренчеләрдән булып садаканы авылның иң өлкән кешесе Әскәров Тәлгать бабай бирә. Казанның «Алмаз-Холдинг» зәркән компаниясе директоры Гомәров Фәрит тә мәчетне газлаштыруда матди ярдәм күрсәтә.

2010 елның сентябрь аенда мәчет тирәсен төсле калай рәшәткә белән әйләндереп алалар. Тимер баганалар утыртып төбен измә ясап катыру, керү ишеге ясау, ишек башына төсле калай белән ай кую эшләрен Апас районы Түбән Барыш авылы кешесе Зарипов Фәнис Фәрит улы бригадасы төгәл итеп башкара.

2013 елда мәчетнең чоланын сүтеп, шул урынга янкорма эшлиләр. 2014 елда бу янкормада тәһарәтханә һәм аш бүлмәләре бүленә, алар тиешенчә җиһазлана, су һәм ут кертелә, тәрәзәләр һәм яңа җылылык батареялары урнаштырыла. Урамда мәчеткә керә торган җиргә баскыч ясап,

аның өстенә «козырек» куела, Исмәгыйлов Зөфәр мәчеткә мөнбәр ясатып кайта.



2015 елда зур залда яңарту эшләре алып барыла: араталар һәм тумбочкалар куеп идәннәре алмаштырыла, стеналар такта белән тышлана, тарттырылган түбә һәм яңа тәрәзәләр куела, зур залга ут кертелә. Бу эшләрнең күбесен авылдашларыбыз Равил улы Ирек, Ринат улы Алмаз, Мансур улы Илдүс, Кәрим улы Ирек, Мөдәррис улы Рәфис, Хәйдәр улы Динар, Камбәр улы Данис, Фәһим улы Илшат, Фәһим улы Илдус һәм Нуриәхмәт улы Тәуфикъ башкарып чыга. Урман хуҗалыгы матди ярдәм күрсәтә. Ә башлап йөрүче һәм акчалата да зур ярдәм күрсәтүче кеше авылдашыбыз Гыйбадуллин Айдар була.

Мәчетебез манарасыннан көн саен намазга чакырып моңлы азан тавышы ишетелә. Өлкәннәр, урта яшьтәге ирләр, балалар һәм хатын-кызлар, тәһарәтләнеп, өйлә һәм җомга намазларын укырга киләләр. Җомга намазларына 18-20 ир кеше йөри. Гает намазларына халык күпләп килә, мәчет бинасы кардәшләребез белән шыгрым тулы була. Гает намазларына килүчеләр арасында яшьләрнең күп булуы – үзе бер сөенеч. Гомумән, авылыбызда яшьләрнең дингә тартылуы күркәм гадәткә әйләнеп бара.

Шунысы шатлыклы: мәчетебездә менә берничә ел инде балаларга һәм олыларга да дин сабаклары нигезләрен өйрәтү буенча нәтиҗәле эш алып барыла. Бу эшне лаеклы ялда булган мөгаллимә, Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә читтән торып белем алган Әлфия Усман кызы Гыймадиева белән элеккеге авыл хуҗалыгы белгече, хәзерге көндә

лаеклы ялда буган Рәшидә Зарифҗан кызы Нигъмәтҗанова башкаралар. Алар бу гамәлне бик теләп, җиренә җиткереп, изге ният белән эшлиләр.

Борындык мәчете, борынгы һәм таш булуы, озак еллар илаһи нур сирпеп торуы белән генә түгел, тагын бер ягы белән үзенчәлекле. Авыл халкын афәтле-хәвефле вакытларда коткарып калучы, сыендыручы да ул. 1926 елда бик көчле ташу булып авылны су баса. Халык, мал-мөлкәтен һәм терлек-туарын алып, авылның иң калку урынына – мәчет тирәсенә елыша. Изге йорт халыкны афәттән йолып кала. 1979 елда язгы сулар кабат котырына. Халыкны кабат изге йорт саклап кала.

*Илсөяр Сафина-Абдрахманова*

# Тәфсир

# Ибраһим галәйһиссәлам кыйссасы

Риваятьтә сөйләнелгәнчә, Ибраһим галәйһиссәлам кавеме арасында ел да билгеләп үтелә торган бер бәйрәм булган. Аның хөрмәтенә шәһәрдән читтә төрле ярминкәләр һәм күңел ачулар оештырылган. Һәммә халык – ирләр һәм хатыннар, картлар һәм балалар бу тантаналарда яратып катнашкан. Бәйрәм вакытында шәһәр барча адәмнәрдән бушанып, тынып ялгыз кала торган була.

Ибраһим галәйһиссәлам кавеме потларга табынган. Бәйрәмгә китәр алдыннан да бу кешеләр иң беренче чиратта үзләре ясаган потлар янына килеп, ризык калдырганнар. Кайтышлый янә сыннарга сәҗдә кылып, шул ризыкларны үзләре үк ашап та бетергәннәр. Янәсе, шулай итсәләр, аларга бәрәкәт һәм байлык насыйп ителәчәк.

Шушы томана халыкның башлыгы булып Нәмруд торган. Ул Җир барлыкка килгәннән бирле хакимлек иткән дүрт бөек хөкемдарның берсе була. Белгәнебезчә, алар арасыннан Сөләйман галәйһиссәлам һәм Зөлкарнәен галәйһиссәлам – иманлы, Нәбүкаднәззәр (Бәхтуннәср) һәм Нәмруд имансыз хакимнәр була. Шулай итеп, Ибраһим галәйһиссәламнең дошманы булган Нәмрудның никадәр зур көчкә ия булуын күз алдына китерүе кыен түгел.

Ибраһим галәйһиссәлам үзе исә бәйрәм йөрешләрендә катнашырга теләми. Бәйрәмнән калу өчен, аның халыкны куркытып болай дип кычкыруы хакында әйтелә:

فَنَظَرَ نَظْرَةً فِي النُّجُومِ ﴿٨٨﴾ فَقَالَ إِنِّي سَقِيمٌ ﴿٨٩﴾

**«Ул йолдызларга караш ташлады да «Һичшиксез, мин [аңладым, сезнең бәйрәм көнегездә] авырыймын», – диде».**

«Саффат / Сафта торучылар», 37:88-89

Моны ничек аңларга? Ибраһим галәйһиссәлам чорында кешелекне еш кына йогышлы авырулар баскан. Йогудан куркып, кешеләр чирле кавемдәшләреннән читләшә торган була. Шуңа Ибраһим галәйһиссәламнең сүзләрен ишетү белән халык аның яныннан төрле якка качып китә. Әмма иң актык рәтләрдә барган карт-корылар бу сүзне ишетми кала, һәм алар якынаю белән Ибраһим галәйһиссәлам тагын сүз ката:

قَالَ لَقَدْ كُنتُمْ أَنتُمْ وَآبَاؤُكُمْ فِي ضَلَالٍ مُّبِينٍ ﴿٥٤﴾

**«Ул: «Сез һәм аталарыгыз ап-ачык бер адашу эчендә булдыгыз», – диде».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:54

Ни өчен Ибраһим галәйһиссәлам аларның аталарын искә ала соң? Чөнки кяферләр потларга табынуны болай дип аклаганнар:

قَالُوا وَجَدْنَا آبَاءَنَا لَهَا عَابِدِينَ ﴿٥٣﴾

**«Алар: «Без аталарыбызны боларга табынган кемсәләр хәлендә таптык [һәм аларга иярдек]!» – диделәр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:53

Ибраһим галәйһиссәлам карендәшләренә, ата-бабалар шулай таныганга күрә генә сыннар илаһ була алмый, дип аңлата. Ул аларны аңга килергә чакыра: «Аталарыбыз шушы юлны сайлаган дип, ялгышлыкта яшәргә мөмкинме?» – дип әйтә. Ул, үз кардәшләрен хаталанып яшәүдән, томаналыктан коткару өчен тырышкан.

Кавемдәшләре исә аның бу сүзләренә ачулана – моңарчы бер генә кеше дә ата-бабаларга каршы сүз әйтергә кыймаган иде. Моңа җавап итеп, Ибраһим галәйһиссәлам тәүге тапкыр үз дине турында ачык итеп игълан итә:

قَالَ بَل رَّبُّكُمْ رَبُّ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ الَّذِي فَطَرَهُنَّ وَأَنَا عَلَىٰ ذَٰلِكُم مِّنَ الشَّاهِدِينَ ﴿٥٦﴾

**«Ул әйтте: «Юк! [Мин сезнең белән уен уйнамыйм]. Сезнең Раббыгыз – күкләрнең һәм җирнең Раббысы, Ул аларны юктан бар итте. Мин исә моңа [дәлил күрсәтә алырлык дәрәҗәдә] шаһитлык итүчеләрдәнмен».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:56

Ибраһим галәйһиссәлам бу сүзләрне йөрәгендәге көчле ышану һәм ихлас иман белән әйтә. Ул кешеләргә: «Аллаһы чиксез куәт һәм кодрәткә ия һәм яратырга сәләтле. Берни дә барлыкка китерә алмаган зат илаһ була аламыни? Сез ничек итеп потларыгызны Раббыга тиң күрә аласыз?» – дип мөрәҗәгать итә.

Аять Ибраһим галәйһиссәламнең шәһадәсе белән тәмамлана. Билгеле, ул җир һәм күкнең яратылганын да күрмәгән, үзенең дә барлыкка килүенә шаһит булмаган. Әмма аның өчен Җиһанда ком бөртегенә кадәр һәрнәрсә  Аллаһы Тәгалә тарафыннан барлыкка китерелгәне көн кебек ачык иде. Боларны сукыр гына күрми. Шуннан Ибраһим галәйһиссәлам кавемдәшләре артыннан болай дип әйтеп кала:

وَتَاللَّهِ لَأَكِيدَنَّ أَصْنَامَكُم بَعْدَ أَن تُوَلُّوا مُدْبِرِينَ ﴿٥٧﴾

**«Аллаһы белән ант итәмен, сезнең [табынуыгызны туктатып, ул һәйкәлләргә] артыгыз белән борылып [бәйрәмегезгә] китүегездән соң, мин, һичшиксез, ул потларыгызга [бер] тозак корачакмын».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:57

Ләкин арттан килүче картлар, балалар һәм гарипләр бу сүзләрне колакларына да элми. Ибраһим галәйһиссәлам тып-тын, бер җан иясе кал-

маган шәһәргә кайта. Кулына балта алып, ул сыннар янына китә. Мәҗүси кардәшләре гыйбадәт кылган урында 72 пот торган. Алар алтын, көмеш, агач һәм таштан ясалган була. Уртада – иң зур һәм зиннәтле ташлар белән бизәлгән сын, аның янында кечерәкләре урнаштырылган. Һәрберсе янында кешеләр калдырып киткән ризык. Ибраһим галәйһиссәлам болай дип әйтә:

فَرَاغَ إِلَىٰٓ ءَالِهَتِهِمْ فَقَالَ أَلَا تَأْكُلُونَ ﴿٩١﴾ مَا لَكُمْ لَا تَنطِقُونَ ﴿٩٢﴾

**«Ул илаһлары янына яшеренеп керде һәм әйтте: «[Алдыгыздагы ашамлыкларны] Ашамыйсызмы? Ни булды сезгә? Сез сөйләшмисезме?»**

«Саффат / Сафта торучылар», 37:91-92

فَجَعَلَهُمْ جُذَٰذًا إِلَّا كَبِيرًا لَّهُمْ لَعَلَّهُمْ إِلَيْهِ يَرْجِعُونَ ﴿٥٨﴾

**«[Кавеме потлар яныннан китеп баргач] Ул [кулына балта алып, сыннар янына килде дә] аларның иң зурысыннан башкаларын ватып чәлпәрәмә китерде [һәм соңыннан балтаны иң зурысының муенына элеп куйды], бәлки, алар аңа мөрәҗәгать итәрләр [дә, ул, аларны зур потка сылтап, җиңеп чыгар]».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:58

Бәйрәмнән кайткан халык хәрабәләрне күреп ала:

قَالُوا مَن فَعَلَ هَٰذَا بِآلِهَتِنَا إِنَّهُ لَمِنَ الظَّالِمِينَ ﴿٥٩﴾

**«Алар [бәйрәмнәреннән кайтып, потларын мондый хәлдә күргәч]: «Кем безнең илаһларыбызга моны эшләгән булса, ул – залимнәрдән», – диделәр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:59

Дөреслектә, бу кешеләр үз-үзләрен дә яклый алмаган һәм җимереккә әйләнгән буш сыннарга табынган. Әмма алар шуның кадәр караңгы наданлыкка батканнар, хәтта аек акылларын җуеп, сабак алырдай зиһеннәрен дә югалтканннар. Шушы наданлык баткагыннан чыга алмыйча, бу адәмнәр гаеплене эзләү һәм аннан үч алу турында уйлана башлый.

قَالُوا سَمِعْنَا فَتًى يَذْكُرُهُمْ يُقَالُ لَهُ إِبْرَاهِيمُ ﴿٦٠﴾

**«Алар: «Без Ибраһим исемле егетнең аларны һәрвакыт [яманлап] телгә алганын ишеткән идек. [Бәлки, бу эшне ул эшләгәндер]», – диделәр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:60

Ибраһим хакында Нәмрудка хәбәр итәләр. Хәзер инде аны бөтен халык алдында үлем җәзасы көтә.

قَالُوا أَأَنتَ فَعَلْتَ هَٰذَا بِآلِهَتِنَا يَا إِبْرَاهِيمُ ﴿٦٢﴾

**«Алар [Ибраһим галәйһиссәламне үзләре алдына чыгарып]: «Ий Ибраһим! Безнең илаһларыбызга моны син эшләдеңме?» – диделәр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:62

Ибраһим галәйһиссәлам көлемсерәп җавап кайтара:

قَالَ بَلْ فَعَلَهُ كَبِيرُهُمْ هَٰذَا فَاسْأَلُوهُمْ إِن كَانُوا يَنطِقُونَ ﴿٦٣﴾

**«Ул әйтте: «Юк [мин эшләмәдем]! Моны менә бу иң зурлары эшләгәндер, сорагыз үзләреннән. Әгәр алар сөйләшә торган булсалар [сезгә сөйләсеннәр]».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:63

Уйланучы кешеләр бу сүзләрдән хикмәт табарга тиеш иде, чөнки потларның берсе дә сөйләү түгел, селкенә һәм бер-берсенә кул

күтәрә алмаулары да һәркемгә аңлашыла. Ибраһим галәйһиссәлам кавемдәшләренә: «Сез ни өчен үз өсләреннән тузанны да сөртә алмаган бу потларга табынасыз?» – дип мөрәҗәгать итә. Кешеләрне бу фикер бер мәлгә аптыраашта калдыра һәм уйландыра, ләкин алар күнегелгән тормыш тәртибен үзгәртергә әзер булмый. Сабырлыгы һәм күркәм холкы белән мәгълүм булган Ибраһим галәйһиссәлам ярсый:

قَالَ أَفَتَعْبُدُونَ مِن دُونِ اللَّهِ مَا لَا يَنفَعُكُمْ شَيْئًا وَلَا يَضُرُّكُمْ ﴿٦٦﴾ أُفٍّ لَّكُمْ وَلِمَا تَعْبُدُونَ مِن دُونِ اللَّهِ ۖ أَفَلَا تَعْقِلُونَ ﴿٦٧﴾

**«[Ибраһим [галәйһиссәлам] Әйтте: «Сез, Аллаһыны калдырып, сезгә бернинди файда да, зарар да китерә алмаган нәрсәләргә табынасызмы әллә? Сезгә дә, Аллаһыны калдырып табынган нәрсәләрегезгә дә тфү! Һаман да аңламыйсызмыни?»**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:66-67

Күрәсез, Ибраһим галәйһиссәлам көнчыгыштан алып көнбатышка кадәр бөтен җир белән идарә иткән хакимгә һәм аның халкына фидакарьләрчә каршы чыга. Бу вакытта аның таянырдай һәм Нәмруд шикелле кабахәт дошманнан якларлдай бер генә иптәше дә, фикердәше дә булмый. Бердәнбер Яклаучысы һәм Ярдәмчесе – Аллаһы Тәгалә. Раббыбызга, Аның кодрәтенә һәм рәхмәтенә чиксез ышану, көчле ихласлылык Ибраһим галәйһиссәламнең тугры юлдашлары була.

Ә халык нәрсә соң? Ярсуыннан нишләргә белмәгән мөшрикләр болай дип әйтә:

قَالُوا حَرِّقُوهُ وَانصُرُوا آلِهَتَكُمْ إِن كُنتُمْ فَاعِلِينَ ﴿٦٨﴾

**«[Нәмруд һәм аның кешеләре: «Аны яндырыгыз һәм илаһларыбызга ярдәм итегез! Әгәр [аларга ярдәм] кылачак**

**кешеләр булсагыз [Ибраһимга газапларның иң катысын бирегез]», – диделәр».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:68

Ибраһим галәйһиссәламнең «Ләә иләәһә илләллаһ» дигән сүзләре кавемдәшләренең шулкадәр ачуын чыгара, алар иң кырыс җәза таләп итә башлыйлар. Җәза үзен озак көттерми – бөтен кавем белән Ибраһим галәйһиссәламне яндыруга әзерли башлыйлар. Моның өчен бергәләп – ирләр һәм хатыннар, балалар һәм картлар утынлыкка дип агач кисеп, коры ботаклар җыеп, учакка тезәләр. Учак тау хәтле биек булган, ул бер көнлек юл ераклыгыннан да күренеп торган. Аның ялкын телләре күкләргә ашып, уйнаклап, яныннан очып барган кошларны көйдергән. Шуннан соң шәйтан бу кешеләрне катапульта ясарга өйрәткән. Аның ярдәмендә Ибраһим галәйһиссәламне учакка ташларга тиеш булалар.

Ләкин Ибраһим галәйһиссәламнең Аллаһы ярдәменә ышануы бу уттан да көчлерәк була. Бу мизгелдә ул: «Хәсбияллаһү вә нигъмәл-вәкил»/ «Миңа Аллаһы җитә. Ул иң яхшы Ярдәмче», – дип кабатлап тора. Раббыбыз аны ишетә, калдырмый һәм учакка очкан мәлдә аңа Җәбраил галәйһиссәламне җибәрә. Җәбраил галәйһиссәлам аннан болай дип сорый:

– Ий Ибраһим! Сиңа ярдәм кирәкме?

Аллаһы Тәгалә Үзенең барлык колларына булыша. Әмма аларга сабыр булу мөһим. Кешеләр исә күбесенчә вакыйгаларны ашыктыра, кечкенә авырлыкларны да җиңә алмыйча, Раббыбыздан ярдәмне тиз арада килер дип көтә. Ибраһим галәйһиссәлам мөэминнәр өчен сабырлык өлгесе булып тора. Ул төрмәгә ябыла, үлем җәзасына тартыла, бөтен халыкка каршы ялгызы чыга... Ләкин хәтта куллары һәм аяклары белән бәйләнгән килеш катапультага терәлеп торганда да ярдәм әле килеп җитмәгән була. Ул аңа утка таба очкан мизгелдә генә ирешә. Һавада аңа Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәламне җибәрә. Хактыр ки, пәйгамбәрләргә дә Үзенең

ярдәмен Яратучыбыз сабыр иткәннән соң гына күрсәтә, һәм аларга җиңү насыйп итә.

Шулай итеп, утка таба очып барган Ибраһим галәйһиссәлам Җәбраил галәйһиссәламгә җавап бирә:

– Миңа синнән берни кирәкми.

– Ә Аллаһыдан нәрсә сорар идең?

– Миңа Аның хәлемне күреп белүе дә җитә.

Ягъни Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы аның хәлен белүендә бер шикләнмичә, насыйбына риза булып, әмеренә буйсынырга әзер була. Ул: «Әгәр дә Раббыбыз миңа янарга язмаган булса, Ул мине уттан саклап калачак. Аннан «Уттан коткар!» дип сорауның мәгънәсе нидә? Мин Аллаһы теләгәнне телим һәм Аның теләгенә каршы килгәнне теләмим», – дип фикер йөртә. Тәвәккәл кылу менә шул була!

Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

قُلْنَا يَا نَارُ كُونِي بَرْدًا وَسَلَامًا عَلَىٰ إِبْرَاهِيمَ ﴿٦٩﴾

**«[Алар аны зур бер ут эченә аткан вакытта] Без: «Ий ут! Ибраһим өчен салкынлык һәм тынычлык бул!» – дидек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:69

Шушы әмердән соң ут эченнән су чыганагы бәреп чыга, кызыл гөлләр үсеп чәчәк ата. Аллаһы Нәмруд халкы яккан учакны гөлбакчага әйләндерә. Җәбраил галәйһиссәлам ярдәмендә Ибраһим галәйһиссәлам учакның нәкъ уртасына – шушы гүзәллеккә килеп урнаша.

Игътибар итегез, Аллаһы Тәгалә утка салкын булырга гына түгел, тыныч булырга да куша. Югыйсә, Ибне Габбас радыяллаһу ганһе әйтүенчә, ут Ибраһим галәйһиссәламне өшетерлек кадәр салкын булыр иде.

Бу көнне җирнең һәр тарафында ут яндыру сәләте бетерелә, бер генә кеше дә учак яндыра алмый.

Ибраһим галәйһиссәлам исә ут эчендә җиде көн буе утыра. Соңыннан ул бу көннәрне гомеренең иң яхшылары дип атый.

## Ибраһим галәйһиссәламнең Нәмруд белән сөйләшүе

Ибраһим галәйһиссәлам утка ташлангач, Нәмруд аны югарыдан күзәтеп тора һәм аның гөлбакча эчендә тыныч кына утыруына шакката:

– Ий Ибраһим! Сине яклаучы Раббың дөрестән дә бөек. Ләкин уттан чыга алырсыңмы син?

– Әлбәттә, чыгам.

– Синең янда кемдер бар. Кем ул?

– Ул – фәрештә. Раббым аны минем белән сөйләшү өчен җибәргән.

– Алайса мин шуның кадәрле кодрәткә ия синең Раббыңа атап корбан чалам.

– Раббыма иман китермичә, синең корбаннарың кабул булмаячак.

Шулай да Нәмруд үзенекен итә һәм, иман китермичә, 4 мең үгез һәм тагын бик күп сарыкны корбан чала. Кызганыч, ул үзен илаһ дип бәяләвен дәвам итә, чөнки тәкәбберлегеннән котыла алмый һәм Аллаһы насыйп иткән иксез-чиксез байлык һәм хакимлеккә ия була.

Уттан тере чыккан Ибраһим галәйһиссәламне Нәмруд янына алып киләләр. Томаналыгыннан арына алмаган халык бу хакимне күргән саен баш игән. Ибраһим галәйһиссәламнең сәҗдә кылмаганын күреп, Нәмруд котырына:

– Ни өчен син миңа баш имисең?

– Мин сәҗдәне Раббыма гына кылам.

– Кем соң синең Раббың?

Аллаһы бу хакта Коръәндә болай дип әйтә:

أَلَمْ تَرَ إِلَى الَّذِي حَاجَّ إِبْرَاهِيمَ فِي رَبِّهِ أَنْ آتَاهُ اللَّهُ الْمُلْكَ إِذْ قَالَ إِبْرَاهِيمُ رَبِّيَ الَّذِي يُحْيِي وَيُمِيتُ قَالَ أَنَا أُحْيِي وَأُمِيتُ ۖ قَالَ إِبْرَاهِيمُ فَإِنَّ اللَّهَ يَأْتِي بِالشَّمْسِ مِنَ الْمَشْرِقِ فَأْتِ بِهَا مِنَ الْمَغْرِبِ فَبُهِتَ الَّذِي كَفَرَ ۗ وَاللَّهُ لَا يَهْدِي الْقَوْمَ الظَّالِمِينَ ﴿٢٥٨﴾

> **«[Ий Расүлем!] Аллаһы аңа падишаһлык бирде, дип [узынып] Раббысы [Аның берлеге] хакында Ибраһим [галәйһиссәлам] белән сүз көрәштергәнне [Нәмрудны] күрмәдеңме? Менә [Нәмрудка] Ибраһим [галәйһиссәлам]: «Минем Раббым – [үлеләрне] терелтүче дә, җаннарны алучы да!» – дигән иде. Ул исә: «Мин дә [үлем җәзасы бирелгән кешене гафу итеп, җанын саклап] терелтәм дә [теләгән кешемне үлем җәзасына тартып] җаннарын да алам!» – диде. [Аның бу сүзеннән никадәр ахмак булганын аңлаган] Ибраһим [галәйһиссәлам]: «Һичшиксез, Аллаһы [һәр иртә саен] кояшны көнчыгыштан чыгара, син [бер генә мәртәбә булса да] аны көнбатыштан чыгар!» – диде. [Шул вакыт] Кяфер аптырашта калган иде. Аллаһы [һидаятьне кабул итүдән качып, үз-үзләрен зарарга салган] залимнәр кавемен һидаять итми».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:258

Моңа җавап итеп Нәмруд үлем җәзасына тартылган ике тоткынны чакыртып алып, берсен үтертә, икенчесен гафу итеп азат итә. Соңыннан Ибраһим галәйһиссәламгә борылып: «Күрдеңме: мин дә гомерне өзә дә, бирә дә алам», – дип әйтә.

Билгеле, Ибраһим галәйһиссәлам кешене тудыру һәм үтерү турында түгел, ә Раббыбызның дөньядагы һәрнәрсәне юктан бар һәм бардан юк итә алуы хакында сөйләде. Дөньяны барлыкка китерүче һәм Яратучы –

бердәнбер Раббыбыз, Аннан башка илаһ юк. Ибраһим галәйһиссәлам Аңа гыйбадәт кылырга чакырып дәгъват кыла. Ул Нәмрудка мондый тәкъдим ясый:

– Минем Раббым кояшны көнчыгыштан чыгара, син исә аны көнбатыштан чыгарып кара.

Нәмруд мәсхәрәгә кала һәм хурлана. Ул Ибраһим галәйһиссәламне уттан тере чыгарган Аллаһы Тәгалә бөтен халык алдында моны эшли алачагын һәм шуннан соң бар мөшрикләрнең иман китерергә теләячәген аңлый. Хакимнең куркуы юкка булган – Ибраһим галәйһиссәламнең дәгъватына ияру өчен халыкка аның уттан котылуын күрү дә җитә. Шулай итеп, кешеләр иман китерәләр. Риваятьләрдә аларның иң беренчесе булып Лут ышана, дип әйтелә.

Соңыннан Яратучы, Ибраһим галәйһиссәламне барлык золымнар һәм дошманнардан саклап, аларны җәзага тартып, юк итә. Мисал өчен:

وَأَرَادُوا بِهِ كَيْدًا فَجَعَلْنَاهُمُ الْأَخْسَرِينَ ﴿٧٠﴾

**«Алар аңа зур бер хәйлә кылырга теләделәр, Без исә аларны иң зур зарар күргән кемсәләр хәленә төшердек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:70

Раббыбыз Үзенең яраткан барлык колларын да шулай золымнардан коткара. Алар исә үз чиратында, Ибраһим галәйһиссәлам шикелле үк, Аллаһыга итагать кылырга, иманнарын ныгытырга һәм сабыр булырга тиеш.

## Исмәгыйль галәйһиссәламнең тууы

Риваятьләрдә Ибраһим галәйһиссәлам үз халкын калдырып һиҗрәт кылганнан соң ялгыз кала, дип хәбәр ителә. Кардәшләреннән читтә калып ул үзен тулысы белән Аллаһыга багышлап, Аңа бөтен җаны белән бирелеп

гыйбадәт кыла. Раббыбыз аңа иксез-чиксез байлыклар насыйп итә, әмма бала бәхетен генә бирми. Ибраһим галәйһиссәлам үзенә тәкъвалы нәсел дәвамчыларын сорап күп дога кыла, ир-бала туса, хәтта аны Аллаһы ризалыгы өчен корбан итәргә нәзер әйтә.

Ибраһимның бала теләве аның хатыны хәзрәти Сараны да борчый. Әмма ул үзен бала тудыруга сәләтсез һәм карт дип саный. «Бәлки, Аллаһы Тәгалә Ибраһимга икенче хатыннан бала насыйп итәр», – дип хәзрәти Сара иренә яшь хатынны – үзенең хезмәтчесен бүләк итеп тапшыра.

Аллаһы тәкъдире белән хәзрәти Һаҗәр никахның беренче төненнән үк балага уза. Бу сабый Исмәгыйль галәйһиссәлам була. Коръәндә монның хакта болай дип әйтелгән:

فَبَشَّرْنَاهُ بِغُلَامٍ حَلِيمٍ ﴿١٠١﴾

**«Без аны йомшак холыклы бер ир бала [булган Исмәгыйль [галәйһиссәлам] белән сөендердек».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:101

Ибраһим галәйһиссәламнең куанычын күз алдына китерү авыр түгел. Күпме догалар кылганнан соң Аллаһы Тәгалә аңа 100 яшендә сау-сәламәт ир-бала бүләк итә.

Ләкин вакыт узу белән хәзрәти Сара Ибраһим галәйһиссәламне хәзрәти Һаҗәрдән көнли башлый. Хисләр акылны камап ала һәм ул хәзрәти Һаҗәрне үз яныннан читкә җибәрергә сорый.

## Хәзрәти Һаҗәр өчен бөек сынау

Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы насыйбы белән Җәбраил галәйһиссәлам артыннан хәзрәти Һаҗәрне һәм аның күкрәк сабыен алып юлга чыга. Мәккәгә җиткәч, ул аларны, Яратучыга ышандырып, хәзерге көндә Зәм-Зәм чыганагы аккан урында калдырып китә. Тирә

якта буп-буш һәм коп-коры чүл генә була. Һаҗәр һәм кечкенә Исмәгыйль галәйһиссәламдә бары бер кәрзин хөрмә җимеше һәм турсык белән су гына була. Ибраһим галәйһиссәламнең мондый гамәленә аптыраган һәм улы белән икесенең алдагы язмышларын күз алдына да китерергә курыккан яшь ана, берсүзсез, аларны ташлап киткән ире артыннан чабып китә. Ул:

– Бер җан иясе һәм бер тамчы су булмаган шушы эссе чүлдә безне ничек калдырып китәсең? – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәлам исә бер сүз дәшмичә һәм борылып та карамыйча юлын дәвам итә. Хәзрәти Һаҗәр аңа артыннан бу сүзләрне берничә тапкыр кычкырып кабатлый. Шуннан соң ул болай дип сорый:

– Сиңа Аллаһы шулай эшләргә куштымы?

Бу сораудан соң Ибраһим галәйһиссәлам аңа борылып җавап кайтара:

– Әйе, Раббыбыз шулай кушты. Мин сезне Аңа ышандырып тапшырам.

Әлеге сүзләрне ишеткәч, хәзрәти Һаҗәр:

– Алай булгач, Ул безне ташламас. Аллаһы Тәгалә безгә җитә, – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәлам Һаҗәр күрмәс ераклыкка җиткәч, яшьләренә тыгылып Аллаһыга дога кыла:

رَّبَّنَا إِنِّي أَسْكَنتُ مِن ذُرِّيَّتِي بِوَادٍ غَيْرِ ذِي زَرْعٍ عِندَ بَيْتِكَ الْمُحَرَّمِ رَبَّنَا لِيُقِيمُوا الصَّلَاةَ فَاجْعَلْ أَفْئِدَةً مِّنَ النَّاسِ تَهْوِي إِلَيْهِمْ وَارْزُقْهُم مِّنَ الثَّمَرَاتِ لَعَلَّهُمْ يَشْكُرُونَ ﴿٣٧﴾

**«Ий Раббыбыз! Һичшиксез, мин нәселемнең бер өлешен игенсез бер үзәнлеккә, [үзенә дә, янында яшәүчеләргә дә һөҗүм итү һәм мәсхәрәләү] харам кылынган йортың янында урнаштырдым.**

> **Ий Раббыбыз! Намаз укысыннар. Кешеләрдән кайберләренең күңелләрен [Мәккәгә урнаштырган гаиләмә һәм алардан таралачак яңа буыннарга] авыштыр һәм аларны [тирә-яктагы мәмләкәтләрдә өлгергән һәм ерак җирләрдән кайтарылган төрле-төрле] җимешләрдән ризыкландыр, – бәлки, алар [намазларын тиешенчә укып һәм бүтән гыйбадәтләрен җиренә җиткереп, бу нигъмәтләргә] шөкер итәрләр».**
>
> «Ибраһим», 14:37

Ибраһим галәйһиссәлам укыган доганың бәрәкәте белән Раббыбыз кешеләрнең йөрәкләрен шушы чүл урынына карата ача. Элек бер йорт та булмаган, хәтта кәрван юллары да үтмәгән бу чүл бүген һәр мөэминнең күңелендә саклана торган, үзенә Җир шарының төрле почмакларыннан күпмиллионлаган халыкларны тартып торган Мәккә-и Мөкәррәмә шәһәре булып тора.

Әнә шулай итеп, хәзрәти Һаҗәр улы белән бергә шушы буш урынга тормыш өрә. Ул Ибраһим галәйһиссәлам калдырган турсыктан су эчеп, хөрмә җимешләрен ашап, баласын имезә. Ләкин ризык бер мәлне бетә башлый, кояш эсселегеннән качар җир дә булмый. Хәзрәти Һаҗәрнең күкрәк сөте бетә, ачтан ярсып елаучы баласына карап йөрәге әрни, ләкин берни эшли алмый.

Хәлсезләнеп калып, ул бары бер җан иясе килеп чыкмасмы дигән өмет белән як-ягына каранып утыра. Ерак түгел урнашкан Сафа тавына менеп тә күзәтеп карый. Аннан соң бертуктаусыз дога укып, баласын кочаклап үзәнлеккә төшә һәм Мәрва тавына менеп карый. Шушы Сафа һәм Мәрва таулары арасын аңа җиде тапкыр үтәргә туры килә. Һәм хәзрәти Һаҗәр могҗизага тап була.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Хаҗилар нәкъ шуңа күрә Сафа һәм Мәрва таулары арасын җиде тапкыр үтә», – дигән сүзләре билгеле.

## Зәм-Зәмнең барлыкка килүе

Хәзрәти Һаҗәр соңгы тапкыр Мәрва тавына менгәч, берничә рәт кеше тавышы ишетә. Беркемне дә күрмәгәч, болай дип сүз ката:

– Ий, тавыш иясе, син үзеңне белдердең. Әгәр дә ярдәм итә алсаң, күрен һәм булыш.

Шулвакытта Зәм-Зәм барлыкка киләчәк урында Җәбраил галәйһиссәлам пәйда була. Исмәгыйль елавыннан туктый алмыйча, аяклары белән җирне дөп-дөп таптый. Җәбраил галәйһиссәлам сабый аягы белән таптаган урынга канаты белән кагылып ала, һәм бу җирдән су чыганагы бәреп чыга. Хәзрәти Һаҗәр моны күреп, куана-куана турсыкны су белән тутырам дип, «Зәм-Зәм» яки «тукта-тукта» дия-дия, су читкә китмәс өчен, чыганакны ком белән коймалап алырга тырыша.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Исмәгыйль анасы Һаҗәрне Аллаһы кичерсен: Зәм-Зәм чыганагын тынычлыкта калдырса, ул елга булып агып китәр иде» – дип әйткәне турында хәбәр ителә.

Югыйсә хәзрәти Һаҗәргә: «Су китә дип борчылма! Аллаһы аны синең һәм улың өчен чыгарды. Ул беркайчан саекмаячак», – дип әйтелә.

Белгәнебезчә, шушы көннән алып һәм бүгенге заманга кадәр бу чыганак кешелек дөньясын үзенең шифалы суы белән куандырып тора һәм, иншәАллаһ, Кыямәт көненә кадәр куандырып торыр. Һәр мөэминнең, хаждa булу-булмавына карамастан, бу судан авыз иткәне булгандыр, мөгаен. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәне хәбәр ителә: «Дөньядагы иң яхшы су – Зәм-Зәм. Бу су тукландыра һәм авыруларга шифа бирә».

Зәм-Зәм хәзрәти Һаҗәрне һәм кечкенә Исмәгыйльне дә, бу җирлеккә кешеләр килеп урнашканчы, ризыкландырып та, сусауларын басып та торган.

## Исмәгыйль галәйһиссәлам корбан ителергә тиеш

Ел саен Ибраһим галәйһиссәлам Мәккәгә үз гаиләсе янына килә торган була. Еллар үтә, Исмәгыйль галәйһиссәлам үсеп буйга җитә, Ибраһим исә әйткән нәзере турында оныта... Ләкин көннәрдән бер көнне әти кешегә әйткән вәгъдәсен исенә төшерәләр – ул төш күрә. Аңа:

– Ий Ибраһим! Аллаһы әмере белән улыңны корбан ит, – дип әйтелә.

Йокысыннан уянгач, Ибраһим галәйһиссәлам бу төшнең шәйтаннанмы яки Рәхманнанмы икәнлегенә шикләнә башлый. Фәхретдин Әр-Разый, Хазин һәм казый Бәйдави моны болай дип аңлаткан. Ибраһим галәйһиссәлам төшне Гарәфә көне алдыннан күрә. Күңеленә шөбһә төшергәнгә күрә, зөлхиҗҗә аеның 8нче көне Тәрвия көне дип атала башлый. «Тәрвия» – шикләнү дигән сүз.

Гарәфә көнендә дә шул ук төшне күргәч, Ибраһим галәйһиссәлам аның Аллаһыдан булуын аңлый, бөтен шик-шөбһәләр юкка чыга. Әмма Раббысының бу әмерен кайчан үтисе?

Өченче тапкыр да әлеге төшне күргәч, ата үз баласын шушы көндә үк корбан итәргә тиешлеге ачыклана. Ибраһим галәйһиссәлам Исмәгыйль галәйһиссәламне корбан итү урынына алып китә. Соңыннан бу көн «Яумун-Нәхр / Корбан бәйрәме» дип атала башлаячак.

Юлда Ибраһим галәйһиссәлам янына карт кыяфәтенә кереп шәйтан килә:

– Ашыкма, бәлки, Аллаһы Тәгалә бу җаваплылыктан сине арындырыр. Улыңа кара: нинди чибәр, сәламәт, төз гәүдәле егет! Үз балаңа пычак кадарга әзер булгач, нинди ата син?!

Шәйтанның бу сүзләрен ишеткәч, Ибраһим галәйһиссәлам:

– Әй каһәр суккан шәйтан! Күземнән югал. Бу – Раббым әмере. Мең улым булса, Аллаһы ризалыгы өчен аларны да корбан итәргә әзер булыр идем, – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәламне юлдан яздырудан өмет өзеп, шәйтан Исмәгыйль галәйһиссәлам янына да барып карый:

– Атаң сине кадап үтерергә алып бара. Пычагын күрдеңме?

Исмәгыйль галәйһиссәлам:

– Ата кеше үз баласын үтерә аламыни?! Ни сөйлисең син? – дип әйтә.

– Аңа Аллаһыдан шундый әмер килә.

– Раббымның теләге шундый булгач, синең ни эшең бар, мәлгунь?! – дип, Исмәгыйль галәйһиссәлам шәйтанга таш атып куып җибәрә.

Кырын эшен болай да майтара алмагач, шәйтан хәзрәти Һаҗәр янына юнәлә, әмма аны куркыту да көченнән килми – Ибраһим галәйһиссәлам гаиләсе аңа каршы нык тора.

Бераздан соң Җир күз күрмәгән, колак ишетмәгән бер могҗизалы вакыйгага шаһит була. Коръәндә болай дип әйтелә:

فَلَمَّا بَلَغَ مَعَهُ السَّعْيَ قَالَ يَا بُنَيَّ إِنِّي أَرَىٰ فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ فَانظُرْ مَاذَا تَرَىٰ ۚ ...﴿١٠٢﴾

**«Ул аның белән бергә [эшләрендә] тырышлык куюга [мөмкинлек биргән унөч яшьләргә] җиткәч [атасы аңа]: «Ий улым! Һичшиксез, мин [берничә төн рәттән] төшемдә сине чалганымны күрдем. Син ни уйлаганыңны кара»,** – диде.

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:102

Күргәнегезчә, сынауның авырлыгына карамастан, Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең әмеренә бер дә каршы килми, аңа берсүзсез күнә. Йөрәгендә һичнинди кайгыру һәм борчылуга да урын калдырмыйча итагать күрсәтә. Ә Исмәгыйль галәйһиссәлам атасыннан Яратучының шушы теләген ишеткәч, үзенең тәкъвалыгы һәм күңеле белән Ибраһим галәйһиссәламнең итагатьлек дәрәҗәсенә ирешә:

قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ ۖ سَتَجِدُنِي إِن شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ ﴿١٠٢﴾

**Ул: «Ий әтием! Сиңа әмер ителгән нәрсәне [һич уйлап тормыйча] үтә. ИншәАллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табачаксың», – диде».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:102

Бу бик мөһим сүзләр. Исмәгыйль галәйһиссәлам корбан китерергә кирәклеге турында ишеткәч тә, атасына карата мәхәббәтен җуймый, шушы авыр мизгелдә аның хәленә керә, теләгенә күнә. Ничек кенә кыен булса да, барыбер яратып «Атам минем» дип эндәшә һәм әдәбен дә саклый. Хәтта Аллаһыны да элек олылаган кебек олылый. «ИншәАллаһ!» ди. Үзен батыр итеп күрсәтеп, мактау сүзләрен ишетү өчен түгел, ә сабыр һәм тәкъвалы булып каласы килә аның. Шуннан да югарырак фида кылу мөмкинме?

## Бөек сынау күренеше

Ачыктан-ачык сөйләшүдән соң Ибраһим галәйһиссәлам һәм Исмәгыйль галәйһиссәлам әмерне үтәүгә әзерләнә башлыйлар. Аларның икесе дә берничә мизгелдән дөньяда булмаган, кеше аңы сыйдыра алмаган, Изге Коръән китабында мәңгелеккә сакланып калынган һәм буыннан-буынга сөйләнә торган олы вакыйганың шаһитлары булачагы турында әле белми. Раббыбыз болай дип әйтә:

فَلَمَّا أَسْلَمَا وَتَلَّهُۥ لِلْجَبِينِ ﴿١٠٣﴾

**«Ул икәү [Аллаһы Тәгаләнең хөкеменә тулысынча] буйсынгач, ул аны яны белән [җиргә] яткырды».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:103

Мондый сынауны кешелекнең бүтән күргәне булмады. Хәтта фәрештәләр дә Ибраһим галәйһиссәлам һәм Исмәгыйль галәйһиссәламнең ихлас гамәлен тын да алмыйча күзәтеп тора. Ниһаять, ата үз

улының муенына пычак тидерә. Ләкин пычак кисми, Исмәгыйль галәйһиссәламнең бер тамчы каны да чыкмый. Ибраһим галәйһиссәлам пычакның үткенлеген тикшерә – пычак ташны яра, әмма Аллаһының бөек хикмәте белән кеше муенын кисми.

Шулчак Ибраһим галәйһиссәлам ачу белән әйтә:

– Әй пычак! Син минем Раббыма итагатьсезлек күрсәтүемне телисеңме?

Пычак болай дип җавап бирә:

– Хәлил (Ибраһим галәйһиссәлам) кисәргә куша, Җәлил (Аллаһы Тәгалә) кисмәскә куша. Миңа нишләргә? Әлбәттә, мин Аллаһы Тәгалә сүзен генә тыңлыйм.

Әнә шулай итеп, ике бөек тәкъвалы кеше Раббыбызга үзләренең тугрылыкларын дәлилли. Атага һәм аның газиз улына Аллаһы ризалыгы өчен корбан китерергә сарык җибәрелә.

إِنَّ هَٰذَا لَهُوَ الْبَلَاءُ الْمُبِينُ ﴿١٠٦﴾ وَفَدَيْنَاهُ بِذِبْحٍ عَظِيمٍ ﴿١٠٧﴾

**«Һичшиксез, бу – ап-ачык бер сынау. Без аңа фидия итеп зур [кыйммәткә һәм гәүдәгә ия булган] бер корбанлык [сарык тәкәсе] бирдек».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:106-107

Шулвакыт күктән тәкбир әйтеп, Җәбраил галәйһиссәлам төште. Аның кулында корбанга китерелергә тиешле сарык иде. Җәбраил галәйһиссәлам:

– Аллаһү әкбәр! Аллаһү әкбәр! – дип тәкбир әйтте.

Ибраһим галәйһиссәлам башын өскә күтәреп: «Ләә иләәһә илләллаһу вәллаһү әкбәр», – диде.

Исмәгыйль галәйһиссәлам бу сүзләрне ишетеп: «Аллаһү әкбәр вә лилләһил хәмде», – дип әйтә.

Менә шушы вакыйгадан соң Корбан гаете көннәрендә мөэмин-мөселманнар һәр фарыз намазыннан соң бердәмләшеп тәкбир-тәшрикъләрне кабатлый башлый. Тәкбирләрне әйтү Гарәфә көненең иртәнге намазыннан башлап, бәйрәмнең дүртенче көнендәге ястү намазына кадәр башкарыла.

Шулай итеп, Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең сынавын үтәп, Аңа үзенең тәкъвалыгын һәм тугрылыгын исбатлый. Раббыбызга үзенең ихласлылыгын күрсәтеп, ул Хәлилуллаһ, ягъни Аллаһының дусты дигән олы исемгә лаек була. Без исә шуны аңладык: сөекле Яратучыбыз Үзенең колларыннан сабырлык, диндарлык һәм ихлас иманнан башка берни таләп итми. Ул бушка китерелгән корбаннардан да риза булмый. Әмма ихластан Аның ризалыгы өчен шәхси милек һәм гомерне корбан итәргә әзер булуыбыз, Аллаһы Тәгалә әмеренә буйсынуыбыз Аңа ихластан гыйбадәт кылуыбызны дәлилли. Хәлилуллаһ шундый булган!

Шушы гыйбрәтле кыйссадан аңлашыла ки, Ибраһим галәйһиссәламнең башына төшкән барлык сынауларның максаты газиз баласының гомерен өзү түгел, ә йөрәгеннән Аллаһы Тагәләдән кала башка мәхәббәтләрне сөртеп ташлау була. Кулына пычак алып, Ибраһим галәйһиссәлам Исмәгыйльне түгел, ә аңа карата сөюен кисеп, күңелендә бердәнбер бөек илаһи яратуны гына калдыра.

Аллаһы теләмәсә, бернинди үткен пычак кисә, бернинди ут яндыра, бернинди диңгез суга батыра алмаячак. Ибраһим галәйһиссәлам һәм Муса галәйһиссәламнең гыйбрәтле мисаллары – безгә үрнәк булыр.

# Кем юмартрак?

Сынауны үткәннән соң, Исмәгыйль галәйһиссәлам атасыннан болай дип сорый:

– Ий атам минем! Безнең кайсыбыз юмартрак икән: синме-минме?

– Улым! Мин юмартрак, чөнки мин гомер буе көткән сау-сәламәт, үсеп җиткән, дөньяның бөтен байлыкларыннан да кадерлерәк булган бердәнбер газиз баламны Аллаһы юлында корбан итәргә әзер идем.

– Атам минем! Мин синнән юмартрак. Минем гомерем бер генә, син исә, мине корбан иткәннән соң, Раббыбыздан үзеңә тагын бала сорый ала идең.

Шулчак Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

– Мин сезнең икегездән дә юмартрак, чөнки берегезгә газиз бала, икенчегезгә гомер бүләк иттем.

Шулай итеп, барлык мөселманнарга Ибраһим галәйһиссәлам һәм Исмәгыйль галәйһиссәлам белән бәйле шушы бөек вакыйгаларны искә төшереп, корбан китерү Исламның бер вәҗиб гамәлләреннән санала. Корбан бәйрәме – җир шарының барлык почмакларында зурлап билгеләп үтелә торган мөселман бәйрәме ул. Корбан – Аллаһы безгә насыйп иткән зур гыйбадәт, Раббыбыз биргән чиксез нигъмәтләр өчен рәхмәтебезне белдереп, буйсынуыбызны күрсәтү, Аллаһыга мал-мөлкәтеңне корбан китереп, үзеңнең тугрылыгыңны һәм мәхәббәтеңне белдерү һәм дәлилләү мөмкинлеге.

# Ибраһим галәйһиссәламне байлык белән сынау

Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне Хәлил, ягъни дусты итеп игълан иткәч, фәрештәләр:

– Ий Раббыбыз! Син аны ничек итеп Үзеңнең дустың итеп таный аласың, аның йөрәге байлык һәм балаларына карата мәхәббәт белән тулы бит? – дип сорый. Раббыбыз:

– Аның калебендә Миннән башка бернәрсәгә дә сөю хисе юк. Теләсәгез, аны сынагыз, – дип әйтә.

Шунда бер фәрештә кеше кыяфәтенә кереп, Ибраһим галәйһиссәлам янына килә дә:

– Син зур байлыклар иясе, ә мин – мохтаҗ, – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәлам болай дип җавап кайтара:

– Минем Раббыма мактаулар әйтсәң, сине үземнең милкемнән бүләклим.

– Суббухун Куддусун Раббуль-Мәләикәти вәр-рух.

– Байлыгымның яртысы – синеке! Раббыма тагын мактаулар ирештер – шушы көтүне тулысы белән сиңа бирәм.

Фәрештә тагын шушы тәсбихне кабатлагач, Ибраһим галәйһиссәлам тау башына менеп, барча көтүчеләренә болай дип җиткерә:

– Ий көтүчеләр! Мин сезне бөтен көтүләрегез белән шушы кешегә бүләк иттем, чөнки ул Аллаһы Тәгаләгә мактаулар әйтте.

Ибраһим галәйһиссәламнең шушы гамәленә һәм юмартлыгына исе киткән фәрештә:

– Мин сине сынарга дип килгән фәрештә һәм синең байлыкларыңа мохтаҗ түгел. Милкең үзеңдә калсын, – дип әйтә.

# Ибраһим галәйһиссәлам Кәгъбә төзи

Ибраһим галәйһиссәлам Әл-Харам җирендә хатынын һәм улын калдырып, туган ягына әйләнеп кайткач, ел саен гаиләсе янына килә торган була.

Ул хәзрәти Һаҗәр үлгән һәм Исмәгыйль галәйһиссәлам өйләнгән елны да килә. Әмма улын өйдә очрата алмый. Йортта аны улының яшь хатыны гына каршылый. Ул Исмәгыйль галәйһиссәламнеңауга киткәнен хәбәр итә. Ибраһим галәйһиссәлам:

– Ни хәлләрдә яшисез? – дип сорый. Килен:

– Без фәкыйрьлектә гомер кичерәбез, – дип җавап кайтара.

Моны ишеткәч пәйгамбәр:

– Ирең кайткач, миннән сәлам әйт һәм ишек тупсасын алыштырырга куш, – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәлам өйгә кайткач, атасының исен сизеп ала һәм аның монда булганын аңлап, хатыныннан:

– Бүген безгә кем дә булса килдеме? – дип сорый. Ул:

– Әйе, бер карт кергән иде, хәлләрне сорашып, сиңа сәлам әйтергә һәм ишек тупсасын алыштырырга кушты, – дип җавап бирә.

Ибраһим галәйһиссәлам моны ишеткәч:

– Ул минем атам булган, ә ишегемнең тупсасы – син. Ул миңа синең белән аерылырга кушкан. Бүгеннән син үз гаиләңә кайта аласың, – дип әйтә.

Бу вакыйгаларда олы хикмәт бар. Пәйгамбәрләр беркайчан да нәфесләреннән чыгып сүз дә әйтмәгән, гамәл дә кылмаган. Бары тик Аллаһы кушуы буенча гына эш иткән. Мондый әмернең мәгънәсе дә шунда: сөекле расүлебез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән чыгарга тиеш булган, шуңа күрә аның хаты-

ны да әлеге нәселнең анасы исеменә лаек булырга тиеш. Билгеле, холыксыз һәм көйсез хатын шушы олы дәрәҗәне күтәреп йөртерлек булмый.

Пәйгамбәрлек чылбыры Ибраһим галәйһиссәламнең ике улы – Исхак һәм Исмәгыйль галәйһимуссәламгә барып тоташа. Хәзрәти Сара һәм Ибраһим галәйһиссәламнең улы Исхак галәйһиссәламнән Исраил угыллары кавеме барлыкка килә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм генә хәзрәти Һаҗәрдән туган Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән чыга.

Күпмедер вакыт узгач, Исмәгыйль галәйһиссәлам Җөрхем кавеменнән үзенә икенче хатын ала. Ул өйдә берүзе калган мәлдә Ибраһим галәйһиссәлам улының хәлен белергә дип килә. Килененең хәл-әхвәлен сорагач, ул:

– Исмәгыйль безгә ризык эзләп, ауга китте, – дип җавап кайтара. Ибраһим галәйһиссәлам:

– Ни хәлләрегез бар? – дип сорый. Килен:

– Аллаһыга шөкер! Без бәхетле һәм имин яшибез, – дип әйтә. Ибраһим галәйһиссәлам:

– Нәрсә ашыйсыз һәм эчәсез? – дип сорый. Килен:

– Ит ашап, су эчәбез, – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәлам моны ишеткәч:

– Ий, Раббым, аларның итләрен һәм суларын бәрәкәт белән бүләклә, – дип дога кыла.

Пәйгамбәрнең бу догасы белән Аллаһы Тәгалә алар яшәгән бөтен җирлеккә бәрәкәт иңдерә – монда һәрчак җитәрлек ит һәм су була.

Ибраһим галәйһиссәлам үз килененең күркәм холкын ошата һәм аңа:

– Ирең өйгә кайткач, аңа миннән сәлам җиткер һәм ишек тупсасын яхшы карарга куш, – дип әйтә.

Бу вакыйга турында хатын ире Исмәгыйль галәйһиссәламгә сөйли. Ул:

– Бу минем атам иде. Ә син – ишегемнең тупсасы. Ул миңа сине кайгыртып һәм яратып яшәргә кушкан. Син элек тә күңелемә газиз идең, хәзер тагын да сөеклерәк булдың, – дип әйтә.

Күпмедер вакыттан соң Аллаһы теләге белән Ибраһим галәйһиссәлам кабат Әл-Харамга килә. Монда аңа Бәйтуллаһны яңадан төзергә кирәк була. Исмәгыйль галәйһиссәлам атасын ерактан ук күреп алып, янына чабып килә, кулларын үбә, алар кочаклаша.

– Ий улым! Раббыбыз миңа бөек гамәл кылырга кушты. Ярдәм итәрсеңме? – дип Ибраһим галәйһиссәлам улына сүз ката.

Ул вакытта Кәгъбәдән бары кечкенә тау гына калган була. Силләр һәм су басулар аның нигезен генә калдыра. Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәлам аны чистартып, диварларын күтәрә башлыйлар. Исмәгыйль галәйһиссәлам ташлар ташып тора, ә атасы аларны тезеп сала.

Кәгъбә шактый күтәрелгәч, Исмәгыйль галәйһиссәлам бүген «Ибраһим мәкаме» дип йөртелә торган бер таш китерә. Ибраһим галәйһиссәлам, буе җитмәгәч, аңа басып диварларны төзүне дәвам итә, шуңа бу ташта аның аяк эзләре уелып кала. Аллаһы Йорты төзелеп беткәч, ата белән ул, шушы олы хезмәтне кабул итүен сорап, Раббыбызга дога кыла:

وَإِذْ يَرْفَعُ إِبْرَاهِيمُ الْقَوَاعِدَ مِنَ الْبَيْتِ وَإِسْمَاعِيلُ رَبَّنَا تَقَبَّلْ مِنَّا ۖ إِنَّكَ أَنتَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ ﴿١٢٧﴾

**«Вакытында Ибраһим белән Исмәгыйль [галәйһимуссәлам] Бәйттән [Адәм [галәйһиссәламнән соң] калган нигезләрне [табып, диварларын] күтәрделәр [һәм, шул ук вакытта, болай**

**дияләр иде]: «Ий Раббыбыз! [Бу хезмәтебезне] Бездән кабул ит, һичшиксез, Син – [һәрнәрсәне] Ишетүче, [һәрнәрсәне] Белүче!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:127

Соңыннан Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы кушканча Кубайс тавына менеп (кайбер риваятьләрдә Ибраһим мәкаме ташына басып дип әйтелә) кешеләргә хаҗ кылу кирәклеге турында хәбәр итә:

– Ий кешеләр! Раббыбыз безгә Аның Йортын әйләнеп тәваф кылырга куша. Ий, кешеләр, бу әмерне үтәгез!

Раббыбыз Аллаһы һәрбарчабызга да шушы изге җирләрдә хаҗ кылырга һәм Аның Йортына маңгай-битләребез һәм йөрәкләребез белән кагылып китәргә язсын иде!

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Коръән сүрәләре

## 71. Нух сүрәсе

Мәккә чоры, 28 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Һичшиксез, Без: «Тилмерткеч газап аларга килгәнче, кавемеңне кисәт!» – дип, Нухны** [галәйһиссәлам] **кавеменә җибәрдек.**
2. **Ул әйтте: «Ий кавемем! Һичшиксез, мин – сезгә** [хакыйкатьләрне] **аңлаткан** [һәм сездән бер түләү сорамаган] **бер кисәтүчемен.**
3. **Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз, Аннан куркыгыз һәм** [ирештергән мәсьәләләрдә] **миңа итагать итегез!**
4. [Шулай итсәгез, Аллаһы Тәгалә] **Сезнең гөнаһларыгызны гафу итәр һәм сезгә билгеләнгән вакытка кадәр кичектерү бирер, чөнки Аллаһының** [тәкъдир иткән] **әҗәле җиткәч, кичектерү бирелми. Әгәр белсәгез иде!»**
5. [Нух [галәйһиссәлам] тугыз йөз дә илле ел кебек озак вакыт ирештерү вазифасын үтәсә дә, берничә кешедән башкаларның иман китермәгәнен күргәч, бу хакта зарын Аллаһы Тәгаләгә белдерер өчен] **Әйтте: «Ий Раббым! һичшиксез, мин** [һич йомшаклык күрсәтмичә] **көне-төне кавемемне** [яшерен рәвештә] **дәгъват кылдым.**
6. **Әмма минем дәгъватым аларның качуларын гына арттырды.**
7. **Һичшиксез, мин,** [иман китерсеннәр һәм шул сәбәпле] **Синең үзләрен ярлыкавың өчен, аларны дәгъват иткән саен,** [минем вәгаземне ишетмәс өчен] **бармакларын колакларына тыктылар,** [миңа карата булган нәфрәтләре аркасында, мине күрмәс өчен] **киемнәренә төренделәр,** [көферлек һәм гөнаһларда] **үҗәтлек күрсәттеләр һәм, масаеп, тәкәбберләнделәр.**
8. **Шуннан соң мин аларны ачык рәвештә дәгъват иттем.**
9. **Шуннан соң** [ысул алыштырып, өченче бер юл эзләп, яшерен һәм ачык дәгъватны берләштердем дә] **мин аларга** [дәгъватымны] **игълан иттем һәм аларга яшерү белән яшердем.**
10. **Мин әйттем: «Раббыгыздан ярлыкау сорагыз. Һичшиксез, Ул –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче.**
11. [Истигъфар кылыгыз, җитмеш ел дәвам иткән корылык һәм кытлыктан соң Раббыгыз] **Күкне өстегезгә** [чиләктән койган кебек] **мул**

**яуган бер хәлдә җибәрер.**

12. **Маллар һәм ир балалар белән сезгә ярдәм итәр** [һәм киң мөмкинлекләр бирер]**, сезнең** [файдалануыгыз] **өчен бакчалар үстерер һәм сезнең өчен** [ургылып аккан] **елгалар булдырыр».**
13. **Нишләп сез Аллаһының бөеклегенә ышанмыйсыз** [да, шул сәбәпле, Аңа каршы чыгудан сакланмыйсыз]**?**
14. **Ул бит сезне** [бер тамчы су, оешкан кан һәм бер чәйнәм ит кебек] **төрле рәвешләр буларак яратты.**
15. **Аллаһының җиде күкне** [бер-бер өсле торган] **катлар хәлендә ничек** [югары бер тәртип белән] **ятратканын күрмәдегезме?**
16. **Алардагы айны** [төн караңгылыгында җирне яктырта торган] **бер нур итте, кояшны исә** [яктырткан, җылыткан] **бер кандил итте.**
17. **Аллаһы сезне** [атагыз булган Адәмне [галәйһиссәлам] **җирдән** [тиңсез бер яратылыш белән] **үсемлек кебек үстерде.**
18. **Шуннан соң аның эченә кайтарачак һәм** [терелтәсе вакытта] **сезне бер чыгарылыш белән** [аннан] **чыгарачак.**
19. **Аллаһы җирне сезнең өчен түшәк итте.**
20. **Аның өстендә киң юлларда йөрүегез өчен».**
21. **Нух** [галәйһиссәлам] моның кадәр вәгазьләрдән һич кенә дә тәэсирләнмәгән кавеменнән Аллаһка зарланыр өчен] **әйтте: «Ий Раббым! Алар миңа карыштылар һәм малы белән баласы зарарларын гына арттырган нәрсәгә иярделәр.**
22. **Алар зур хәйлә кордылар.**
23. **Алар әйттеләр: «Илаһларыгызны ташламагыз,** [бигрәк тә иң олуг потларыгыз булган] **Вәддне, Сүвагны, Ягусны, Ягукны, Нәсрне кире какмагыз!» – диделәр.**
24. **Һичшиксез, алар бик күпләрне юлдан яздырдылар.** [Ий Раббым!] **Залимнәрнең адашуларыннан башка берниләрен дә арттырма!»**
25. [Нухның [галәйһиссәлам] кавеме ширек кебек олы] **Гөнаһлары өчен алар суга батырылдылар һәм** [газабына дучар булганнан соң] **утка кертелделәр, ләкин үзләренә Аллаһыдан башка ярдәмчеләр таба алмадылар.**
26. **Нух** [галәйһиссәлам] **әйтте: «Ий Раббым! Җир йөзендә кяферләрдән яшәү урыннарында беркемне дә** [исән] **калдырма!**
27. **Чөнки Син аларны калдырсаң,** [саннары аз булган, инанган] **Синең колларыңны адаштырырлар. Алар** [балигъ яшькә җиткәч] **кяфер**

**һәм гөнаһлы кешеләрдән башка беркем дә тудырмаслар.**[1]

28. **Ий Раббым! Мине дә, ата-анамны да, өемә иманлы булырак кергән кешеләрне дә,** [Кыямәт көненә кадәр киләчәк] **иманлы ирләр белән иманлы хатыннарны да ярлыка! Залимнәргә исә һәлакәттән башка бернәрсәне дә арттырма!»**

## 72. Әл-Җинн (Җеннәр) сүрәсе

Мәккә чоры, 28 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. [Расүлем!] **Әйт: «Миңа җеннәрдән бер төркем** [Коръән укылганын] **тыңлаганы вәхи ителде, алар әйттеләр: «Һичшиксез, без** [төзелеше һәм мәгънәсе белән башка китаплардан башка булган] **гаҗәеп Коръәнне ишеттек.**
2. **Ул туры юлга илтә. Без дә аңа иман китердек.** [Шул сәбәпле] **Раббыбызга беркемне дә ширек кушмаячакбыз.**
3. **Раббыбызның бөеклеге бик өстен. Ул Үзенә хатын да, бала да алмады.**
4. **Безнең ахмагыбыз** [булган Иблис һәм аңа ияргән бозык җеннәр] **Аллаһыга карата чиктән ашкан сүз сөйли иде.**
5. **Һичшиксез, без кешеләр һәм җеннәр Аллаһы турында ялган сөйләрләр дип уйламый идек** [шуңа күрә бүгенгә кадәр Иблискә ияргән идек, ләкин хәзер Коръән безгә аларның ялганнарын фаш итте]**».**
6. [Ий Мәккә мөшрикләре! Миңа тагын болай дип вәхи ителде] **Һичшиксез, кешеләр арасыннан ирләр җеннәр арасындагы ирләргә сыеналар иде, шулай болар аларның бозыклыкларын арттыралар иде.**[2]
7. **Алар да сез уйлаган кебек Аллаһы беркемне дә** [үлгәненнән соң]

1 Ибне Габбастан (радыяллаһу ганһе) риваять ителгәнчә, алардан берәү улын Нухка (галәйһиссәлам) алып килгән, аны күрсәтеп: «Кара аны, менә моннан саклан! Бу – зур бер ялганчы! Мине атам шулай ук кисәткән иде», – дигән. Шуннан соң ул үлгәч, баласы да, шулай ук, инкяр итүче үстергән (Хазин).

2 Риваятьтән күренгәнчә, җаһилият дәверендә гарәпләрдән берәү сәфәр вакытында буш, тын, куркыныч бер урында төн кунарга мәҗбүр булгач, анда булган җеннәрнең олугын күз уңында тотып: «Кавеменең акылсызлары явызлыгыннан шушы үзәнлекнең хуҗасына сыенамын», – дигән. Шулай итеп, яктырганчы тынычлык эчендә яткан. Менә бу җеннәр башлыкларының тәкәбберлеген арттырган өчен, алар: «Без – җеннәрнең дә, кешеләрнең дә әфәнделәре», – дия торган булганнар (Бәйдави, Нәсәфи, Хазин).

**терелтмәячәк дип саныйлар иде.** [Әмма хәзер җеннәр Коръәнне тыңлап терелүне кабул иттеләр, алар кебек, сез дә ышану турында уйламыйсызмы?]

8. [Җеннәр сүзләрен болай дәвам иттеләр] **Без күккә ирешергә** [һәм аның халкының сөйләгәннәрен тыңларга] **теләдек, ләкин аның** [фәрештәләр кебек] **куәтле сакчылар һәм** [йолдызлардан купкан] **ут кисәкләре белән тулы булганын күрдек** [тә, аннан куылдык]**.**
9. [Элек] **Без,** [фәрештәләр үзара сөйләшкән яшерен хәбәрләрне] **тыңлап торыр өчен, аның кайбер урыннарында мәҗлесләрдә утыра идек. Ләкин хәзер** [Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) җибәрелгәннән соң, арабыздан] **кем дә булса** [күк хәбәрләрен] **тыңларга маташа, аны күзәтеп торган ялкынлы ут кисәге булганын күрә.**
10. **Һичшиксез, без** [күк җеннәрдән һәм шәйтаннардан сакланып] **җирдә булганнарга бер явызлык күз уңында тотыламы, яки Раббылары аларга бер игелек телиме – белми идек.**
11. **Арабызда** [иманлы, тәкъвалык иясе] **изгеләр дә бар. Янә арабызда моннан түбәндә булганнар да бар. Без аерым юлларда идек.**
12. **Без** [кайда гына булсак та] **Аллаһыны җирдә гаҗиз калдыра алмаячагыбызны һәм качу белән** [дә] **Аны һич гаҗиз итә алмаячагыбызны шиксез белдек.**
13. **Һичшиксез, без һидаятьне ишеткәч, аңа иман китердек. Кем** [безнең кебек] **Раббысына иман китерә, ул ни** [савабы] **киметелүдән, ни хурлыкка калудан курыкмас.**
14. **Арабызда мөселманнар да бар. Янә** [туры юлны калдырып] **адашканнар да бар. Мөселман булганнар туры юлга иярделәр.**
15. [Хактан] **Адашучылар исә җәһәннәмгә утын булдылар».**
16. [Янә миңа вәхи ителгәнгә күрә] **Әгәр дә алар** [җеннәр һәм кешеләр] **юлда нык торсалар, Без аларга мул итеп су эчерер** [һәм ризыклар бирер] **идек.**
17. **Аларны шуның белән сынар өчен** [шулай иттек]**. Кем Раббыгызны зикер итүдән йөз чөерә, Ул аны** [торган саен арта барган] **каты газапка кертә.**
18. **Һичшиксез,** [Аллаһы өчен намаз укылсын дип бина кылынган] **мәчетләр – Аллаһыныкы.** [Яһүди һәм насаралар гыйбадәтханәләренә кергәч ширек кушканнары кебек, сез дә мәчетләрдә] **Аллаһыдан башка беркемгә дә гыйбадәт кылмагыз!**

19. **Аллаһының** [иң бөек] **колы** [булган Расүлем] **Аңа ялварып, кыямда торган чакта, алар** [аның гыйбадәтен күргәч һәм рөкүгъ, сәҗдә кебек хәлләрендә сәхабәләренең аңа оеганын күзәтеп, кыйраәтен дә ишеткәч, шул көнгә кадәр һич күргәннәре булмаган манзара каршында хәйран калулары сәбәпле] **аның тирәсендә төркем-төркем булып өелештеләр».**
20. [Расүлем!] **Әйт: «Мин Раббыма гына гыйбадәт кылам һәм беркемне дә Аңа ширек кушмыйм.**
21. **Әйт: «Һичшиксез, минем сезгә зарарга да, файдага да көчем юк».**
22. **Әйт: «Һичшиксез,** [миңа карата начарлык теләгән очракта] **Мине Аллаһыдан беркем дә коткара алмас, һәм мин Аңардан башка сыенырлык урын таба алмам.**
23. **Ләкин Аллаһыдан ирештерүгә һәм илчелекләренә** [көчем җитә]. **Кем дә кем** [мин ирештергән бу хөкемнәрне кабул итмичә] **Аллаһыга һәм Аның Расүленә** (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) **буйсынмый, аның өчен** [кяферләр] **эчендә мәңге калачак җәһәннәм уты** [әзерләп куелган]**».**
24. [Кяферләр, иманлыларны кимсетә торачаклар]. **Аларга вәгъдә ителгән нәрсәне күргән чакларында исә, кемнең ярдәмчеләре зәгыйфьрәк һәм азрак булганын беләчәкләр.**
25. **Әйт: «Сезгә вәгъдә ителгән нәрсә якынмы, әллә Раббым аны кичектергәнме, мин белмим.**
26. [Ул] **Бөтен гаибләрне белә. Һәм Ул гаибен беркемгә дә ачмый.**
27. **Бары разый булган бер расүлгә** [генә ачар]**, чөнки Ул аның алдыннан һәм артыннан сакчылар куяр** [да, алар вәхине ирештергәнче, аны шәйтаннарның вәсвәсәләреннән саклар].[1]
28. **Алар Раббыларының илчелекләрен ирештерүләрен** [пәйгамбәр]

1 Кайберәүләр бу аятькә нигезләнеп, әүлияләргә кәрамәт буларак кайбер гаибләр белдерелә алуны инкяр иткәннәр. Моның чыганагы – зур наданлык, чөнки бу аяте кәримәгә тыштан карап гаибләр бары тик расүлләргә белдерелә дигән хөкемгә киленсә, фәрештәләргә дә, нәбиләргә дә беркинди гаибнең белдерелмәгәнен кабул итү кирәк була. Шуңа күрә биредә «Аллаһы Тәгаләнең бөтен гаибләрен расүлләренә белдерә» дигән мәгънә чыгарылырга тиеш булмаган кебек, «расүл булмаган фәрештәгә дә, нәбигә дә, әүлиягә дә беркинди гаибне белдерми» дигән хөкем дә чыгарырга ярамый. Мәсәлән, Хозыр (галәйһиссәлам) кебек пәйгамбәрлеге турында шик булмаган бер затка ничәмә-ничә гаибнең белдерелгәне Коръәни Кәримдә ап-ачык бәян ителгән. Моннан тыш, ике сахих хәдисләр җыентыгында да элекке өммәтләрдә булган кебек, бу өммәттә дә кайбер гаибләр белдерелгән коллар барлыгы хәбәр ителгән (Бохари, Әнбия: 52, № 3282, 3/1279, Мөслим, Фәзаил әс-сахабә: 2, № 2398, 4/1864). Шулай булгач, монда пәйгамбәрләргә генә бәйләп әйтелү арадашчысыз, вәхи юлы белән белдерелүне аңлата, әүлияләргә исә төш яки илһам кебек арадашчылар аркылы кайбер гаибләр белдерелә ала. Ләкин бу пәйгамбәрләргә белдерелгән кебек катгый гыйлем була алмый (Бәйдави, Нәсәфи, Хазин, Алуси).

**белсен өчен. Ул** [Раббылары] **аларның яннарында булганны уратып алган шәкелдә белә, Ул** [яңгыр тамчыларына һәм ком бөртекләренә кадәр булган] **һәрнәрсәне** [берәм-берәм] **санап куйган.**

## 73. Әл-Мүззәммил (Чорналган) сүрәсе

Мәккә чоры, 20 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Ий** [беренче вәхи килгәч, киеменә] **төренгән** [Расүлем]**!**
2. **Төнне уяу үткәр, бик азыннан кала.**
3. **Яртысын** [уяу уздыр] **яки аннан да бераз кимет** [тә, өчтән берен намазда үткәр]**.**
4. **Яки аңа өстә** [һәм өчтән икесен гыйбадәттә үткәр]**. Коръәнне тәртил белән** [әкрен-әкрен, ачык итеп] **укы.**
5. **Без тулысынча сиңа** [һәркем җиңел генә аңлый алмаслык] **авыр** [әһәмиятле] **бер сүз җибәрәчәкбез.**
6. **Һичшиксез, төнлә кыямда булган кеше** [йөрәк белән тел] **ярашу ягыннан көчлерәк, уку ягыннан да дөресрәк.**
7. **Һичшиксез, син көндез бик озак мәшгуль буласың** [һәм гыйбадәтеңә тиешенчә игътибар итә алмыйсың, шуңа күрә төннәреңне Раббыңа гыйбадәткә бүл]**.**
8. [Намаз укып, Коръән укып, тәһлил кебек зикерләр белән] **Раббыңның исемен зикер ит һәм** [игътибарыңны Раббыңнан башка һәрнәрсәдән] **тулысынча өзеп, Аңа гына багышла.**
9. **Көнчыгышның һәм Көнбатышның Раббысы, Аннан башка һичбер илаһ юк. Шулай булгач, Аны** [һәр эшеңдә] **бер Яклаучы ит.**
10. **Аларның** [Минем һәм синең хакта] **сөйләгән** [мәгънәсез һәм ялган] **нәрсәләренә сабырлы бул һәм** [аларның һәр кыланышларына җавап бирү юлына басма, ихтыярлы бер шәкелдә] **аларны күркәмлек белән кире как.**
11. **Мине нигъмәт ияләре булган ялганчылар белән калдыр һәм аларга** [Бәдер көненә кадәр] **аз гына** [бервакытка] **кичектерү бир** [чөнки сине мыскыл иткән Корәеш мөшрикләренә ул вакыт Мин җитәрлек булачакмын]**.**
12. **Һичшиксез, Безнең хозурыбызда** [кяферләрне җәзалау өчен] **богаулар һәм Ут бар.**

13. **һәм** [ут чәнечкеләре һәм зәкъкум агачы кебек] **тамакка тыгыла** [ашказанына да үтми, тышка да чыкмый] **торган ашамлык һәм тилмерткеч газап бар.**
14. **Ул көнне җир һәм таулар тервячәк һәм** [биеклектә үрнәк булган] **таулар чәчелә торган ком өеме булачак.**
15. [Ий ахырзаман өммәте!] **Һичшиксез, Без фиргавенгә илче җибәргәнебез кебек, сезгә дә шаһит итеп бер расүл җибәрдек.**
16. **Фиргавен илчегә каршы төште, һәм Без аны бик каты бер тотып алу белән тотып алдык.**
17. [Ий кешеләр!] **Әгәр дә** [дөньяда] **кяфер булсагыз, балаларны чал чәчле** [карт кебек] **итәчәк көннән ничек котылырсыз?**
18. **Күк** [хәтта] **ул көнне** [дәһшәттән] **ярылачак. Аның** [Аллаһы Тәгаләнең] **вәгъдәсе тулысынча үтәләчәк.**
19. **Һичшиксез, бу –** [эчләренә янауларны алган аятьләр] **үгет.** [Һидаятьне табарга] **Теләгән** [иман һәм итагать белән] **Раббысына таба бер юл тотар.**
20. **Һичшиксез, синең Раббың белә: син** [үзеңә әмер ителгәнчә хәрәкәт итеп, кайчак] **төннең өчтән икесеннән азрак бервакытны,** [кайчак] **яртысын һәм** [кайчак] **өчтән берен** [тәһәҗҗөд белән] **үткәрәсең, синең белән бергә булган кешеләрдән бер өлеше дә** [шулай итә]**. Төнне һәм көнне Аллаһы тәкъдир итә. Ул** [Аллаһы Тәгалә] **сезнең моңа** [төн буена гыйбадәткә] **көч җиткерә алмаячагыгызны белә, шуңа күрә тәүбәгезне кабул итте.** [Намазларда] **Коръәннән үзегезгә җиңел килгәнне укыгыз. Ул** [Аллаһы Тәгалә] **белә: арагызда авырулар булачак, башкалар Аллаһының фазылыннан** [ризык яки гыйлем] **эзләгән хәлдә җирдә сәфәргә чыгачаклар, башкалар исә Аллаһы юлында сугышачаклар** [һәм таңга кадәр гыйбадәт кылырга көч тапмаячаклар]**. Шулай булгач,** [намазларда] **аннан үзегезгә җиңел булганны укыгыз,** [фарыз] **намаз укыгыз, зәкят бирегез,** [бурыч сораучыга рибасыз акча бирү кебек] **яхшы нәрсәне Аллаһыга бурычка бирегез. Игелектән үзегез өчен** [Ахирәткә дип] **нәрсә әзерлисез, Аллаһы хозурында шуны** [дөньянык белән чагыштырганда] **яхшырак һәм савап ягыннан артыграк табачаксыз. Аллаһыдан**

**ярлыкау сорагыз. Һичшиксез, Аллаһы –Гафу итүче, Рәхимле.**

## 74. Әл-Мүддәссир (Төренгән) сүрәсе

Мәккә чоры, 56 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Ий капланган** [Пәйгамбәрем]**!**
2. **Тор һәм** [кавемеңне] **кисәт!**
3. **Раббыңны олыла!**
4. **Киемнәреңне** [бөтен керләрдән] **чистарт!**
5. **Газапны** [үзеңнән] **ераклаштыр!**
6. [Кылган бер ярдәмне] **Күп күреп игелек кылма** [һәм ярдәм итүеңне кешенең башына кагып битәрләмә]**.**
7. **Раббың өчен сабыр ит!**
8. **Чөнки быргыга өрелгәч.**
9. **Ул көн – бик читен бер көн.**
10. **Кяферләр өчен һич җиңел түгел.**
11. **Мине Үзем бар иткән** [Вәлид бине Могыйра исемле] **кеше белән берүземне калдыр.**[1]
12. **Мин аңа күп мал бирдем.**
13. **Янында торган уллар да** [бирдем]**.**
14. **Һәм аңа тулы бер җәю белән** [мөмкинлекләрне] **җәйдем.**
15. **Шуннан соң да арттырыйм дип хирыслана.**
16. **Юк!** [Бу өметен һич акламаячакмын]. **Чөнки ул – Безнең аятьләребезгә карата** [инкярен дәвам иткән] **үҗәт** [бер адәм]**.**
17. **Мин аны** [җитмеш елда менеп, җитмеш елда төшәсе һәм мәңге шулай газап чигәсе] **текә үргә салачакмын.**
18. **Чөнки ул** [Коръән хакында ни әйтәсен] **уйлады һәм исәпләде.**
19. **Каһәр төшсен аңа! Ничек исәпләде!?**
20. **Шуннан тагын каһәр төшсен аңа! Ничек исәпләде!?**
21. **Шуннан соң ул** [кешеләрнең йөзләренә] **карады.**
22. **Шуннан соң чыраен сытты һәм кашларын җыерды.**
23. **Шуннан соң** [хактан ераклашып] **артына борылды һәм**

---

1 Һәр кеше анасының карынында ялгыз була – аның Аллаһыдан башка ярдәмчесе дә, гаиләсе дә, милке дә булмый. Монда һәм алга таба Раббыбыз тарафыннан телгә алынган кяфер – ул Әл-Вәлид бине Әл-Могыйра. Аллаһы Тәгалә аңа байлык һәм нәселне мулдан бирә. Ибне Габбас әйтүенчә, аның биләмәләре Мәккәдән Таифка кадәр сузылган була. Имам Әс-Саури билгеләгәнчә, аның еллык кереме ун миллион динарга җиткән.

[Расүлуллаһка (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) иярүдән үзен өстен күреп] **тәкәбберләнде.**

24. **Һәм әйтте: «Бу – кабатлап сөйләнгән сихер генә.**
25. **Бу – тик кеше сүзе».**
26. **Мин аны Сәкарга кертәчәкмен.**
27. **Сәкарның ни икәнен син каян белә аласың?** [Ул – шундый бер җәһәннәм].
28. **Ул ни** [ит] **калдырмый, ни** [сөякне] **бетерми куймый.**
29. **Ул тирене яндыра.**
30. **Өстендә** [вазифалы] **унтугыз** [фәрештә] **бар.**[1]
31. **Без Утның сакчылары итеп фәрештәләрне вазифаландырдык. Китап бирелгән кешеләр шиксез ышансыннар, иман китерүчеләр** [илаһи китаплар арасындагы бу уртаклыкны күреп] **иманнарын арттырсын, күңелләрендә** [нифак кебек] **чир булган кешеләр һәм** [Мәккәдәге] **кяферләр: «Бер үрнәк итеп Аллаһы моның белән нәрсә әйтергә теләгән?» – дисеннәр өчен, Без аларның санын** [шулкадәр аз итеп] **кяфер булган кешеләр өчен бер сынау иттек. Аллаһы шулай теләгәнен адаштыра, теләгәнен һидаять итә. Раббыңның гаскәрләрен Үзеннән башка беркем дә белми. Бу –** [аятьләрдә сөйләнелгән Сәкар һәм зобаниларның саны] **исә кешелек өчен бер үгет кенә.**
32. **Юк!** [Алар зобанилар белән һич җиңә алмаслар]. **Ай белән ант итәмен!**[2]
33. **Чигенеп барган төн белән ант итәмен!**
34. **Ата башлаган таң белән ант итәмен!**
35. **Һичшиксез,** [җәһәннәм] **иң зур бәлаләрнең берсе.**
36. **Кешелек өчен бер кисәтү буларак.**
37. **Арагыздан** [игелекләргә таба] **алга барырга яки** [алардан] **артта калырга теләгән** [инанган һәм инанмаган] **кешеләр өчен.**
38. **Һәр кеше** [яхшымы, начармы] **ирешкән нәрсәсе өчен** [Аллаһы хозу-

1 Риваятьләргә караганда, бу фәрештәләрнең күзләре яшен кебек ялтырый, азау тешләре кальгалар кебек нык, авызларыннан ялкыннар чыга, һәрберсенең ике иңбаш арасы бер еллык ара киңлегендә һәм һәрбере җитмеш мең кешелек төркемне җәһәннәмнән теләгән урынга ыргытырлык көчкә ия (Хазин).

2 Зобаниларның унтугыз булуын белдергән аять иңүеннән соң, Әбү Җәһел Корәешкә: «Сез моның кадәр күп була торып, арагыздан һәрбер ун кеше бу унтугыз фәрештәнең берсенә өстен чыгудан гаҗизмени?» – дигәч, күнне аягы белән ерткаларлык дәрәҗәдә көчле булган Әбү Әл-Әшүдд: «Унҗидесенә мин дә җитәрмен, сез икесен хәл итәрсез!» – дигәнгә, җавап итеп бу аяте кәримә иңгән (Алуси).

рында] **җаваплы.**

39. **Уң якның кешеләреннән башка** [ки, алар дәфтәрләрендә булган күркәм гамәлләре аркасында рәһеннәрен түләп котылуга ирешер]**.**
40. [Алар] **Җәннәтләр эчендә бер-берләреннән сорашачаклар.**
41. **Гөнаһлылар хакында** [аннары араларындагы пәрдә ачылгач, әйтерләр:]
42. **«Сезне Сәкарга нәрсә кертте?»**
43. [Җәһәннәм әһеле] **Әйтер: «Без намаз укучылар түгел идек.**
44. [Мөселманнар кебек] **Мескеннәрне дә ашатмадык.**
45. [Аллаһының аятьләрен инкяр итүгә] **Керешкәннәр белән без дә керешкән идек.**
46. **Җәза көнен дә ялган дип саный идек.**
47. **Хакыйкать** [булган үлем] **безгә килгәнче».**
48. [Фәрештәләр, пәйгамбәрләр һәм изгеләрдән торган бөтен] **Шәфәгатьчеләрнең дә шәфәгате аларга файда бирмәс.**
49. **Ни булды аларга? Нишләп алар Үгеттән йөз чөерәләр?**
50. **Куркытылган кыргый ишәкләр кебек.**
51. **Арысланнан качкан.**
52. **Әмма аларның һәрбере җәеп салынган** [һәм эчендә: «Аллаһыдан фәлән колга! Мөхәммәдкә ияр!» – дип язылган] **сәхифәләр үзенә бирелсен иде дип тели.**
53. **Юк! Алар Ахирәттән курыкмыйлар.**
54. **Юк! Һичшиксез, ул** [Коръән] – [зур бер] **Үгет.**
55. [Ике җиһан бәхетен казанырга] **Теләгән кемсә аны хәтерләр, үгет алыр.**
56. [Алар: «Алай булгач, теләгән чагыбызда Коръәнне тикшерербез, күңелебезгә ятса, ышанырбыз!» – диләр] **Ләкин Аллаһы теләмәсә, алар хәтерләп үгет ала алмаслар. Ул – саклануга лаек һәм** [сакланганнарга карата] **мәгъфирәт әһеле булучы.**

## 75. Әл-Кыямә (Кыямәт) сүрәсе

Мәккә чоры, 40 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Кыямәт көне белән ант итәмен!**
2. [Кыямәт көнендә үзен] **Шелтәүче җан белән ант итәмен** [һичшиксез терелтеләчәксез]**!**

3. **Кеше** [үлеп таркалганнан соң] **Без аның сөякләрен җыя алмаячакбыз дип саныймы әллә?**
4. **Әйе! Бармакларын** [да дөньяда булган хәлләрендә] **җыярга көчебездән килә.**
5. **Әмма кеше** [булган хәлендәге кебек] **алга таба да хактан тайпылуын дәвам итәргә тели.**
6. [Үҗәтләнеп] **Шуннан сорый: «Кыямәт көне кайчан соң?»**
7. [Күргән нәрсәләрнең зурлыгы сәбәпле] **Күзләр акайгач.**
8. **Айның яктысы югалгач.**
9. **Кояш белән ай** [көнбатыштан чыгу ноктасында] **берләшкәч.**
10. **Шул көнне кеше: «Кая качарга?» – диячәк.**
11. **Юк** [ий кеше]**! Сыенырлык бер урын да юк!**
12. **Бүген урнашу – Раббыңда.**
13. **Ул көнне кеше киләчәк өчен әзерләгән һәм үзеннән соң калдырган** [кылган һәм кылмаган] **нәрсәләреннән хәбәрдар ителәчәк.**
14. **Кеше үзенә каршы шаһит.**
15. **Ул гозерләрен белдерсә дә** [бер файда да күрмәс]**.**
16. [Ий Җәбраил китергән вәхине тыңлаганда ул бетергәнче укый башлаган Расүлем!] **Аны тизрәк отып алыр өчен** [тәмамлануын көтмичә] **телеңне дә кузгатма!**
17. **Һичшиксез, аны** [синең хәтереңдә] **җыю да һәм укыту да – Безнең өстебездә.**
18. **Һәм Без аны** [Җәбраилнең теле белән] **укыган чакта, син аның укуына ияр генә!**
19. **Шуннан соң аны** [мәгънәләре белән] **аңлату – Безнең өстебездә.**
20. **Юк шул** [ий коллар]**! Сез ашыга торганын** [дөньяны] **сөясез.**
21. **Ахирәтне исә кире кагасыз.**
22. **Ул көнне бер төрле йөзләр бик матур.**
23. **Раббысына карап торучы.**
24. **Бер төрле йөзләр исә сытык һәм кара.**
25. **Алар үзләренә сырт сөякләрен сындырачак бер эш эшләнәчәген шиксез беләләр.**
26. **Юк!** [Үлем сәгатендә] **Ул** [җан] **умрау сөягенә ирешкәч.**
27. [Янындагылар тарафыннан:] **«Кем** [үлемнән калыр өчен] **әфсен укыр?» – диелгән чакта.**
28. **Ул кеше** [дөньядан] **аерылу булганын аңлагач.**
29. **Сыйрак сыйрак белән кушылгач.**

30. **Шул көнне куып китерү – Раббыңа** [әмер итәчәк урынга – җәннәткә яки җәһәннәмгә]**.**
31. [Әбү Җәһел] **Иман китермәде һәм намаз укымады.**
32. **Ләкин** [Коръәнне] **ялган дип санады һәм** [иманнан] **йөз чөерде.**
33. **Шуннан соң** [кылганы белән мактанган бер хәлдә] **масаеп гаиләсе янына китте** [дә Расүлуллаһка (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) әйткәннәрен сөйләп бирде]**.**
34. **Ни үкенеч сиңа, янә ни үкенеч!**
35. **Тагын ни үкенеч сиңа, ни үкенеч!**
36. **Әллә кеше караучысыз калдырылган** [үлеме артыннан терелтелеп, җәзаландырылмас] **дип саныймы?**
37. **Ул** [аналыкка] **атып чыгарылган мәнидән бер тамчы түгел идемени?**
38. **Шуннан соң** [сөлек кебек аналык диварына ябышып кан имеп тукланган аталанган йомыркадан гыйбарәт] **оешкан кан булды, аннары Ул аны бар итте һәм** [әгъзаларын тәмамлап, тәкъдир ителгән рәвешкә кертеп аны] **шәкелләндерде.**
39. **Ул** [Аллаһы Тәгалә] **алардан пар – ир һәм хатынны барлыкка китерде.**
40. **Әллә бу** [кадәр бөек сәнгатьләр иясе булган] **Зат үлеләрне терелтергә кодрәтле түгелме?**

## 76. Әл-Инсән (Кеше) сүрәсе

Мәккә [1] чоры, 31 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Кешенең** [ана карынында] **искә алынмый торган бернәрсә булган чагы үтмәдемени?**
2. **Без кешене сынар өчен,** [ир белән хатыннан] **кушылган тамчыдан яраттык һәм аны ишетә, һәм күрә ала торган иттек.**
3. **Без** [аятьләр иңдереп һәм дәлилләр китереп] **аңа** [туры] **юлны күрсәттек: йә шөкер кылучы, йә кяфер** [булыр]**.**
4. **Без кяферләр** [җәһәннәмдә сөйрәп йөртелер] **өчен чылбырлар, богаулар һәм Ут әзерләп куйдык.**

1 Мәдәни дип белдерүчеләр дә булган, шулай мәкки һәм мәдәни аятьләр дә барлыгы хәбәр ителгән.

5. **Һичшиксез, изге коллар касәдән** [татлы, хуш исле һәм ак] **камфара кушылган** [җәннәт шәрабы] **эчәчәкләр.**
6. [Һәм бу] **Чишмә, аңардан Аллаһының** [сайланган] **коллары эчәчәкләр һәм** [җиңел генә] **агызу белән** [үзләре теләгән якка] **аны агызачаклар.**
7. **Алар** [берәр нәзер әйткән чакта] **нәзерне үтиләр һәм яманлыгы таралган көннән куркалар.**
8. [Кытлык аркасында ашауга ихтыяҗлары булуга һәм] **Аны яратуларына карамастан, мескенне, ятимне һәм әсирне ашаталар.**
9. [Һәм әйтәләр] **«Без сезне Аллаһының Үзе өчен генә ашатабыз. Без сездән бер әҗер дә, бер рәхмәт тә көтмибез.**
10. **Без бит читен һәм бәлале бер көндә Раббыбыздан куркабыз».**
11. **Аллаһы аларны ул көннең явызлыгыннан саклар һәм аларга балку һәм** [күңелләренә] **шатлык бирер.**
12. [Гыйбадәтләрнең авырлыгына һәм кяферләрнең җәфалавына] **Сабыр иткәннәре өчен, Ул аларны җәннәт һәм ефәк** [киемнәр] **белән бүләкләр.**
13. **Анда** [кыйммәтле пәрдәләр корылган гөмбәзләр астындагы] **ятаклар өстендә таянган хәлдә** [хозур эчендә булачаклар]. **Алар анда** [эссе] **кояш та,** [өшетә торган] **суык та күрмәячәкләр.**
14. **Өсләренә** [агачларының] **күләгәләре якын булган** [икенче бер җәннәт] **белән** [бүләкләнәчәкләр]. **Җимешләре дә** [сузылып алуы җиңел ителеп] **тулысынча буйсындырылган.**
15. **Көмештән савытлар һәм бәллүр чүмечләр белән тирәләрендә әйләнеп йөриячәкләр.**
16. **Көмештән бәллүр, алар аларны үлчәп куйганнар** [алар нәкъ теләгәннәречә мәйданга килгәннәр]**.**
17. **Аларны анда касәдән имбир кушылган** [шәраб] **эчерерләр.**
18. **Андагы Сәлсәбил дип атала торган чишмәдән.**
19. **Алар тирәсендә мәңге яшь** [һәм чибәр булган] **яшүсмерләр** [хезмәт күрсәтеп] **әйләнеп йөриячәк. Син аларны күргәч, аларны чәчелгән энҗе дип санарсың.**
20. **Син анда** [мөмкинлекләрне] **күргәч, нигъмәт һәм бөек хөкемдарлык күрерсең.** [Мәсәлән, җәннәт әһеленең иң астагысы да ия булган милекне мең еллык ара кебек табачак].
21. **Өсләрендә – юка һәм калын ефәктән ямь-яшел киемнәр. Алар көмеш беләзекләр белән бизәнер. Раббылары аларга пакь эчем-**

**лек эчерер.**

22. [Ул көнне аларга] **Һичшиксез, бу – сезнең** [гамәлләрегез] **өчен әҗер, сезнең тырышлыгыгызга яхшылык белән җавап кайтарылды»** [дип әйтеләчәк]**.**
23. **Һичшиксез, Без бу Коръәнне сиңа** [бер хикмәт белән өлеш-өлеш] **иңдерү белән иңдердек.**
24. **Шулай булгач, Раббыңның** [ярдәмен кичектерү] **хөкеменә сабыр ит, алардан** [ширек кушканнардан] **бер гөнаһлыга яки кяфергә буйсынма!**
25. **Иртән** [иртә намазын укып] **һәм зәвәлдән соң** [өйлә һәм икенде намазларын укып] **Раббыңның исемен зикер ит.**
26. **Төнлә дә Аңа сәҗдә кыл. Төннең озын бер өлешендә** [тәһәҗҗөд намазын укып] **Аны тәсбих ит.**
27. **Һичшиксез, болар** [Коръәнне инкяр итүчеләр] **тиз үтүчәнне** [дөньяны] **яраталар, үзләреннән соң исә авыр бер көн калдыралар.**
28. **Без аларны яраттык, яратылышларын нык иттек. Әгәр дә теләсәк, аларны** [яратылышта] **охшашлары** [әмма иманлы кешеләр] **белән алмаштырырбыз.**
29. **Һичшиксез, бу – үгет. Һәр** [ике җиһан бәхетенә ирешергә] **теләгән** [иман белән] **Раббысына таба юл алыр.**
30. [Ий мөшрикләр! Сез: «Теләгән чагыбызда юлга керербез», – дип әйтәсез] **Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе.**
31. **Ул** [Раббыгыз] **рәхмәте** [җәннәт] **эченә кертәчәк.** [Үзенә бирелгән ихтыяр һәм көчне туры юлны эзләүдә кулланмаган] **Залимнәргә исә Ул тилмерткеч газап әзерләп куйган.**

## 77. Әл-Мүрсәләәт (Җибәрелгәннәр) сүрәсе

Мәккә чоры, 50 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. [Аллаһының вәхиләрен китерер өчен, ат ялы кебек] **Бер-бер артлы җибәрелгәннәр** [фәрештәләр] **белән ант итәмен.**
2. [Өермә кебек] **Көчле бер исү белән** [ашыккан һәм җил кебек] **искәннәр** [фәрештәләр] **белән** [ант итәмен]**.**
3. [Ислам хөкемнәрен җир йөзендә] **Ашкынып таратучылар**

[фәрештәләр] **белән** [ант итәмен]**.**

4. [Хакны ялганнан] **Яхшы аеручылар белән** [ант итәмен]**.**
5. [Пәйгамбәрләргә] **Вәхи тапшыручылар белән.**
6. [Хак юлдагыларга] **Гафу итүләр яки** [ялгыш юлдагыларга] **кисәтүләр бирер өчен.**
7. **Һичшиксез, сезгә вәгъдә ителгән** [Кыямәт кубу белән бәйле] **нәрсә булачак.**
8. **Йолдызлар сүнгәч.**
9. **Күк** [йөзе] **ярылгач.**
10. **Таулар урыннарыннан кубып теткәләнгәч.**
11. [Шаһитлык итәр өчен] **Расүлләргә вакыт билгеләнгәч.**
12. [Әйтеләчәк:] **«**[Ул пәйгамбәрләрнең шаһитлыгы мәсьәләсендә] **Кайсы көнгә кадәр кичектерү биреләчәк?**
13. [Барлыклар арасында] **Аерма ясау** [вакыты булган Кыямәт] **көненә кадәр!»**
14. **Ул аерма ясау көненең ни икәнен син каян беләаласың?**
15. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
16. **Без әүвәлгеләрне һәлак итмәгән идекме?**
17. **Шуннан соң алар артыннан калганнарны** [һәлакәткә] **җибәрәчәкбез.**
18. [Ширек гөнаһын кылган] **Гөнаһлыларга без шулай итәчәкбез.**
19. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
20. **Без сезне әһәмиятсез судан яратмадыкмы?**
21. **Шуннан соң аны ышанычлы урын** [аналык] **эченә урнаштырдык.**
22. [Туар өчен тәкъдир ителгән] **Билгеле булган бервакытка кадәр.**
23. **Без** [моңа] **көч җиткердек.** [Без] **Нинди күркәм көч җиткерүчеләр!**
24. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
25. **Без җирне туплану урыны итмәдекмени?**
26. [Өстендә] **Тереләрне һәм** [астында] **үлеләрне** [сыендырмадыкмыни]**?**
27. **Без аңарда какшамас таулар урнаштырдык һәм сезгә төче су эчердек.**
28. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
29. [Кыямәт көнне кяферләргә әйтеләчәк] **«Үзегез ялган дип санаган нәрсәгә барыгыз!**
30. [Зурлыгы сәбәпле] **Өч тармаклы күләгәгә** [һәм җәһәннәм төтененә] **барыгыз.**
31. [Утның эссесеннән] **Күләгә дә ясамый, уттан да коткармый.**
32. **Ул** [җәһәннәм] **сарай кебек** [зур һәм биек] **очкыннар ата бит.**

33. **Гүяки алар –** [бер-берсе артыннан барган] **сап-сары дөяләр».**
34. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
35. **Бу** [җәһәннәмгә керү вакыты] **– алар** [коточкыч дәһшәттән һәм шаккатудан телләре тотылып] **сөйләшә алмаячак көн.**
36. **Аларга** [сүз әйтеп] **акланырга рөхсәт тә бирелмәячәк.**
37. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
38. [Ул көнне кяферләргә әйтеләчәк сүзнең берсе] **«Бу** [көн] **– аерма ясау көне. Без сезне дә, сездән әүвәлгеләрне дә** [хозурыбызда] **бер арага китердек.**
39. **Әгәр дә сездә** [Минем газабымнан котылу мәсьәләсендә] **бер хәйлә булса,** [һич тартынмыйча] **Миңа тозак корыгыз** [да газаптан качыгыз]**.**
40. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
41. [Ширектән сакланган] **Тәкъвалык ияләре күләгәләр һәм чишмәләр арасында** [булачаклар]**.**
42. **Һәм җаннары теләгән** [төрле-төрле] **җимешләр** [арасында]**.**
43. [Җәннәткә кергән чакларында, аларга әйтеләчәк] **«**[Дөньяда чакта] **Кылган** [яхшы] **нәрсәләрегез өчен тынычлык белән ашагыз һәм эчегез!»**
44. **Һичшиксез, Без игелек кылучыларга шушылай әҗерләрен бирәбез.**
45. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
46. [Ий кяферләр!] **«**[Дөньяда яшәгән санаулы көннәрегез кадәр] **Ашагыз һәм бераз** [тагын дөнья нигъмәтләреннән] **файдаланыгыз, чөнки, һичшиксез, сез – гөнаһлыларсыз».**
47. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
48. **Алар: «**[Бу тәкәбберлекне калдырыгыз да, Аллаһыга иман китереп, намазда] **Рөкүгъка барыгыз!» – дип әйтелгәч, алар рөкүгъ кылмыйлар.**
49. **Ялганда гаепләүчеләргә ул көнне ни үкенеч!**
50. [Бу Коръәнгә ышанмаганнар] **Моннан соң нинди сүзгә ышаначаклар?**

## 78.Ән-Нәбә (Хәбәр) сүрәсе

Мәккә чоры, 40 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Алар** [кяферләр] **бер-берләреннән нәрсә сорашалар?**
2. [Терелү мәсьәләсе кебек] **Бөек хәбәр турында.**

3. **Ул** [шундый хәбәр] **ки, алар аның хакында каршылыклы фикердә.**
4. **Юк! Алар** [хакыйкатьне] **беләчәкләр.**
5. **Тагын бер юк!** [Терелү берничек тә инкяр ителә алмый]. **Алар** [сораган нәрсәләренең чынга ашканын ачыктан-ачык күргәч, аның хак булганын] **беләчәкләр.**
6. **Без җирне бишек** [кебек рәхәтләнеп урнашыла алган урын] **итмәдекмени?**
7. **Тауларны да казыклар буларак.**
8. **Без сезне** [ирле-хатынлы] **парлар хәлендә яраттык.**
9. **Йокыгызны ял итү иттек.**
10. **Төнне Без** [караңгылыгы белән һәрнәрсәне каплаган] **бер пәрдә иттек.**
11. **Көндезне исә кәсеп итү вакыты иттек.**
12. **Өсләренә нык җиде** [кат күк] **бина иттек.**
13. **Балкып торган бер кандилне** [кояшны] **бар иттек.**
14. [Җилләр тарафыннан] **Суы чыгарылып сыгылганнардан** [болытлардан] **күп итеп түгелгән су иңдердек.**
15. **Аның ярдәмендә** [туфрактан] **орлыклар һәм үсемлекләр үстерик дип** [иңдердек].
16. [Агачлары] **Куе** [булып үскән] **бакчаларны да.**
17. **Һичшиксез,** [яхшы белән начар һәм хак белән хаксыз арасында] **аерма ясау көне – билгеләнгән бервакыт.**
18. **Ул көнне сурга өреләчәк, һәм сез** [дөньяда буйсынган башлыкларыгыз белән бергә] **төркем-төркем булып** [мәхшәргә] **киләчәксез.**
19. **Күк тә** [фәрештәләр төшәр өчен ярылып] **ачылачак һәм** [ул көнне] **капкалар булачак.**
20. **Таулар** [җир йөзеннән кубып, һавада] **хәрәкәткә киләчәкләр һәм рәшә булачаклар.**
21. **Һичшиксез, җәһәннәм – капкын.**
22. **Чиктән ашканнар өчен кайту урыны.**
23. **Алар анда чиксез заманнар буе калачаклар.**
24. **Анда ни салкынча һава, ни** [сусауны баса торган] **эчемлек татымаячаклар.**
25. **Бары** [йөзләренә тидергән чакта тиреләрен өтеп алачак һәм эчкән чакларында эчәк-бавырларын өзгәләячәк дәрәҗәдә] **кайнар су һәм** [җәһәннәм әһеленең яраларыннан чыккан] **эрен** [эчәчәкләр].
26. [Дөньяда кылган начар гамәлләргә] **Тиешле җәза буларак** [бу газапларга дучар ителәчәкләр].

27. **Чөнки алар** [терелүгә ышанмаганнары өчен, кылган гамәлләре белән бәйле] **хисапны көтмиләр иде.**
28. **Безнең аятьләребезне дә тулысынча ялган дип саныйлар иде.**
29. **Без бит һәрнәрсәне санап һәм** [Ләүхүл-Мәхфүзгә] **язып куйдык.**
30. [Җәһәннәмдә янган кяферләргә] **«Алайса татыгыз** [бу газапны]**! Без сезгә газаптан башка бернәрсәне дә арттырмаячакбыз!»** [дип әйтеләчәк].
31. **Тәкъвалык ияләре өчен котылу бар.**
32. **Бакчалар һәм йөземнәр.**
33. **Яшь кызлар – яшьтәшләр.**
34. **Янә шәраб тулы касәләр.**
35. **Алар анда буш сүз дә, ялганлау да ишетмәячәкләр.**
36. **Синең Раббыңнан бер әҗер һәм бүләк буларак.**
37. **Күкләрнең, җирнең һәм аларның арасындагыларның Раббысы булган Рахманнан, алар Аңа дәшәргә көч җиткерә алмаячаклар.**
38. **Рухның һәм фәрештәләрнең бер саф хәлендә торасы көнне алар сөйли алмаячаклар. Фәкать Рахман рөхсәт биргәннәр генә** [сөйли алачак]**, һәм ул дөресен сөйләячәк.**
39. **Ул Көн – хак. Кем** [чиксез рәхмәткә ирешергә] **тели,** [итагатькә борылып] **Раббысына кайту юлын табар.**
40. [Ий кяферләр!] **Һичшиксез, Без сезне якын булган бер газап белән куркыттык** [Кыямәт үлемнән башланганлыктан, бу газап бик якын]**. Кеше ике кулы эшләгән** [яхшы-яман һәр] **нәрсәне күрәчәк, кяфер исә: «Аһ, мин** [дөньяда] **туфрак булса идем!» – диячәк көнне** [газап чынга ашачак].

# Фән

# «Хәдис» гыйлеменең аңлатмасы

«Хәдис» гыйлеме ике төрле була:

1. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен (хәдисләрен) җыеп, туплап һәм аларны тапшырган фән (гыйлем әл-хәдис би әр-ривайә).

2. Хәдисләрнең дөреслек дәрәҗәсен билгеләргә һәм хәдиснең бирелү чылбырын аңларга мөмкинлек биргән фән (гыйлем әл-хәдис би әд-дирайә).

## Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен (хәдисләрен) җыйный һәм тапшыра торган фән

Хәдис фәненең өйрәнелү предметы: пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән чыккан сүз, эш, килешү, холкый һәм әхлакый сыйфат рәвешендә булып, сәхабәләр һәм табигыйннәр тарафыннан бер-берсенә риваять ителеп, хәдис җыючыга барып җиткән хәбәрне хәдис дип атыйлар.

Хәдис фәненең максаты: пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әйткән сүзләрен, гамәлләрен, әхлакый һәм холкый сыйфатларын тапшыруда хаталардан саклану.

Хәдис фәненең файдасы: ике дөньяда да бәхеткә ирешү.

Фән өйрәнүнең өстенлеге: мөһим фәннәр арасында югары урында торуы әлеге фәнне өйрәнүнең өстенлеген күрсәтә. Хәдис фәне Аллаһы Тәгаләнең кушуы буенча безгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ни рәвешле ияргә икәнлеген өйрәтә. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең түбәндәге аятьләрендә болай дип әйтә:

قُلْ يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنِّي رَسُولُ اللَّهِ إِلَيْكُمْ جَمِيعًا الَّذِي لَهُ مُلْكُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ ۖ لَا إِلَٰهَ إِلَّا هُوَ يُحْيِي وَيُمِيتُ ۖ فَآمِنُوا بِاللَّهِ وَرَسُولِهِ النَّبِيِّ الْأُمِّيِّ الَّذِي يُؤْمِنُ بِاللَّهِ وَكَلِمَاتِهِ وَاتَّبِعُوهُ لَعَلَّكُمْ تَهْتَدُونَ ﴿١٥٨﴾

**«[Расүлем! Үзең белән бүтән пәйгамбәрләр арасындагы аерманы аңлатыр өчен, бөтен колларыма] Әйт: «Ий кешеләр! Һичшиксез, мин – сезнең һәммәгезгә [җибәрелгән] Аллаһының расүлемен. Күкләрнең һәм җирнең хакимлеге Аныкы гына, Аннан башка илаһ юк, Ул терелтә һәм җаннарны ала. Аллаһыга да, Аллаһыга һәм [шулай ук башка пәйгамбәрләргә иңдерелгән] сүзләренә ышанган өмми Нәби булган Расүленә дә иман китерегез. Аңа иярегез, – бәлки, [хакка һәм хакыйкатькә] һидаять таба алырсыз»;**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:158

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ اللَّهَ فَاتَّبِعُونِي يُحْبِبْكُمُ اللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ وَاللَّهُ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿٣١﴾

**«[Расүлем!] Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк. Аллаһы – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһедән тапшырылган бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәне риваять ителә: «Минем сүзләремне ишеткән, хәтерендә калдырган, аңлаган һәм ишеткәннәрен тапшырган кешене Аллаһы Тәгалә шатландырсын.

Кайвакытта гыйлемне тапшыручы үзеннән дә күбрәк белгән кешегә гыйлемне тапшыра» .

Имам Тирмизи, Имам Әбү Давыд түбәндәге хәдисне китерәләр: «Бездән нәрсәнедер ишеткән һәм ишеткәннәрен нәкъ ишетелгәнчә башкаларга тапшырган кешене Аллаһы шатландырсын, чөнки тапшыручы ишетелгән нәрсәне ишеттерүчегә караганда да яхшырак (турыдан-туры) үзләштерергә мөмкин».

Күренекле галим Әл-Касталәни болай дип әйткән: «Хәдиснең мәгънәсе: хәдис гыйлемен яктыртырга тырышулары һәм сөннәтне яңартулары сәбәпле Аллаһы Тәгалә хәдис тапшыручыларны аеруча шатландырган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе үк догасында хәдис тапшыручыга хәерлесен сораган». Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән тапшырылган бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәне риваять ителә: «Аллаһым, минем хәлифәләремә шәфкатьле бул». Сәхабәләр: «Йә Аллаһының Расүле, синең хәлифәләрең кемнәр соң алар?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип җавап биргән: «Минем хәдисләремне тапшыручылар һәм алар аша кешеләрне өйрәтүчеләр» .

Габдулла бине Гамер радыяллаһу ганһедән тапшырылган бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәне риваять ителә: «Гыйлем өч төрле була: ачык аять, үтәлә торган сөннәт һәм гадел канун. Калганнары – артык» .

## Хәдисләрне бер китапка туплау

Иң беренчеләрдән хәдисләрне җыеп туплаучы Мөхәммәд бине Мөслим бине Гобәйдулла бине Габдулла бине Шиһаб Әз-Зөһри булган. Ул Хиҗаз һәм Шам җирләрендә билгеле булган күренекле галим. 670 елда (һиҗри белән 50 нче елда) Мәдинәдә туган. 742 елда (һиҗри белән 124 нче елда) вафат булган.

Ибне Шиһаб Әз-Зөһри бишенче тугры хәлифә Гомәр бине Габделгазиз әмере буенча хәдисләрне бергә туплаган.

Хәдис белүчеләрнең аз санда булуларын һәм үзләреннән соң андый дәвамчыларны калдыра алмаганнарын күреп, Гомәр бине Габделгазиз галимнәргә һәм төрле илләрдәге үз ярдәмчеләренә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйи вә сәлләмнең хәдисләрен язарга дигән әмер биргән.

Гомәр бине Габделгазиз Әбү Бәкер бине Хәземгә болай дип язган: «Пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә кара һәм язып ал. Дөреслектә, мин галимнәр белән бергә дини дәресләр дә бетәр дип куркам. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләреннән тыш бернәрсәне дә кабул итмәгез. Алган белемнәрегезне таратыгыз һәм бергәләп җыелып, үзегез белмәгән нәрсәләрне өйрәнегез. Хакыйкатьтә, гыйлем яшерен булганчыга кадәр юкка чыкмас».

Әбү Ногайм үзенең «Тарих әл-Исбәхан» дип аталган китабында түбәндәге сүзләрне китерә: «Гомәр бине Габделгазиз төрле өлкәдәге галимнәргә: «Аллаһы Рәсүленең хәдисләрен җентекләп тикшерегез һәм аларны җыегыз», – дип язган».

Шуннан соң галимнәрнең яңа дәвере килә. Аларның һәрберсе сәхабәләрнең сүзләрен һәм табигыйннәрнең фәтваларын үз эченә алган китаплар туплаганнар.

Имам Мәлик рахимәһуллаһи Мәдинәдә «Әл-Мүвәттә» дип аталган хәдисләр җыентыгын төзи һәм бу җыентыкта Хиҗаз халкы таянган хәдисләрне аерып күрсәтә. Имам Әш-Шәфигый: «Ышанычлылыгы ягыннан Коръәннән соң Имам Мәликнең китабыннан кала бер ышанычлы китап та юк», – дип әйткән.

Әбү Мөхәммәд Габделмәлик бине Габделгазиз бине Җөрәйҗ Мәккәдә хәдисләр җыентыгы төзегән.

Әбү Гамер Габдрахман Әл-Әүзагый – Шамда, Әбү Габдулла Суфьян бине Сәгыйд Әс-Сәүри – Куфәдә, Әбү Сәләмә Хәммад бине Сәләмә бине Динар – Басрада хәдис җыентыклары төзегәннәр.

Алардан соң галимнәрнең яңа дәвере килгән. Алар исә үзләре теләгәнчә хәдисләрне таратканнар. Бу галимнәрнең кайберләре бары тик Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрен генә китерергә теләгәннәр.

Гобәйдулла бине Муса Әл-Габси Әл-Куфи, Мөсаддад бине Мөсәрхәд Әл-Басри, Әсад бине Муса Әл-Өмәви, Ногайм бине Хәммад Әл-Хузагыйлар мөснәд төзегәннәр.

Күп имамнар, шул исәптән, Имам Әхмәд бине Хәнбәл, Исхак бине Раһәвиһ, Госман бине Әбү Шәйбә шулай ук үзләренең мөснәдләрен төзегәннәр.

Шуннан соң Имам Бохари килгән. Бу китапларны күреп, үзеннән соң килүчеләргә алардагы хәдисләрне тапшырган. Ләкин бу җыентыкларда дөрес, ягъни ышанычлы (сахих), яхшы (хәсән) һәм зәгыйфь хәдисләр дә булганлыктан, Имам Бохар бары тик дөрес хәдисләрне генә җыярга карар кылган.

Имам Бохари иң беренчеләрдән булып бары тик дөрес хәдисләрдән торган җыентык төзегән. Аннан соң бу эшне Имам Мөслим дәвам иттергән.

## Хәдисләрнең терминнары турындагы фән (гыйлем әл-хәдис би әд-дирайә)

Хәдисләрнең терминнары турындагы фән хәдисләрне тапшыру кагыйдәләрен, шартларын һәм тапшырылу төрләрен, хәдис тапшыручының халәтен, аңа билгеләнгән шартларны, тапшырыла торган хәбәрләрнең төрләрен һәм аның белән бәйле булганнарны өйрәнә.

«Хәдисләрне тапшыру» гыйбарәсенең асылы: Сөннәттән алынган хәбәрләрне тапшыру, хәбәр итү, белдерү, хикәяләү һ.б. шәкелдә хәбәрләр һәм аларны тапшыручылар арасында элемтә урнаштыру.

Хәбәрләрне тапшыру шартлары: хәбәр түбәндәге юл белән тапшырылырга тиеш: ишетү, хикәяләү, рөхсәт итү.

Тапшырылу төрләре: тоташтан һәм өзек-өзек.

Хәдисләрне классификацияләү төрләре: материаллары тематик сәхифәләргә бүленгән җыентыклар күз алдында тотыла: җәвәмигъ, сөнән, мәсәнид, мәгаҗим, әҗзагъ һ.б.

«Җәвәмигъ»: (берлек санда «җәвәмигъ» – берләштерүче). Китап төзүче материалларны төрле темаларга, шул исәптән, дини кагыйдәләргә, гыйбадәт төрләренә, кешеләр арасындагы мөгамәләт һәм Кыямәт көненә бәйле хәбәрләргә багышланган бүлекләргә аера. Мисалга Имам Бохариның «Әл-Җәмигъ Әс-Сахих» китабын әйтергә була.

«Сөнән» – фикһ бүлекләренә (тәһарәт, намаз, зәкят, ураза һ.б.) бәйле тупланган хәдисләр җыентыгы. Мисалга Имам Әбү Давыдның «Сөнән» җыентыгын әйтергә була.

«Мәсәнид» (берлек санда «мөснәд»). Сәхабәләрнең (исемнәре алфавит тәртибендә бирелеп яки Ислам динен кабул итүләренә яисә күркәм нәселдән булуларына бәйле рәвештә) әйтелгән сүзләреннән җыелган хәдисләр җыентыгы. Мисалга Имам Әхмәд бине Хәнбәлнең «Мөснәд» җыентыгын атарга була.

«Мәгаҗим» (берлек санда «мөгъҗәм» – сүзлек). Бу төр китапларда төзүче нигездә хәдисләрне шәехләре исемнәрен алфавит тәртибендә куеп урнаштыра. Мисал итеп Имам Табәранинең «Әл-мәгаҗим әс-сәләс» җыентыгын әйтергә була.

«Әл-әҗзагъ» (берлек сандагы «җөз» сүзеннән). «Җөз» (өлеш) сүзе белән хәдис тапшыручыларның берсе тарафыннан тапшырылган (бу хәдис тапшыручы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең

сәхабәләреннән яки аңа иярүчеләрдән булу-булмавына бәйле түгел) хәдисләр тупланган, күләме ягыннан зур булмаган китапны атыйлар. Мисал итеп Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең, Мәлик бине Әнәс радыяллаһу ганһенең «җөз»е. Шулай ук бер генә темага багышланган хәдисләрдән торган китапны да «җөз» дип атыйлар.

*Габдулла Сираҗетдин Әл-Хөсәйнинең «Хәдис гыйлеменә кереш. «Әл-Мәнзүмәт Әл-Бәйкуния»гә комментарияләр» китабыннан*

# Мөслимә

# Ислам тарихында эз калдырган мөслимәләр

Берәү Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән үз туганнары арасында кайсының аңа күбрәк хакы барлыгы хакында сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әниең», – дип җавап биргән. «Ә тагын кем?» – дип сорагач та, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул ук җавабын кабатлаган. Теге кеше янә үз соравын кабатлап сораган. Аллаһының Расүле шулай ук җавап кайтарган. «Алай да, аннан соң кем?» – дип сораган бу кеше. Дүртенче тапкыр сорагач кына Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ә менә хәзер синең әтиең», – дип җавап кайтарган.

Ислам диненең үсешендә, милләтнең әхлакый сыйфатларын камилләштерүдә, балаларны дини рухта тәрбияләүдә хатын-кызларның керткән өлешен танымаган берәү дә табылмас, мөгаен. Мөслимәләр һәрвакыт үзләренең ныклы иманнары, зирәклекләре, әдәплелекләре белән башкалардан бик нык аерылып торганнар.

Исламга кадәр булган дәвердә гарәп илендә хатын-кызлар теләсә нинди хокуклардан мәхрүм булганнар. Төп вазифалары балалар тудыру, ирен һәм өй эшләрен караудан гыйбарәт булган. Аларның бернинди сүз, сайлау иреге дә булмаган. Бары тик Ислам дине килгәч кенә хатын-кызларга күпмедер дәрәҗәдә хокуклар бирелеп, алар күркәм нәсел дәвамчылары тәрбияләүгә генә түгел, ә өммәтебезнең үсешенә, Ислам динен дөнья буйлап таратуга үзләренең барлык көч-куәтләрен түктеләр.

Мисалга Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллау галәйһи вә сәлләмнең хатыны – **Хәдичә бинте Хөвәйлид радыяллаһу ганһә**не генә алыйк. Ул сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән яшь ягыннан шактый олы булып, үзенең зирәк акылы, эшкуарлык өлкәсендә шактый осталыгы белән аерылып торган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә

сәлләмгә, бигрәк тә пәйгамбәрлегенең беренче елларында бик зур ярдәм иткән һәм нык терәк булган. Ислам диненең хатын-кызлар арасында таралуына зур этәргеч ясаган, шул рәвешле, беренче мөслимә дәрәҗәсенә лаек булган, ягъни хатын-кызлардан иң беренче булып иман китергән.

Имам Мөслимнең сахих хәдисләр җыентыгында түбәндәге хәдис китерелгән: пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бөек һәм Кодрәтле Аллаһы Тәгалә бу дөньяда миңа аннан да яхшырак берәүне дә бирмәде. Башкалар миннән йөз чөергәндә, кире какканда, ул мине кабул итте; кешеләр миннән шикләнгәндә, ул миңа ихластан ышанды; кешеләр мине бөтен барлыгымнан мәхрүм иткәндә, ул барлык байлыгы, малыннан минем белән бүлеште; Аллаһы Тәгалә миңа бары тик аннан гына балалар бүләк итте».

Ислам дине таралуда үз эзен калдырган хатын-кызлар арасында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Хәдичә радыяллаһу ганһәдән туган кызы **Фатыйма Зә-Зәһра** да бар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселе нәкъ менә аңа бәйле рәвештә сакланып калган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тагын бер хатыны – **Гайшә бинте Әбү Бәкер радыяллаһу ганһә** турында да искә алу кирәк. Яшь булуына да карамастан, Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребезнең сәхабәләре арасында зур абруй казанган. Шактый катлаулы дини һәм сәяси мәсьәләләрне тикшерүдә һәм карарлар чыгаруда катнашкан.

Гайшә радыяллаһу ганһә гыйлем алуга да зур игътибар биргән, Пәйгамбәребезнең күп хәдисләрен һәм гамәлләрен истә калдырган. Аның гыйлеме турында сәхабәләр түбәндәге сүзләрне әйткәннәр: «Гайшәнең гыйлемен җыеп, аны башка хатын-кызлар гыйлеме белән чагыштырсаң, Гайшәнең гыйлеме өстенрәк булыр иде. Безгә нинди дә булса хәдис аңлашылмаса, без аның турында Гайшәдән сорый идек һәм һәрвакытта

да җавап таба идек». Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән 2210 хәдис тапшырган.

**Зәйнәб бинте Гали** – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең оныгы, Фатыйма һәм Гали бине Әбү Талибның кызы. Зәйнәб бинте Гали Әһле Әл-Бәйтнең (Пәйгамбәребез гаиләсенең) иң тәкъва һәм күренекле кешеләре арасында булып, Кәрбаладагы (Гыйрактагы шәһәр) сугышта төп рольне уйнаган. Бу сугышта өммәвиләр тарафыннан аның бертуганы Әл-Хөсәен бине Гали һәм 70 абзасы һәм туганнан туган энеләре үтерелә. Бу вакыйгалардан соң күп еллар дәвамында Зәйнәб бинте Гали Әһле Бәйтнең җитәкчесе булып торган, туганы Хөсәеннең эшен дәвам иттергән. Куфа шәһәрендә туганнан туган энесе, Хөсәеннең улы – Гали бине Әл-Хөсәенне үлемнән саклап калган, судта нотык тоткан. Бу нотыктан соң хәлифә Кәрбаладагы тоткыннарны азат иткән. Зәйнәб бинте Гали үзенең көчлелеге, сабырлыгы һәм зирәклеге белән башкалардан аерылып торган.

## Нәфис һәм тәвәккәл гүзәл затлар

Ислам тарихында үз эзләрен калдырган мөслимәләр белән беррәттән, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышын саклап калырга ярдәм иткән нәфис гүзәл затлар, ләкин шул ук вакытта тәвәккәл булган мөслимәләрнең исемнәрен искә алу да урынлы булыр.

«Бервакыт сәфәрдә чагында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөяләргә утырган берничә хатын-кызны күргән. Дөяләрне йөртүче шулчаклы кызу куалаган, хатын-кызларга бу шактый уңайсызлыклар тудыруы хакында да уйламаган. Шулвакытта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Син бәллүр тартмачыклар алып барасың, берүк алар белән саграк бул!» – дип әйткән.

Беренче мөслимәләр, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең замандашлары, «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр расүлуллаһ» («Аллаһыдан башка илаһ юк, Мөхәммәд – Аллаһының Илчесе») кәлимәсенең мәгънәсен башкаларга караганда да ныграк аңлаганнар.

Мәккә мөшрикләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үз урынында йоклаган вакытында үтерергә ниятләгәндә, нәкъ менә **Нәфит Гали Гыйльмийә** исемле мөслимә Пәйгамбәребезнең гомерен саклап калган. Ул дошманнарның үзара сүз куешканнары хакында белеп, бу турыда Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәбәр биргән. Дошманнары аны йоклаган дип белсеннәр өчен, Аллаһының Расүле үз йокы бүлмәсенә Гали бине Әбү Талибны калдырып, төн караңгылыгында Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән Мәккәдән чыгып киткән. Алар юлга җәяүләп чыкканнар. Дошманнарны юлдан яздыру өчен, Мәдинә ягына – төньякка түгел, ә Йәмәнгә таба киткәннәр. Аннан соң Сәвер дип аталган мәгарәгә кереп яшеренгәннәр. Һәр төн саен Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең кызы **Әсма радыяллаһу ганһә** аларга ризыклар китергән, аларны эзләүчеләр хакында яңа хәбәрләрне ирештереп торган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне һәм әтисен саклау максатыннан бу яшь мөслимә бервакыт төнлә биек тауга күтәрелгән. Аны тирә-яктагы дошманнар һәм тынгысыз бу җирлек тә куркытмаган. Бервакыт корәешлеләр юлына чыгып, аны әйләндереп алганнар, сорау үткәргәннәр. Ләкин ул куркып калмаган, сер бирмәгән. Араларыннан берәү йөзенә сугып, колакларындагы алкаларын тарта башлаган. Мондый мәсхәрәләргә дә түзгән ул, бернәрсә дә сөйләмәгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән әтисе Мәдинәгә юл тотканчыга кадәр Әсма аларга гел ризык китереп торган.

**Әсма бинте Өмәйс** – Җәгъфар бине Әбү Талибның хатыны, ире белән беррәттән Ислам динен кабул иткән. Үз диннәренә тугрылыкны саклау максатыннан үз яшәгән җирләрен калдырып, ире белән Хәбәшәгә һиҗрәт кылган.

**Сөмәйә өмми Гаммәр бине Ясир** – шулай ук Ислам дине хакына үз гомерен кызганмаган. Аның гаиләсен камчы белән җәзалаганнар, үлем якынлашуын сизсен өчен башларын суга тыкканнар. Ләкин алар диннәреннән баш тартмаганнар. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларның хәлләрен белеп болай дип әйткән: «Түзегез, Ясир гаиләсе, сезгә оҗмах вәгъдә ителгән».

**Нәсибә бинте Кәгъб Әл-Мәсинил өмми Гомәр** – сәхабә хатын-кызларның берсе. Бер бәрелеш вакытында ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп кушылган. Шулай бервакыт, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә куркыныч янаган вакытта, Аллаһының Илчесен саклау максатыннан, ул бер адым алгарак чыккан. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кайсы якка гына борылса да, гел аны яклап алдына Нәсибә чыга торган булган.

Көннәрнең берендә Нәсибәнең улы Гомәр яраланган. Әнисе улының яралы җилкәсен бәйләгән дә: «Тор, улым, туктап калма, ахыргача көрәш!» – дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның бу батырлыгына һәм көчлелегенә сокланып: «Йә, тагын кайсыгыз Гомәрнең әнисе кылганнарны булдыра ала?» – дип сораган. Шул көнне Нәсибә ялалардан үзе дә хәлсезләнгән һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән үзе һәм улы өчен дога кылуын үтенгән. Аллаһының Расүле аның үтенечен кабул итеп, Аллаһы Тәгаләгә дога кылган. Нәсибә бик шат булган, ул бернәрсәдән дә курыкмаган.

Күргәнебезчә, Аллаһыга чынлап ышанган бу кешеләрне – гүзәл хатын-кызларны бернәрсә дә куркытмаган. Аларга тән җәзалары да, рухи яктан кысрыклаулар да тәэсир итмәгән. Алар Аллаһы хакына түзгәннәр. Без дә алардан үрнәк алып, динебезгә һәм телебезгә тугры булсак иде.

*«Дин вә Мәгыйшәт» газетасының ноябрь санынннан*

# Ана – бөек исем

## Исламда әни кешегә булган мөнәсәбәт – ул үзе бер дәреслек, яшәү күрсәтмәсе

Ислам динендә әни кешегә зур игътибар бирелә. Изге Китабыбызда да, Расүлебез сөннәтендә дә ата-аналарга карата мәрхәмәтле, игътибарлы булуның мөһимлеге ассызыкланган. Әгәр кем дә булса, динебезне буярга, аның хөкемнәренә яла ягарга, дин катгый тыюлардан гына тора, дип әйтергә теләсә, әлегә мөһим мәсьәләне өйрәнсен, бу турыда күбрәк белергә омтылсын иде.

Ислам дине – тынычлык, игелек, мәрхәмәтлелек дине. Анда дорфалыкка, каты бәгырьлелеккә, әхлаксызлыкка урын юк. Әни кешене шул дәрәҗәдә хөрмәтләргә, бөекләргә кирәклеген без иң беренче чиратта Коръәннән һәм хәдисләрдән укып беләбез. «Җәннәт – әниләрнең аяк астында», дип әйтелгән гыйбарә Расүлебезнең хәдисе икәнен белеп бетермәүчеләр дә бардыр. Аны кайберәүләр бары тик мәкаль яки тормыштан алынган сүзләр дип кенә кабул итәр.

Әмма Исламда әни кешегә булган мөнәсәбәт – ул үзе бер дәреслек, яшәү күрсәтмәсе. Боларны кечкенәдән аңлап, үзенә гомер бүләк иткән кешесен хөрмәтләп, олылап, әйткән изге нәсыйхәтләрен тыңлап үскән бала ялгыш юлга кереп китмәс, чөнки ана кеше беркайчан да баласына начарлык теләми, аны, балам тәүфикъсыз булсын, дип тәрбияләми. Үзе дә Ислам нуры белән яшәгән ана баласына туры юлны, һидаятьне күрсәтә алыр. Ә бала боларны аңлап үскән очракта итагатьле, инсафлы шәхес булып җитешер.

Әйе, бала әнисе алдында күпме генә тырышса да, аңа булган рәхмәтен әйтеп бетерә алмас. Берьюлы Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер сәхабә килеп, йә Аллаһының Расүле, минем анам картайды, өлешчә зиһенен югалтты. Мин аны үз кулларым белән ашатам, аңа су

бирәм, аңа тәһарәт алырга ярдәм итәм, әниемне аркамда күтәреп йөрим. Мин аның алдында булган бурычымны үтәп бетердемме, дип сораган. Моңа җавап итеп Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

– Юк, син йөздән бер өлешен дә үтәмәдең. Ул син көчсез булганда сине карады, син үлмәсен өчен сиңа хезмәт итте. Син исә аның үлемен көтеп аңа хезмәт итәсең. Син берничек тә аңа бурычыңны түләп бетерә алмассың, әмма син игелекле гамәл кыласың, моны дәвам иттер, – дип әйткән.

## Бала күңеле – ак кәгазь

Әмма баланың әнисе алдында бурычы булу белән беррәттән, безнең – әниләрнең дә сабыйларыбыз алдында бурычларыбыз булганлыгын онытмасак иде. Ыгы-зыгы белән тулы, вакыт җитмәгән, бер көнебез бер сәгать кебек үткән мәшәкатьле дөньяда бу аеруча да мөһим.

Бала күңеле ак кәгазь кебек. Ул саф, пакь һәм гөнаһсыз җан иясе. Үсеп буйга җиткәч балаларыбызның нинди шәхес булып җитешүләре, ничек фикерләүләре безнең кечкенә вакытта аларга биргән тәрбиябездән, әйткән үгет-нәсыйхәтләребездән тора. Бүген күпләребез бала тәрбияләүне ашату-эчертү, киендерү, дөньяви гыйлем бирү, төрле түгәрәкләргә йөртүгә генә кайтарып калдырганда, сабыйларыбызны югары әхлаклы, көчле ихтыярлы итеп тәрбияләү мәсьәләсе икенче планга күчмиме икән?!

Җәлил хәзрәт үзенең вәгазьләрендә, китапларында Локман Хәкимнең әлеге гыйбарәсен китерүе дә юкка гына түгел. Ул: «Балага кечкенәдән Аллаһы Тәгалә турында сөйләмәсәң, картлыгыңны Аллаһы Тәгаләгә балаң турында сөйләп (зарланып) үткәрерсең», – дип әйтә.

Әйе, берәү дә баланы алдына утыртып, кил мин сине тәрбиялим әле, дип әйтми. Бу мөмкин дә түгелдер. Тик шуны онытмасак иде: балаларыбызга тәрбия бирү үзебездән башлана. Балалар безнең көзгеләребез кебек. Алар безне тасвирлый. Без үз-үзебезнең тотышыбыз, бу дөньяга,



әйләнә-тирәбезгә, ата-аналарыбызга, туганнарыбызга, якыннарыбызга мөнәсәбәтебез белән балаларыбызга бу тормышны ничек алып барырга кирәк икәнлеген күрсәтәбез. Оясында ни күрсә, очканда шул булыр, дигән кебек, балаларыбызны олы тормыш юлына әзерлибез. Ә алар, үз чиратларында, бу тәртипне үзләре төзегән ояларында кулланачак.

## Харамнан тыелу мөһим

Без күп әйберләрне белеп тә бетермәскә мөмкин. Әмма шулай да иң гади һәм мөһим булган тәртипләр бар. Ул – балаларыбызга хәләл ризыклар гына ашату. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Балаларыгызның тәнен харам ризыктан җыйсагыз, көче ныгыгач, үзегезгә каршы борылыр», – дигән. Төрле зыянлы, хәләл булмаган кушылмалардан торган тәм-томнар балаларның әле ныгымаган организмына зарар сала. Кызганычка, бу аларның тәртипләре бозылуга, игътибарсыз, таркау булып үсүләренә дә сәбәп булырга мөмкин. Кызганычка, күпләребез моңа зур әһәмият бирми. Хәләл ашауны, харамнан тыюлуны дингә генә кайтарып калдыра. Әмма харамнан ерагаю, иң беренче чиратта, безнең үзебезнең бәхетебез, иминлегебез өчен мөһим.

Ана бөек исем. Аллаһы Тәгалә әни кешене баласы, гаиләсе алдында шундый зур вазифалары булганга күрә бөекләгән дә инде. Безнең өчен тырышлык куйган әниләребезне хөрмәтләп, олылап яшәп, балаларыбызны да безне олылый алырлык итеп тәрбияли алсак иде.

*Айсылу Юлдашева*

# Нәсыйхәт

# Олы гөнаһлар

## Ялган

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

فَإِذَا اسْتَوَيْتَ أَنتَ وَمَن مَّعَكَ عَلَى الْفُلْكِ فَقُلِ الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي نَجَّانَا
مِنَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ ﴿٢٨﴾

**«Яныңдагылар белән бергә көймәгә урнашкач, [Миңа шөкер итеп] әйтегез: «Барча мактаулар – Аллаһыга, Ул безне залимнәр кавеменнән коткарды»;**

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:28

قُتِلَ الْخَرَّاصُونَ ﴿١٠﴾

**«Ялган фаразларда булучылар һәлак булсын!»;**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:10

فَمَنْ حَاجَّكَ فِيهِ مِن بَعْدِ مَا جَاءَكَ مِنَ الْعِلْمِ فَقُلْ تَعَالَوْا نَدْعُ أَبْنَاءَنَا
وَأَبْنَاءَكُمْ وَنِسَاءَنَا وَنِسَاءَكُمْ وَأَنفُسَنَا وَأَنفُسَكُمْ ثُمَّ نَبْتَهِلْ فَنَجْعَل لَّعْنَتَ
اللَّهِ عَلَى الْكَاذِبِينَ ﴿٦١﴾

**«[Расүлем! Гайсәнең [галәйһиссәлам] Аллаһының улы булмыйча, Аның колы һәм расүле булганы турында] Сиңа [бу кадәр] гыйлем килгәннән соң, [насаралардан] кем дә кем аның хакында синең белән тартышса: «Килегез, [иң якын һәм кадерле булган кешеләребез] улларыбызны һәм улларыгызны, хатыннарыбызны һәм хатыннарыгызны, үзебезне һәм үзегезне ча-**

**кырыйк та, Аллаһының ләгънәте ялганчылар өстенә төшсен, дип дога кылыйк!» – дип әйт».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:61

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, ялган гөнаһларга, ә гөнаһлар утка илтә. Ялган сөйләвен дәвам иттерүче кеше, Аллаһы каршында ялганчы дип язылачак»[1].

«Икейөзле кешенең өч билгесе бар: ул сөйләгәндә алдый, биргән вәгъдәсендә тормый, ышанып тапшырганны саклый белми»[2].

Икенче бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Хакыйкый икейөзле кеше шулдыр, кем әлеге дүрт сыйфатка ия. Ә шуларның берсен генә булса да үзендә йөрткән кеше, моннан котылганчыга кадәр, икейөзлелекнең өлешен үзендә йөртер. Икейөзле:

1. Аңа ышанып тапшырганга хыянәт итә.
2. Сөйләгәндә ялганлый.
3. Биргән вәгъдәсендә тормый.
4. Берәрсе белән дошманлашса, канунга каршы килгәнчә эш итә[3].

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый сүзләр әйткән:

«Кыямәт көнендә төшендә күргән кебек итеп сөйләүче кешегә ике арпа бөртеген төен итеп бәйләргә тәкъдим итәләр. Әмма ул беркайчан да моны эшли алмас»[4].

«Яла ягуның һәм ялганның иң югары дәрәҗәсе – ул үзең күрмәгәннәрне сөйләү»[5].

---

1 Имам Әл-Бохари, Китаб Әл-Әдәп, 6094; Имам Әл-Мөслим, Китап Әл-Бирр, 2606.

2 Имам Әл-Бохари, Китаб Әл-Иман ,59; Имам Әт-Тирмизи, Китаб Әл-Иман, 2633; Ән-Нәсаи, Китаб Әл-Иман, 8/117.

3 Имам Әл-Бохари, Китаб Әл-Иман, 34; Имам Әл-Мөслим, Китаб Әл-Иман ,57.

4 Имам Әл-Бохари; Китаб Әл-Таһир, 7042.

5 Имам Әл-Бохари; Китаб Әл-Әнбия, 3509.

Сәмура бине Җөндүб Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күләмле әлеге хәдисен тапшыра. Биредә Расүлебез үзенең күргән төшен сөйли:

«Без чалкан яткан кеше янына килдек. Аның янында бер кеше тора иде. Ул кешенең кулында тармаклы ыргак иде. Бу кеше әлеге ыргакны яткан кешенең авызыннан башына кадәр кертте дә, авызның бер өлешен ертып алды. Аннары авызының икенче ягы белән дә шул рәвешчә эшләде. Моның сәбәбе шул иде: чалкан яткан кеше һәркөнне иртән өеннән чыгып, уйдырмалар сөйли торган булган. Хәтта аның сөйләгәннәре күкләргә ирешкән»[1].

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

«Мөселман кешесенең холкында, ялганнан һәм хыянәт итүдән тыш, төрле сыйфатлар булырга мөмкин»[2].

«Хакыйкатьтә, кешеләр төркемендә ялганның бер өлеше бар»[3].

«Гөнаһлы булыр өчен, кешегә һәр ишеткәнен сөйләү җитә»[4].

«Беркайчан да эшләмәгән гамәлләре хакында игълан итүче кеше – икеләтә ялганчы»[5].

«Шик-шөбһәләрдән сакланыгыз. Алар сүзләрнең иң ялганы»[6].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә өч кеше белән сөйләшмәячәк», – дип әйткән. Һәм алар арасында ялганчы хөкемдарны санаган[7].

---

1 Имам Әл-Бохари, Китаб Әл-Тәгъбир, 7047.

2 Имам Әхмәд бине Хәнбәл, 5/252.

3 Имам Әл-Бохари, Әдәб Әл-Мүфрад, 2/334.

4 Имам Әл-Мөслим, Мүкаддимә.

5 Имам Мөслим, Китаб Әл-Либәс, 213.

6 Имам Әл-Бохари, Китаб Ән-Никах, 51143; Имам Әл-Мөслим, Китаб Әл-Бирр Вәсилә, 2563.

7 Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

## Үз-үзеңә кул салу

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَأْكُلُوا أَمْوَالَكُم بَيْنَكُم بِالْبَاطِلِ إِلَّا أَن تَكُونَ تِجَارَةً
عَن تَرَاضٍ مِّنكُمْ ۚ وَلَا تَقْتُلُوا أَنفُسَكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ كَانَ بِكُمْ رَحِيمًا ﴿٢٩﴾
وَمَن يَفْعَلْ ذَٰلِكَ عُدْوَانًا وَظُلْمًا فَسَوْفَ نُصْلِيهِ نَارًا ۚ وَكَانَ ذَٰلِكَ عَلَى
اللَّهِ يَسِيرًا ﴿٣٠﴾ إِن تَجْتَنِبُوا كَبَائِرَ مَا تُنْهَوْنَ عَنْهُ نُكَفِّرْ عَنكُمْ سَيِّئَاتِكُمْ
وَنُدْخِلْكُم مُّدْخَلًا كَرِيمًا ﴿٣١﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Үзара килешенгән [һәм динебез тарафыннан рөхсәт ителгән] сәүдә юлы белән булмаса, [шәригать кушмаган риба, отышлы уен һәм талау кебек] бозыклык белән арагызда [бер-берегезнеке булган] малларыгызны ашамагыз. [Үз-үзегезгә кул салып яки җаныгызны куркыныч астына куеп] Үзегезне үзегез үтермәгез. Кем дә кем [ялгышлык яки кыйсас юлы белән түгел, башка берәүгә] дошманлык һәм [үз-үзенә] хаксызлык белән моны [үз-үзенә кул салу һәм башка берәүне үтерү кебек харамнарны] кылса, аны [газабы бик дәһшәтле] Утта яндырачакбыз. Бу Аллаһы өчен бик җиңел. [Аллаһы һәм Аның Расүле тарафыннан] Тыелган [начар] нәрсәләрнең иң авырларыннан саклансагыз, Без дә сездән начар эшләрегезне [һәм кече гөнаһларыгызны] капларбыз һәм сезне [җәннәт дигән] бик шәрәфле бер урынга кертербез».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:29-31

وَالَّذِينَ لَا يَدْعُونَ مَعَ اللَّهِ إِلَٰهًا آخَرَ وَلَا يَقْتُلُونَ النَّفْسَ الَّتِي حَرَّمَ اللَّهُ إِلَّا
بِالْحَقِّ وَلَا يَزْنُونَ ۚ وَمَن يَفْعَلْ ذَٰلِكَ يَلْقَ أَثَامًا ﴿٦٨﴾

**«Янә алар Аллаһы белән беррәттән башка илаһка табынмыйлар [үтергән бер кеше өчен кыйсас, Исламга кергәннән соң диннән чыгу һәм өйләнгән килеш зина кылу кебек] хак белән булмыйча, Аллаһы тыйган җанны үтермиләр, зина да кылмыйлар. Кем дә кем боларны кылса, [гөнаһының] җәзасын алачак».**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:68

Җөндүб бине Габдулла Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен китерә: «Сезгә кадәр яшәгән кешеләр арасыннан берәү яраланган иде. Һәм авыртуга түзә алмыйча пычак алып, кулын кисте. Шуннан соң күп кан югалтканга күрә үлде. Раббыбыз болай дип әйтте: «Минем колым үзенең гомерен өзеп, мине узып китте. Шуңа күрә мин аның өчен җәннәтне харам кылдым»[1].

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Кем үзен тимер белән үтерсә, шул тимерне тотып корсагына кадаган көе җәһәннәм утында булыр. Һәм бу газаплар бик озак дәвам итәр. Агу эчеп үз-үзен үтергән кеше – аны җәһәннәм утында да эчәчәк. Һәм бу газаплар бик озак вакытлар дәвам итәчәк»[2].

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм авыртуга түзә алмыйча кылыч белән үз-үзен үтергән кеше турында:»Ул җәһәннәмдә булучылар арасында», – дип әйткән[3].

Сәбит бине Дәххак болай дип тапшырган: «Мөэминне каргау – аны үтерүгә тиң. Берәү мөэминне көферлектә гаепләсә (кяфер дисә), бу аны

1 Имам Әл-Бохари, Китаб Әл-Әнбия, 3463; Имам Әл-Мөслим, Китаб Әл-Иман, 113.

2 Имам Әл-Бохари, Китаб Әт-Тыйбб, 5788; Имам Әл-Мөслим, Китаб Әл-Иман ,109; Имам Әт-Тирмизи, Китаб Әт-Тыйбб; 2044; Имам Ән-Нәсаи, Китаб Әл-Җәнаиз, 66,67; Имам Әбү Давыд, Китаб Әт-Тыйбб, 3872.

3 Имам Әл-Бохари, Китаб Әл-Җиһад, 3062; Әл-Мөслим, Китаб Әл-Иман ,111.

үтергән кебек була. Аллаһы Тәгалә үз-үзенә кул салган кешегә Кыямәт көнендә җәза бирер»[1].

## Суд карарлары чыгаруда гаделсезлек күрсәтү

وَمَن لَّمْ يَحْكُم بِمَا أَنزَلَ اللَّـهُ فَأُولَـٰئِكَ هُمُ الْكَافِرُونَ ﴿٤٤﴾

**«Кем дә кем Аллаһы иңдергән [кагыйдәләрнең дөреслеген белә торып, аларны чынга алмыйча, алар] белән хөкем итмәсә, алар имансызлар».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:44

إِنَّ الَّذِينَ يَكْتُمُونَ مَا أَنزَلْنَا مِنَ الْبَيِّنَاتِ وَالْهُدَىٰ مِن بَعْدِ مَا بَيَّنَّاهُ لِلنَّاسِ فِي الْكِتَابِ ۙ أُولَـٰئِكَ يَلْعَنُهُمُ اللَّـهُ وَيَلْعَنُهُمُ اللَّاعِنُونَ ﴿١٥٩﴾

**«...Без иңдергән ап-ачык дәлилләрне һәм һидаятьне яшерүчеләрне Аллаһы ләгънәт итә, аларны бөтен ләгънәт итүчеләр дә ләгънәтли».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:159

Талхә бине Гобәйдулла Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләрен риваять итә: «Аллаһыдан бирелгән кануннар буенча идарә итмәгән хөкемдарның намазы кабул ителмәс»[2].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

«Өч казый арасыннан бары берсе генә җәннәткә эләгер, калган икесе – җәһәннәмгә. Җәннәткә хакыйкатьне белеп, аның буенча эш иткән казый керәчәк. Җәһәннәмгә эләгүчеләрнең берсе: хакыйкатьне белеп тә,

1 Имам Әл-Бохари, Китаб Әл-Иман, 6652; Имам Әл-Мөслим, Китаб Әл-Иман, 110; Имам Әт-Тирмизи, Китаб Әл-Иман, 2638, Имам Ән-Нәсаи, Китаб Әл-Иман, 715.

2 Хәким, Мөстәдрак, Китаб Әл-Әхкәм, 4/89.

аның буенча гамәл кылмаучы, ә икенчесе: хакыйкатьне белмичә, үзенең гыйлемсезлеге белән карарлар кабул итүче»[1].

Автор фикеренчә, бу кисәтүләр Аллаһы Тәгаләнең һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләренә таянмыйча карарлар чыгарган казыйларга кагыла.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Өч казый арасыннан берсе генә җәннәткә, калган икесе җәһәннәмгә керә», – дип әйткәч, сәхабәләр: «Йә Аллаһының Расүле! Белмәүченең гаебе нидә?» – дип сораганнар. Бу сүзләргә җавап итеп Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тиешле гыйлеме булмаган көе ул казый булырга тиеш түгел»[2], – дип әйткән.

Тагын да дөрес, ышанычлы булган хәдис бар. Мәгъкал бине Синән Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләрен риваять итә: «Теләсә кайсы сорау буенча гаделсез карар чыгарган өммәтем кешесен Аллаһы Тәгалә җәһәннәмгә атачак»[3].

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе түбәндәге хәдисне тапшырган: «Казый булу – пычаксыз суелуга тиң»[4].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сүзләренчә, дәлилләр табуга бар тырышлыгын куйган, үз фикеренә түгел, ә тапкан дәлилләргә таянган казый, һичшиксез, әҗерле булачак:

«Әгәр казый карар чыгару өчен бар көчен һәм тырышлыгын куйса һәм бу карарлар дөрес булса, ул ике әҗерле булачак. Әгәр көч куюына һәм тырышлыгына карамастан, карары дөрес булмаса – бер әҗергә ия булачак»[5].

---

1 Хәким, Мөстәдрак, Китаб Әл-Әхкәм, 4/90.

2 Хәким, Мөстәдрак, Китаб Әл-Әхкәм, 4/90; Әбү Давыд, Китаб Әл-Әзкыйә, 3573.

3 Хәким, Мөстәдрак, Китаб Әл-Әхкәм, 4/90-91.

4 Әбү Давыд, Китаб Әл-Әзкыйә, 3571; Әт-Тирмизи, Китаб Әл-Әхкәм, 1325.

5 Әл-Бохари, Китаб Әл-Игътисам, 7354; Әл-Мөслим, Китаб Әл-Әзкыйә, 1716.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әҗерле булуны тырышлык кую белән бәйләгән. Әгәр казый тырышлык куймыйча, кемнеңдер фикеренә генә таянып карар чыгарса, югарыда әйтелгәннәр аңа кагылмаячак.

Казыйның ачулы халәттә карар чыгаруы тыелган гамәл, бигрәк тә ачуы дошманга карата булса.

Казыйның гыйлеме җитмәү, начар холыклы булуы, тәкъвалыгы булмавы – аның хәлләрен катлауландыра. Мондый очракта ул бу вазифадан китәргә һәм үзен Уттан сакларга тиеш.

*Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан*

# Әдәби сәхифә

# Кайнар диңгез юлы

Тәрәзәдән кергән әрсез салкын җил улаган тавышка Таһир сискәнеп уянды. Туңудан калтыранган тәне җылы эзләп, өстенә юрганын ике катлап япты. Бер кешелек тимер караватка җәелгән юка матрас аша идәннән күтәрелгән салкын җил аның җанына-бәгыренә үтә. Ул юрганына уралган килеш, урыныннан торды. Тәрәзә пәрдәсен күтәреп, тышка карады. «Йә Раббым!» – диде ул. Май аенда кап-караңгы төнне яктыртып ишелеп-ишелеп кар ява. Тәне калтыранып куйды, башында кайнаган уйлар өермәсе аша күзен йомды... Ул менә икенче атнасын тулай торакның ун квадрат метрлы бүлмәсендә үткәрә. Кичә дә көне буе бер үзе булды. Нигә аны җитәкчеләр үз яннарына чакырып сөйләшмиләр? Каршы алдылар, шушында китереп урнаштырдылар да, үзләре сүзсез генә китеп югалдылар. Оныттылармы әллә Таһирне? Югыйсә, Татарстан Диния Нәзарәте тарафыннан Сургут җирендә динне күтәрергә дип җибәрелгән юлламасын шатланып кабул иткән кебек тоелдылар ич. Бүген дә чакыручы булмаса? Өстендә дә юка кием генә. Себернең салкын җиле аның костюмы аша үтеп, тәнен өшетеп туңдыра. Әгәр ул мондагы салкынга түзә алмаса?.. Таһирның үзәген өзеп сагыну хисе биләп алды, кайтасы килә башлады... Куллары белән үз-үзен кочаклады. Күз алдына нәфис җан иясе, беренче саф мәхәббәте, хәләл хатыны Рәйсәсе килеп басты. Аның илаһи матурлык белән карый торган күзләренә төбәлгәндәй булды, йомшак тавышын ишетте. Ул аңа: «Таһирем, ник Зөһрәңне ялгыз калдырып киттең, мин синсез ничек яшим? Кайт, бәгърем, нинди зур Казаныбызда синең кебек тәкъва имамнарга урын табылыр. Кайт...», – дип эндәшә, чакыра кебек. Әниләренең муенына сарылган кызы Әлфинурының аңа яшьле күзләре төбәлде. Ул да үпкәле кебек. Шушы ике илаһи зат иясен унике яшьлек улы Камил тынычландыра сыман тоела. Таһирне тимер юл вокзалына озатырга килгәч: «Җәйге каникулга чыккан көнне үк, Себергә килеп җитәрбез,

әти», – дип, саубуллашкан иде. Шулчакта барысының да күзе дымланды. Ә Камил тәкъвалыгын күрсәтеп, күз яшен эчкә йотты. Улының, әле яшүсмер малай гына булса да, шул минутта әтисенә карата теләктәшлек күрсәтүе, муенына сарылып еларга керешмәве, аны берьяктан куандырды. Тик, шушы минутта, ул балаларына да кирәк. Бу салкын бүлмәдә тагын күпме ятарга тиеш? Әгәр дә иртәгә дә бернинди үзгәреш булмаса, кайтып китәчәк ул. Монда имам кирәк булса, аны шул көнне үк чакыртып алып, уй-фикерләре белән уртаклашырга тиешләр иде…

Таһир уй-хыялында кулына кечкенә чемоданын тотып, туган ягына кайтып китәргә җыенды. Шулчак: әтисе Татарстанның баш казые, Габделхак хәзрәт Саматовның: «Тукта, улым! Үзеңнең Аллаһ юлында хезмәт итәргә киткәнеңне исеңнән чыгарма! Кирегә юл юк! Син – Себер җиренә Аллаһның илчесе итеп җибәрелдең. Безнең милләттәшләребез дөньяның бар кыйтгасына таралган. Шулар арасыннан Аллаһның сөекле бәндәләрен эзләп тап. Ул кешеләрдән сиңа җылы җил исәр, Аллаһ сиңа аларны йогышлы сүзләре, җылы мөнәсәбәтләре аша белгертер…». Таһир сискәнеп китте. Нәрсә бу?! Әтисе аның янәшәсендә генә кебек. Тавышы да каракаршы басып сөйләшкән кебек.

Таһир уйларын тәртипкә салды. Ул, шушы мизгелдә әтисенең дә аны уйлап, аның өчен борчылып, йокысыз төн үткәргәнен йөрәге, акылы белән тойды. Караватчитенә барып ятуга, аны уйлар өермәсе бөтереп алды…

…Алар гаиләдә дүрт бала үсте. Бик гади, уртача гына тормышта яшәделәр. Унбер ел әтисенең бертуган абыйсы Кәнзелголум гаиләсе белән бер баракта кысан гына бүлмәләрдә яшәгән вакытларын искә төшерде. Ике ояга ун бала шунда әүмәкләшеп үстеләр. Әти-әниләре көне буе эштә. Абыйсы белән әнисе бер заводта эшләделәр. Күз алдына тыйнаклыгы, әдәп-әхлакның үрнәге булган әнисе килеп басты. Ул кырык ел хәтта Кәнзелголум абыйдан да тел яшерде. Әйтәсе килгән сүзен дә аңа

Шакирә җиңги аша җиткерде. Унбиш кешелек гаилә абыйлары сүзеннән чыкмады. Акча да аның кулында булды. Татар гаиләсендә борынгыдан, акча бер кеше кулында гына булырга тиеш дигән тәртип сакланган. Ике оя бала әти-әниләре үрнәгендә кече яшьтән намаз укыды. Бер Аллаһны гына танырга, Аңа гына гыйбадәт кылырга, берәүне дә ширек кылмаска кирәклеген каннарына сеңдереп үстерде. Әтисенең һәр гамәлен, әйткән сүзләрен исенә төшерде. Колак төбендә аның ягымлы тавышын ишетә... Хәтер хәзинәсе аша үткәнне әйләндерә башлады.

...Әнә, ул апалары белән бергә тәһарәт ала. Әтиләре аларны күзәтеп тора. «Терсәкләрегезне әйбәтләп, өч кат юыгыз. Савабы үзегезгә күбрәк булыр», – дип өйрәтә. Аңа әнисе Кәүсәриянең йомшак тавышы ялганды. «Ястү намазыннан соң, яңадан бер тапкыр сәҗдәгә китеп, Аллаһтан үзегезгә бәхет-һидәят сорагыз, балалар!»...

Унынчы сыйныфны тәмамлагач, Таһирне әтисе үзе белән Лаеш районында яшәүче Борһан дустына кунакка алып барды. Техникумда белем алучы кызы Рәйсә аларга аш чыгарды. Ул аларга керфеген дә күтәреп карамады. Хан кызы кебек тоелды ул Таһиргә. Беренче тапкыр күргән көнне үк, кыз аның йөрәгендә үз урынын алды. Армиягә чакыру кәгазе килгәч, Рәйсәне күрер өчен, әтисе белән янә аларга барды. Кызның үзен генә туры китереп: «Хәрби бурычымны үтәп кайтуга, Казанга алып китәм мин сине гүзәл кыз», – дип пышылдады. Рәйсә комач кебек кызарды. Таһир аның адресын сорап алды. Өч ел егет белән кыз арасын тыйнак кына язылган хатлар тоташтырды. Таһир көз көне армиядән кайтты, гыйнвар уртасында никахлаштылар...

Әти-әнисе Әлмәткә күченеп киттеләр. Ул Рәйсә белән Волгоград урамындагы ике бүлмәле фатирларында яши башлады. Хатыны эшкә аптекага урнашты, ә Таһир төзелештә кранда эшләде. Уллары Камил шул йортта туды. Тудыру бүлегеннән алып кайткан көнне үк, Таһир Каравай бистәсеннән җир сатып алды һәм алар үзләренә җыйнак кына йорт сал-

дылар. Яңа йортта кызлары Әлфинур туды. Тормыш түгәрәкләнде. Малай чактан дини рухта тәрбияләнгән ир белән хатын үзләрендә гыйлем җитмәвен аңладылар. Рәйсә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә керде, ә Таһиргә әтисе Төркиягә барып укырга киңәш итте. Ата сүзенә каршы килергә өйрәнмәгән ир, гаиләсен калдырып, укырга китте. Чит илдә ике ел белем алды. Гаиләсе белән елга дүрт-биш тапкыр гына күрештеләр. Сабырлык дигәндә, тиңдәше булмаган Рәйсәсе, ике баланы бер үзе тәрбияләде. Төркиядән укып кайткач, Таһир читкә китәргә җыенмаган иде. Әтисе – Татарстанның баш казые Габделхак Саматов, Себергә үз улын җибәрер дип, уена да китермәде. Каршы килеп тә маташты. «Себергә синең кебек чит илдә белем алган гыйлемле имам гына тәкъдим итеп була. Каршы килмә, улым, барасың булгач, барасың!» – диде, катгый итеп. «Син кушкач, килдем, әти. Аллаһ ташламас әле», – диде үз-үзенә.

...Себер җирендә таң иртә ата. Чөнки монда вакыт безгә караганда ике сәгатькә алда йөри. Таһир ялт кына урыныннан сикереп торды. Электр чәйнегендә су кайнатып, тәһарәт алды, намаз укыды. Кайнар чәй эчеп алды. Әнисе пешереп җибәргән ипине чәйнәгән саен йөрәгенә көч кергәнен тойды. Бүген аның тормышында ниндидер яңалык булыр кебек тоелды. Тулай торакның сиртмәле ишеген шыгырдатып ачып, урамга чыгуга, йөзенә салкын җил килеп бәрелде. Әйтерсең лә, йөзенә бозлы су аттылар. Йөзен учы белән каплый төшеп, салмак кына атлады. Урамнар буйлап бараклар тезелеп киткән. Анда-санда яңа биналар күтәрелеп килә. Каршысына олырак яшьтәге, башына түбәтәй кигән ир кеше килгәнен күреп, куанычыннан нишләргә белмичә, туктап калды. Ике кулын сузып исәнләште, Сургутка имам итеп җибәрелгәнен әйтеп, үзе белән таныштырды. «Наиф абыең булам, бик хуп, яшь күренәсең», – диде. Ул Таһирне үзләренә алып кайтты. Чәй өстәле янында бик озаклап сөйләшеп утырдылар.

– Энем, син бик вакытлы килдең, динсез гомер итеп булмый. Зур дини гыйлемем юк, шулай да бала тугач, исем кушарга мине чакырдылар. Үзлегемнән Коръән укырга өйрәндем. Заводта эшләүче Расих кордаш та та намаз укый. Җомга намазын уку өчен 4 кеше булу шарт. Төпле урын булганчы, җомга намазын безнең өйдә укый торыйк.

Наиф абыйсының шушы сүзен ишеткәч, куанычыннан Таһирнең күзеннән яшенә кадәр бәреп чыкты.

– Намаз укый белүче кешеләрне беләсезме? Килсеннәр генә, белмәүчеләрне үзем өйрәтер идем, – дип өзгәләнде Таһир.

– Энем, күрәм, җаның-тәнең белән Аллаһка бирелгәнсең. Аллаһ боерса, синең кебек зур гыйлемле имам булганда, Себер җирендә дә дин күтәрелер…

…Җомга намазына Наиф йортына иң беренче Таһир килеп утырды. Ярты сәгать кала дүрт ир кеше килде. «Заводта бергә эшлибез», – дип таныштырды алар белән Наиф. Таһир башта вәгазь сөйләде. Аннары имамга оеп намаз укыдылар.

Таһир куанып кайтып керде. Ул хәтта баракның салкынлыгын да сизмәде, һәр җомга намазында сөйләргә төрле темага вәгазьләр әзерләү белән мәш килеп, төн үткәрде. Үз-үзенә, кат-кат сөйләп карады. «Үтемле вәгазь тыңлагач, кешенең иманы ныгып, күңеле сафланып калырга тиеш», – дия иде әтисе.

Икенче атнада җомга намазына килгәч, Рәис Латыйпов Таһирнең кулын кысты да:

– Яшь кенә булсаң да, гыйлемле имам син. Без сиңа, булышырбыз, бер команда булырбыз, – дип, күңелен тагын да күтәреп җибәрде.

– Команданы ишәйтер өчен, мәхәллә төзергә кирәк башта, Рәис абый, – диде Таһир.

– Заводта мәрхәмәтле кешеләр күп, барысын да тартырбыз, әкренләп, – диде дә: – Себердә мондый юка бишмәтләр белән генә салкыннан ка-

чып булмый, хәзрәт, мин сиңа җылы өс киеме алып килдем, – дип, зур сумкасыннан мех эчле күн куртка чыгарды.

Таһир уңайсызланып булса да, куртканы киеп карады. Үзенә үлчәп тегелгән кебек таман икәнен күргәч, эченә җылы йөгерде. Ихлас күңеленнән олы рәхмәтләрен җиткерде.

– Салкыннар кайчанга кадәр дәвам итәчәк? – дип сорап куйды.

– Май аенда мондый салкын булганы юк иде. Сабантуй июньнең егермесенә билгеләнде, шуңа кадәр җир җылынып бетә.

Рәис Латыйповның ышанычлы итеп әйткән сүзен ишеткәч, Сабантуйга чакырып, Рәйсәгә шалтыратты.

***

Иреннән хәбәр алу белән, Рәйсә ике баласын юлга әзерли башлады.

Бөтенләйгә бармыйсың ич әле, кызым, күп булса, бер атна торырсың, Камилне генә алып бар, Әлфинурны бездә калдырып тор, - диде әнисе.

Рәйсә әнисенең киңәшен тыңлады. Аларны аэропортка кадәр энесе Илфар озата килде. Салонга кергәч, Рәйсә башта Камилне урнаштырды.

Йоклый алсаң – йокла, улым, яки китап укып утыр, – диде.

Камил сумкасыннан китап алды. Рәйсә үзе тәрәзә янына барып утырды. Мизгел эчендә уйлар чоңгылына кереп чумды. Беренче тапкыр Таһир яныннан кайтканнан бирле, Рәйсә үзенә урын таба алмады. Ирен сагынганын да, аның өчен борчылганын да туганнары алдында йөзенә чыгармады. Эчтән янды, эчтән көйде. Сирәк кенә телефоннан сөйләшкән вакытларда да сагынганын сиздереп, ирен борчымаска тырышты. «Синең янәшәсендә булсак, Себердә яшәргә дә риза, җаныем», – дигән сүзен генә әйтте.

...Рәйсә үзе җиде балалы ишле гаиләдә үсте. Ул үзенең сабыр холкын әнисенә охшата. Әти-әнисе аларны кече яшьтән намаз укытып үстерде. Коръәннән сүрәләр ятлатты, гарәп графикасына өйрәтте. Кем яхшы укый,

әниләре шуңа илле тиен акча бирә иде.. Әниләренең өч яшүсмер кызын елга бер тапкыр, кыш көне, Казанга Тынычлык бистәсендә яшәүче туганнары Муллаян абыйларга кунакка алып барганын исенә төшергәч, Рәйсә көлемсерәп куйды. Утырмага килгән балаларның барысын да чиратлап Коръән укыттыралар. Алар арасында әнисе Кәүсәрия абыстай белән Таһир дә килә иде. Киләчәк тормышы аның белән кушыласы булганга, биш-алты малай арасында күз алдында Таһир генә калды. Армиягә китәр алдыннан, әтисе белән Рәйсәләргә килгәч, ул аны шундук таныды, тик үзенә генә сиздермәде. Ә Таһир, аны таныганын шыпырт кына: «Мин сине күптәннән беләм, армиядән кайтуга, кулыңны сорарга киләм», – дип пышылдады. Рәйсә Лаеш авыл хуҗалыгы техникумында бухгалтер һөнәрен үзләштерде, Таһир белән дусларча хат алыштылар. Егет әйткән сүзендә торды: хәрби хезмәттән кайтуга, әти-әнисе белән Рәйсәне сорап килделәр. 1982 елның чатнама суык 15 гыйнварында туй ясадылар. Өйләнешкәч кенә, үзләренең яшүсмер чактагы оял- чанлыкларын исләренә төшереп, көлешеп утырдылар. Рәйсә тирән итеп сулап куйды. Казанда төпләнеп яши генә башлагач, язмыш аларга яңа сынау җибәрде. Ул үз алдына: «Ашар ризыгыбыз Себердә булгач, бармый нихәл итәсең!» – дип кенә әйтеп куйды.

...1993 елның июнь ае. Таһир гаиләсен Сургут аэропортында каршы алды. Вакытлыча яшәп торырга Рәис Латыйповның әнисе йортына алып кайтып урнаштырды да, үзе ашыгыч эшем бар дип, китеп барды.

Себергә дин нуры таратырга килгән кардәшләребезне баракта яшәтеп булмый, гаиләңне туп-туры үземә алып кайт, дидем хәзрәткә. Әйдәгез, узыгыз, – дип, Нәсыйха апа якты йөз белән каршы алды. Өч бүлмәле фатирының берсенә кунакларны урнаштырды.

Аллаһы боерса, барысы да уң булыр, минем кебек, белгәне белән гамәл кылып яшәүчеләр байтак әле без монда. Иртәгә Сабантуйда барысы

белән дә таныштырырмын, – дигәч, Рәйсә аңа күчтәнәч итеп алып килгән бер сумка Корбан ите бирде.

Иии, кызым, шундый ерак җирләрдән зур күчтәнәчләр белән килгәнсең. Иртәгә мөселман кардәшләребезгә үз кулың белән бирерсең, – дип, итләрне суыткычка урнаштырды да: – Әйдәгез, табын янына узыгыз, үз йортыгыздагы кебек иркенләп утырыгыз, – диде.

Нәсыйха татар хатын-кызына хас булган кунакчыллык күрсәтте. Үзе пешергән түгәрәк ипине калын итеп кисеп, табынга куйды. Аннары камыр ризыклары чыгарды.

Үзебезчә, тәмле итеп чәй эчик әле, – диде дә, Казандагы тормышлар белән кызыксынды.

Иялəшкән идек инде Казанга да. Үзебез салган яңа йортыбызга күченеп яши башлаган идек тә... Монда да иялəшеп кенә китсәк ярар иде инде. Яңадан өр-яңадан тормыш башларга кирәк бит. Улыбыз татар гимназиясендә укыды, кызыбыз бакчада татар группасында йөрде. Икесе дә русча юньләп сөйләшә белмиләр. Аларга монда тел өйрәнергә кирәк булачак. Барысы да уйландыра инде, – диде Рәйсә.

Нәсыйханың бусагасыннан әле генә атлап кергән булса да, күптәнге дусты кебек якын итеп, күңелендәге уйлары белән бүлеште.

Сургут җитәкчеләре үзләре чакырып китергәч, фатирын да бирерләр, мәчет салырга да ярдәм итәрләр. Авырлыкларны җиңеп чыкканчы сабыр итәргә туры килә инде, сеңлем. Монда төрле яктан җыелган халык арасында, диннең «д» хәрефен белмәүчеләре күбрәк. Аллаһ кулында барысы да, әгәр Себер җирендә ислам диненең җәелүен тели икән, барлык ишекләрне дә ачар.

Без дә Аллаһ ярдәменә генә ышанып килдек, Нәсыйха апа. Менә үзегез дә безне якын туганнарыгыз кебек кабул иттегез.

Казыксыз җирдә казык кагу өчен, бик диндар кеше булу кирәк. Таһир хәзрәт нәкъ шундый, гаярь ир солтаны. Аңа булышмый мөмкин түгел.

Нәсыйха апа әйткән иде диярсең, Аллаһы боерса, Сургутыбызда биек манаралы мәчетләрдән азан тавышы яңгырар көннәрне дә күрербез, – дип, Нәсыйха Рәйсә белән Камилнең чәен яңартып бирде.

Амин, – диде Рәйсә. – Шулай гына була күрсен…

***

Сургут шәһәре тарихында беренче тапкыр Сабантуйда азан әйтелде. Яшүсмер малай саф, чиста тавыш белән азан әйтә башлагач, халык шым булды. Бер-берсенә: «Кем улы бу малай?» – дигән сораулы карашлар сирпелде. Нәсыйха апа хатын-кызларга, Рәис Латыйпов ир-атларга таба борылып, азан әйтүченең шәһәрнең имамы Таһир хәзрәтнең ун яшьлек улы Камил әйткәнен җиткерде. Сүз җил кебек мәйданга таралды.

Шәһәребезнең имамы Таһир хәзрәт Саматовны барыгыз да танып, күреп калыгыз. Барлык дини эшләр аның җитәкчелегендә башкарылачак, – диде хакимият башлыгы һәм сүзне хәзрәтнең үзенә бирде.

Рәйсә дулкынланудан, иренең барлык сүзләрен ишетеп тә бетерә алмады. Аны таныш булмаган апалар әйләндереп алды.

Таһир хәзрәтнең абыстае икәнсез, танышыйк, – дип кулларын суздылар.

Мин – Әлфия апаң, Зәйтүнә, Нурдидә, ирем Нурислам абыең…

Рәйсәнең алар белән күрешкәндә, сөенеченнән күзеннән яшенә кадәр бәреп чыкты, һәрберсенең кулына Корбан ите тоттырды.

Таһир хәзрәткә бергәләп булышыйк, ямегез, апаларым, – дип кенә әйтә алды.

Дин бит ул, абыстай, барыбыз өчен дә яшәү ачкычы, – диде арадан берсе.

…Икенче көнне иртән үк Таһир, мәхәллә төзергә Устав эшләтү өчен, Ханты-Манси округына китте. Рәйсә улын җитәкләп, шәһәр белән та-

нышты. Сургут шәһәрендә зур корылмалар төзелеп кенә килә. Мәчет кайсы ягында булыр икән?

Әни! – диде Камил.

Әү, балам.

Бу матур шәһәр түгел, Казанда гына яшик. Мин монда укымыйм.

Алай әйтергә ярамый, улым. Иртәгә Казанга кайтабыз. Әтиең фатир алгач, монда күченеп киләбез.

Әтиеңне ялгыз гына яшәтеп булмый ич, – дип җавап биргәч, Камил эндәшмәде.

***

...Санаулы көн тиз узды. Ире, фатир бирделәр, дип хәбәр итүгә, Рәйсә иң кирәкле әйберләрен тартмаларга тутырды. Гаиләсен алырга Таһир машина белән кайтты. Ике бала белән ике мең чакрым машинада авыр булыр дип, Рәйсә поезд белән барды.

...Ике ай эчендә Таһир хәзрәтнең гаиләсенә фатир да бирелгән, Камилне – мәктәпкә, Әлфинурны бакчага урнаштырырга да сөйләшенгән булуы, аларның тормышын җанландырып җибәрде. Беренче сентябрь көнне Камилне мәктәпкә илттеләр. Бигрәк тә укытучысының татар булуына куандылар. Әлфинурны бакчага иярләштерү генә әлегә авыр Рәйсәгә. Көн саен: «Казанга кайтыйк, дусларымны сагындым», – дип елый. Бакчадан кайтканда, күршедә яшәүче балаларның велосипедта йөргәннәрен күргәч: «Миңа да сәпит кирәк», – диде. Балага: «Акчабыз юк бит әле, кызым», – дисә дә, Рәйсә Таһир белән киңәште. Дөресрәге, велосипед алып биргәч, Казанны сагынуы басылмасмы дип өметләнде. Шул кичне аларга Рәис Латыйпов килде. Кыз велосипед сорый дигәч, бурычка акча биреп торды. Әлфинурга сәпит алып биргәч, сагынып елавы кимеде...

...Судья хатыны Фәния аларны Коръән мәҗлесенә чакырып килгәндә, Рәйсә камыр ризыгы пешерә иде. Үзләре янына табынга чакырды. Өстәлгә куярга кабартма белән шикәрдән башка ризык юк.

Булганы белән җитешегез, әлегә кибеттән тәм-том сатып алырлык мөмкинлек юк. Казаннан алып килгән оныбыз бар, көн саен диярлек тәмлүшкәләр пешерәм.

Фәния кабартманы мактый-мактый, Рәйсә ясап биргән чәйне эчеп куйды. Янәшәсендә утырган Әлфинурның чәченнән сыйпап, хәлен сорашты. Бер катлы сабый, күңелендәгесен әйтеп салды.

Көн саен кабартма да кабартма. Казанда кәнфит тә бар иде. Монда уйнарга уенчыгым да юк, – диде, авызын турсайтып.

Иртәгә безгә мәҗлескә син дә кил яме, уенчыклар бирермен, – диде Фәния.

Мәҗлескә дүртесе бергә бардылар. Таһир хәзрәт йортка Коръән укыды. Мәҗлестән соң да кунакларның хәзрәтне табын яныннан җибәрәселәре килмәде. Ипләп кенә үзләренең сорауларын бирделәр.

Ханты-Манси округында юлларың уңдымы, хәзрәт?

Мәхәлләнең Уставын алу авыр булмадымы?

Мәҗлестәгеләрнең дини эшчәнлек белән кызыксынулары хәзрәтнең күңелен күтәрде.

Аллага шөкер, бик авырлык белән булса да, мәхәлләбезне теркәтеп, Уставын алып кайттык. Профсоюз комитеты рәисе Рәис Латыйпов белән өч көн көрәштек руслар белән. «Монда дини оешма нәрсәгә кирәк? Без иректле дәүләттә яшибез, мөселманнар дигән аерым оешма төзү кирәк түгел», – дип каршы төште юстиция җитәкчесе Козлов. Татар юристларына, татар судьясына аңлатып, бик авырлык белән алдык Уставны. Рәискә Аллаһның рәхмәте булсын, аның дуслары ярдәм итте. Кунакханәләр тулы, кунып чыгарга урын юк. Өч көн пароход каютасында йокладык. Әлхәмдүлилләһи, бу эшебезне башкардык. Хәзер безнең алда мәчет салу

бурычы тора, кардәшләрем. Халыкка йөрергә уңайлы булсын өчен, урынны шәһәрнең уртасыннан алырга иде.

– Сургутта җир күп, булыр, хәзрәт. Мәхәллә составындагы җитәкчеләр булышырлар.

– Аллаһка һәм җитәкчеләрнең миһербанлы күңеленә ышанам да инде.

Мәҗлестәгеләр, үзләренчә ярдәм итәргә теләп, мәчет салу өчен уңайлы урыннар тәкъдим иттеләр. Кайдан биреләчәге әле Аллаһ кулында иде...

Саматовлар гаиләсен, Фәния белән ире фатирларына кадәр озата килделәр. Өстәлгә күп итеп азык-төлек куйдылар, Әлфинурга бер капчык йомшак уенчык бирделәр.

– Безнең балалар үсте инде, рәхәтләнеп уйна, матурым, – диде аңа Фәния.

*Дәвамы киләсе санда*

*Гөлсинә Галимуллинаның*

*«Кайнар диңгез юлы» повестеннән өзек*